ИДЕЛ
Яшьләр журналы

**2017, №09 (336)**

1989 елның июль аеннан чыга



# ЭЧТӘЛЕК

*Сөй җирне, сөй халыкны,*
*Сөй халыкның дөньясын!*

**2** ТҮР БАШЫ
**Ландыш ЗАҺРЕТДИНОВА**
*Рифә Рахман: «Ни генә эшләсәм дә, әти белән әнине күз алдына китерәм, ә алар әле – миннән бик югарыда»*

**6** ЛӘБИБИ ХӘТЕР
**Ләбиб ЛЕРОН**
*Нури Арсланов васыяте*

**10** СӘЯХӘТНАМӘ
**Фәния ХУҖАХМӘТ**
*Иран – Арийлар иле*

**14** ИДЕЛ-ЙОРТ
**Энҗе БАСЫЙРОВА**
*Аның өчен бар дөнья ачык*

**17** TAT-ONLINE
**Гөлүсә ШИҺАПОВА**
*Бишәү чыктык ерак юлга!*

**18** TAT-ONLINE
**Радик САБИРОВ**
*Ркаил Зәйдулланың яшьлегенә сәфәре*

**20** ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕ
**Гөлүсә ЗАКИРОВА**
*«Үз өемдә үз көем»*

**22** ГАЛӘМӘТ
**Рөстәм БАЙБУЛАТ**
*Сак булыгыз: спиннер!*

**24** ШИГЪРИЯТ
**Эльвира САФИНА**
*Кеше бәхетенә кызыкма*

**26** ШИГЪРИЯТ
**Рифә РАХМАН**
*Иреннәрем сусылланып китәр, керфек очларына иелсәң...*

**29** НӘСЕР
**Рәзилә ГАЗИЗОВА**
*Либераль Ләйлә*

**32** НӘСЕР
**Гомәр ДАУТОВ**
*Төш*

**34** НӘСЕР
**Алмаз ХӘМЗИН**
*Себер Мәҗнүннәре*

**49** ША-ЯРЫШ
**АРСЛАНГАЛИ**
*Наласа мәзәкләре*

**50** ӘДӘБИ ТӘНКЫЙТЬ
**Гөлшат ФӘТТАХОВА**
*Ипле көлә беләсеңме?*

**54** ШИГЪРИЯТ
**Әсгать ЗАКИРОВ**
*Кошлар җыры ак кәгазьдә*

**55** УКУЧЫ МӨНБӘРЕ
**Эльвира ФАТЫЙХОВА**
*Язучы Марат Кәбировка ачык хат*

**56** СПОРТ
**Радик САБИРОВ**
*Киткән урын буш тормый, ләкин...*

**60** МӘДРӘСӘ
**Нәзирә ГЫЙЗЗӘТУЛЛИНА**
*Дини белемгә яңа мөмкинлекләр*

**62** ТАТАР ҖИҺАНЫ
**Гөлүсә ЗАКИРОВА**
*Римзил Вәлинең күчмә бакчасы*

**68** ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ
**Асия ЗАРИПОВА**
*Саба хоккейчылары*

**70** ИҖАТХАНӘ
**Альбина ГОМӘРОВА**
*Алисә Венесуэла илендә*

**74** СӘЛӘТЛЕЛӘР УНИВЕРСИТЕТЫ
**Сөмбел ӘХМӘТҖАНОВА**
*Татарстан укучылары «Сириус»та: «Проект иҗаты башкача фикер йөртергә ярдәм итә»*

**76** ГОМЕР ИТМЕШ
**Чәчәк ГӘРӘЕВА**
*Исемнәр күркәм булсын!*

**78** СӘЛБИТ
**Йолдыз МИҢНУЛЛИНА**
*Эй... йөрәк тибә: Казан – Монреаль – Казан*





**ЛӘБИБИ ХӘТЕР**
*Нури Арсланов васыяте*



**ИДЕЛ-ЙОРТ**
*Аның өчен бар дөнья ачык*



**ГАИЛӘ КЫЙММӘТЛӘРЕ**
*«Үз өемдә үз көем»*

# Заман

*түр башы*

Ландыш Заһретдинова

# «НИ ГЕНӘ ЭШЛӘСӘМ ДӘ, ӘТИ БЕЛӘН ӘНИНЕ КҮЗ АЛДЫНА КИТЕРӘМ, Ә АЛАР ӘЛЕ – МИННӘН БИК ЮГАРЫДА»



Сентябрь аенда танылган язучы, публицист, галимә-педагог Рифә Рахманга 55 яшь тула. Шул уңайдан шагыйрә белән әңгәмә тәкъдим итәбез.

**– Рифә апа, Сез – бик күп яшьләрне әдәбият мәйданына җитәкләп алып кергән кеше. Ә үзегезнең беренче иҗат адымнарыгыз ничек һәм кем ярдәмендә башланды?**

– Үземне белгәннән бирле нәрсәдер уйлап табам: ясыйм, язам, корам, хәтта урамда шигырь сөйләп бару – минем өчен гадәти бер хәл. Күптән түгел өч яшьлек оныкам, әбием, Тукай бабай кебек син дә китаплар яза аласыңмы, дип сорады. Мин әйтәм: Назлым, мин бит сиңа көннәр буе үз әкиятләремне, шигырьләремне сөйләп торам. Алайса, әйдә, минем турындагы берәрсен тагын сөйлә әле, ди. Нәшриятка барганчы сөйләдем. Матур икән, кайткач, энигә китабыңнан да укып күрсәтерсең, диде. Аларның берсе дә китапта юк, сөйләп барам, онытып барам. Кайткач, шуны ук яңадан сөйләмәгәч, укып та күрсәтмәгәч, бераз кәефсезләнде. Аңладым: бала өчен дә китапка язылган сүз – зур-

рак сүз, ә китап чыгарган шагыйрь – зур шагыйрь икән.

Җитәкләү дигәннән, кемнең дә булса реаль ярдәмен бервакытта да тоймадым. Аңа ихтыяҗым да булмады. Беренче шигырьләремне дә, орышырлар дип куркып, әтиәнигә әйтмичә генә, редакциягә юллаган идем, югыйсә үзләре дә бер дигән язалар һәм укытучылар иде бит. Хәтта әдәбият укытучым да әтием булды. Басылып чыкканны күреп тә орышмагач, алга таба күрсәтеп тормадым да тормадым инде. Гаиләдә вакытлы матбугатны, әдәби әсәрләрне бергәләп укып, өстәл тирәсендә фикер алыша идек, ә менә мин язганнарны укымадык, чөнки басылып чыккан шигырьләрем, мәкаләләрем, рәсемнәрем бик кызык яисә матур булганда да, якын кешеләремнән ояла идем. Хәзер дә шулай ук. Авылдашлар, туганнар каршында чыгыш ясый башласам, еш кына борчылудан тавыш юкка чыга. Кайвакыт шуны алдан тоеп алсам, кеше сизгәнче дип, сөйләүдән тиз туктыйм. Шигырь укыганда залда якын кешеләрнең утыруын теләмим, ә менә китапларымны яратып укуларына бик сөенәм. Әнием аларны уннарча мәртәбә укып чыккандыр инде.

Өлкән язучыларның ярдәменә килгәндә... Элек, хәзерге кебек, кешеләрне иҗатка, Берлеккә керергә өндәү, язганнарыңны төзәтеп бастыру юк иде бит ул. Бала вакытымда районның «Салават күпере» берләшмәсенә йөрдем, әмма бу ярдәм эзләп бару түгел, яңа һава сулау, башкалар белән аралашу өчен иде. Мин бервакытта да китаплар чыгарырга, язучы таныклыгы алырга атлыкмадым. Хәзер исә, мәктәпкә кергәнче үк форма планында камил яза торып, кемдер һәм нәрсәдер хакына үз-үземне зур әдәбияттан озак вакытлар читләштерү, бик актив язган чорымда әсәрләремне иремә генә укып, чүплеккә ташлап яшәвем дөрес булмаган дип саныйм. Мин әдәбияттан шуның аркасында иң кызыклы ун елдан артык иҗатымны сызып ташладым. Китапларым эчендә очраклы сакланып калган яшьлек шигырьләрем очраса, аларның бүгенге әсәрләремнән башкарак рухта язылганлыгын, хәтта кызыклырак икәнлеген күрерсез. Яшьлек шигъриятен бервакытта да кабатлап булмый, ә менә проза белән эш башкачарак тора.

**– Ни өчен?**

– Яши-яши, иҗатка материал бик күп туплана. Чынбарлыктан алган конфликтлар, эш-хәлләр укучы өчен кызыграк, ныграк ышандыру көченә ия. Өлкәнрәкләрнең тормышны аңлау һәм фикерләү тирәнлеге, кешеләрне белүе, эчендәгеләрен укуы да – башка. Шигърияттә син буш хыяллар, өермәле хисләр, сюжет ситуацияләре белән дә ерып чыгасың, каләмең генә метафорик осталыкка ия булсын. Проза өчен болар гына җитми. Бөтен шагыйрьләр дә проза язмый бит, хәлбуки алар каләменнән чыккан хикәяләр күпкә отышлырак була дип саналса да. Өлкәнәйгәч, талантлылары бу өлкәдә үзен сынамый калмый. Дөрес, талантлы булып та, проза язмаучылар бар, әмма үтә сирәк, һәм һәрберсенең сәбәбен үземчә аңлатып бирә алыр идем. Зур тормыш мәктәбе, төрле шәхси авырлыклар кичергән, үзенә каршы махсус торгызылган киртәләрне үтә алган талант иясе проза язмый кала алмый. Милләт фаҗигасен шәхси фаҗига дәрәҗәсендә күтәргәннәр бигрәк тә. Шагыйрь А. Хәлим, Ф. Сафин, Р. Зәйдулла, З. Хәким, Ф. Җамалетдинова, И. Иксанова... Әгәр үз язмышымны гына сурәтләп утырсам да, гомер ахырынача материалым җитәчәк.

**– Бу сүз үзе генә дә Сезнең көрәшче икәнлегегез турында уйга салды.**

– Һичшиксез. Мин – туры сүзле ике нәселнең баласы. Зур тормышка аяк басканчы, бигрәк тә әтием кебек гаделләр, кешеләргә ярдәмчеләр, җитәкчеләргә ялагайланмыйча да үз юлын тапканнар күп була, бу гадәти бер хәлдер дип уйлый идем. Ул авылыбызның һәр кешесенә терәк кебек гомер итте, кызганыч, арабыздан иртә китте. Миңа нигәдер авылдашларым да аңа охшаган һәм аныңча яшәргә тиеш бер кеше кебек карады. Әле дә урамнан барганымда туктатып, молодец, әтиеңә охшагансың, диючеләр бар. Мин башкача булдыра алмыйм. Аның кебек үк милләт дип җан атам, авырлыкка тарыганнарны кызганам, ярдәмгә ташланасым килә, гаделсезлеккә түзеп тора алмыйм. Шул ук вакытта көрәшчелек сыйфатым зур күпчелекнең, хәтта үзе хакында, мин шундый, мин тегенди, дип лаф орган ирләрнең көчсезле-

**Көрәшчелек сыйфатым зур күпчелекнең, хәтта үзе хакында, мин шундый, мин тегенди, дип лаф орган ирләрнең көчсезлеген күрүдән, алардан бервакытта да ярдәм тоймавым аркасында ныгыды. Алай да таныйм: гаделлек сагында торудан да авыры юк.**

ген күрүдән, алардан бервакытта да ярдәм тоймавым аркасында ныгыды. Алай да таныйм: гаделлек сагында торудан да авыры юк. Зур залларда сүз алып, милләт, тел яшәсен, дип күңелеңдә булмаганнарны сөйләп, үзеңне күрсәтергә, көрәшчеләр кирәк, дип лаф орырга була ул, син мәйданнарга чыгып кара, бер генә тапкыр югарыдагыларга адресланган тәгаен эчтәлекле мәкалә белән матбугатта чыгыш яса – аннан соң ничек язарсың, ничек яшәрсең, карарбыз. Бер генә көн милләт хезмәтендәге Фәүзия Бәйрәмова булып яшәп карарга да киңәш итәм. Шул милләтнең ниндидер тупас, маңкорт, имансыз көчләре матбугатта агызган шакшыга гына түзеп карарга. Андый сүзләрне язучы, ә асылда куркак булганнарга, көрәшчеләр кирәк икән, әйдә, көрәш, нигә көрәшчеләргә каршы тарафта яшисең, аларның майлы калҗаларын ашап рәхәт көн итәсең, дип әйтәсе килә.

**– Милли хәрәкәтнең сүнүеннән, татар тормышындагы коточкыч киеренкелектән, киләчәкне фаразлаулардан иҗатка теләк сүрелмиме?**

– Сүрелә. Яза башлаган җиремнән торып китәм. Кем укыр? Кем аңлар? Безнең бу хәсрәтле көннәребезне киләчәк ничек бәяләр? Ул киләчәк нинди булыр? Бер гасырдан соңгы татар… Кем ул? Нинди ул? Бу сораулар минем төнге йокымны качыра.

**– Нишләргә соң?**

– Сүздән кайчан да бер эшкә күчәргә. Хәер, инде ни теләгәнеңне сөйләп тә булмый торган заманда яшибез. Сүзнең дә ихласын батырлар гына әйтә, гадел һәм кыю фикергә мәйдан тарайганнан тарая бара. Һәркайда тикшерү, әлегә – яшерен һәм төрле битлекләр кигән цензура. Дөрес яңгыраган сүзгә шәхси газеталарда гына юлыгасың, ә бит аларның редакторларын, чыгаручыларын да эчке – күңелләрендәге цензура богаулаган. Кызганыч, шәхси газеталарның барысы да милләт язмышын кайгырткан мәкаләләр язмый, хәзер инде рәсмиләрендә дә бу темага урын азрак бирә. Кайнар язылган иҗтимагый-сәяси мәкаләләр вакытлы матбугат органын тагын да популярлаштырачак кына, югыйсә.

Татар конгрессының корылтаенда утырдым. Тел, мәгариф мәсьәләләре каралды. Андагы чыгышларны тыңлаганнан соң, болай булгач, юк икән инде, дип кул селтәп кайтып киттем. Их, бар чыгыш ясаучы да, үзен бер читкә куеп торып, милләтне яшәтү турында глобальрәк масштабта, дәүләт яссылыгындагы хәрәкәт юнәлешендә фикер йөртсәче. Милләтне, телне гаилә, мәктәп директоры, җыр һәм тагын кемнәрдер, ниләрдер яшәтә ала, кебек ахмак сүзләр күп тыңланылды. Аның гаиләсе дә еш кына катнаш бит әле. Әлеге институтларның нинди булуы илнең эчке сәясәтеннән тора ул. Гаиләне үзгәртеп, илне үзгәртеп буламыни? Мәгърифәтчелек чорында яшибезмени? Синең корылтаең турында ишетеп тә белмәгән урыслашкан гаиләләрнең акылына үзеннән-үзе килә торган теләкмени ул? Телне саклау кирәклеген аларга кем сеңдерергә тиеш соң? Күпчелек урыс мәктәпләрендә белем ала. Шуларда укыткан урыс телле укытучылар өндәргә тиешмени таныклыгы буенча татар саналган сабыйларны телгә өйрәнүгә? Әз сәгать бирелгәнлектән, укучыларына берни өйрәтергә дә өлгермәгән гади укытучымы? Илең халкыңныкы булганда, җитәкчеләр үзләре теләгәнчә идарә итә алганда, әлеге проблемалар көн кадагына да куелмас иде. Без бит, татарча сөйләшергә һәм укырга рөхсәт сорап, башка халык алдына килеп тезләнгән хәлдә. Көлке дә. Аяныч та. Ышандырмаслык, булмаска тиеш бер хәлдә. Асылда, гомумиләштергәндә – зур милли фаҗига. Чыгышлар шуны күрсәтте: үтә тар фикерле депутатлар сайлана корылтайга. Хәтта «түгәрәк өстәл»дә дә бер төпле итеп, тирәннән сүз алып баручы җәмәгать эшлеклесенә, бер кыю язучыга сүз бирү каралмаган. Ярый әле Фәндәс абый чыгышы булды. Ул башка барлык чыгышларны алмаштырды.

**– Сез гомер буе университетта укыттыгыз. Без Сездә укыганда, университетта үзегез булып кала алуыгызга аптырадык.**

– Чын мөгаллим, укучыларын иманлы татар итеп күрергә теләүче педагог шундый булырга тиеш тә. Минем гадел әңгәмәмә комментарийларда берәү, ул кырык эш урыны алмаштырган, дип язган, имеш. Хезмәт кенәгәмне ачып караганмы әллә? Чыннан да, язмышымны Казан дәүләт университеты белән бәйләдем, ул юкка чыгарылгач, аның үзем белән эшләгән тирән белемле фәнни җәмәгатьчелеге таралгач, хәзерге КФУда үз урыным калмады, дип санап киттем. Директор Р. Җамалетдиновка берничә мәртәбә гариза тотып кердем, баштарак, китмәгез инде, сез бик кирәкле белгеч, дигәч, бик матур сөйләшкәч, китми дә торган идем, алга таба да калырга үз-үземне мәҗбүр итә алмадым. Соңыннан, хушлашырга кергәч тә, теләсә кайчан әйләнеп кайтыгыз, диде. Шул сүзләре өчен, ихластан әйтелгәндерме-юкмы, бик рәхмәтлемен.

Кайда гына эшләсәм дә, үземне ирекле тотарга өйрәнгәнмен, студентларымны да шундый булуларын теләп укыттым. Мине тар кысаларда беркем дә яшәтә һәм эшләтә алмаячак. Соңгы эш көнемдә кафедра җитәкчем Флера Сәгый-



товна ишек төбенә кадәр озата чыкты. Аны башкаларга хөрмәтле һәм гадел мөнәсәбәте өчен бик хөрмәт итә идем. Ул ялганларга бирмәс: җитәкче кешелекле булганда, үзен хезмәткәрләреннән өстен куймаганда, мин бар кешедән дә күбрәк, нәтиҗәлерәк эшлим. Икебезгә дә хушлашу авыр булды кебек, шулай да бу КДУны югалту авырлыгы түгел иде инде. Аның белән татар дөньясыннан зур фән китеп барды. Кырык эштән киткән, дигәннән, әйе, янәшә рәвештә, бик күп җирләрдә эшләргә туры килде, чөнки кая гына карасаң да, хәзерлекле кадрлар җитми, чакырып алалар иде. Әйтик, янәшә рәвештә ТӘһСИдә эшләвем – андагы иҗтимагый мөһим башлангычларга үземнән өлеш кертү максатыннан булды. Тәҗрибәле өлкән буын сан ягыннан аз калды, белемле яшьләр хезмәт хакы түбән фән өлкәсенә килергә атлыгып тормый, әлегә төп йөкне илле-алтмыш яшьлекләр тартып бара. Инде һаман да Г. Ибраһимов исемендәге институтта хезмәт итүемә милләт каршындагы бер бурыч рәвешендә карыйм.

**– Рифә апа, нинди популяр булуыгызга карамастан, Сез үтә гади дә бит әле.**

– Үз-үземнән көлебрәк әйткәндә: димәк, талантлымын. Галимнәр, гадилек һәм табигыйлек чын талант иясенең төп сыйфатлары, дип яза. Эрелек, үзеңне башкалардан югары кую ул, чыннан да – бернигә сәләтсезләр, кешеләрнең хезмәте хисабына яшәүчеләр, шул хезмәтне үзенеке итеп күрсәтүчеләр гамәлияте. Китапханәмдә 8-9 мең китап, берничә йөзе бакчамда калды, берничә йөзе – гаражда, берничә йөзе башкаларга бирелгән, һәм шуларның һәрберсе белән танышмын, шактые хакында фәнни мәкаләләрдә язылган, йә булмаса башкача кулланышка кертелгәннәр. Ә китапханәләрдә укыган китапларның очы-кырые юк!

**– Үзегезгә авырлык китерүчеләргә бәхет теләп буламыни?**

– Була. Ул шәхеснең рухи көче турында сөйли. Әле бала чагымда миннән күпкә өлкән малайлар белән бер иптәшебезгә бер гүзәл шуклык эшләгән, аны чын мәгънәсендә сөендергән идек. Әнисе мәгънәсен аңламадымы, нишләптер төп гаепле мин дип уйлады, ә мин үпкәләп елап җибәрдем, бик кечкенә идем шул әле. Өйгә кайтырга оялдым, кышкы карларга бата-бата су буйларында йөрдем. Шуннан аларга бик зур авырлыклар килде. Алай да булмагандыр инде ул: шул үпкәм өченме әллә дип бик үкендем, хәсрәтләре үтсен, дип теләдем, үпкәм бик нык төшә икән, моннан соң үпкәләргә тырышмам, дидем. Ачу чыкканда, үпкәләгәндә, авырлыкка тарыганда, һәркем тарафыннан да ниндидер сүзләр әйтелә бит ул, әмма алар һичкемнең җанына җиңеллек китерми. Мин хәтта әдәби тәнкыйть мәкаләләре язганда да, оппонентларымны кызганам, әмма әдәбиятны һәм җәмгыятьне кемдер сафландырырга тиеш, дигән фикер белән эш йөртәм. Әгәр мин дә түгел икән – кем? Һәрбер журналист һәм әдип алдына шул сорауны куеп иҗат итәргә, зур мәйданнарда чыгышлар ясарга, үз халкын үз урынында һәм үз биеклегендә күрәшергә, нәтиҗәсенә дә ирешергә әйдәргә тиеш.

**– Сезгә мондый рухны сакларганиләр һәм кемнәр ярдәм итә соң?**

– Шундый ук караштагы, намаздагы әниемнең исәнлеге. Янәшәмдә киявемнең, кызымның, оныкларымның булуы, аларның мине олылыклавы. Милләт, җәмгыять, әдәбият дип сөйләсәм дә, мин бит шушы гаиләнең алдында барган маякчы әле. Берәү миңа, нигә Сез җитәкчегезгә гел ялган җиткереп торасыз, дип катырак әйтүемә бәйле рәвештә, сез бит – педагог, ничек шулай әйтә аласыз, диде. Бердән, педагоглык шул дөресен күзгә карап әйтүдә дә чагыла инде ул. Икенчедән, мин кырык яшьлекләрнең тәрбиячесе түгел, алар, чирләреннән котылу кирәксә, табибларга йөрергә тиеш. Мин кызымның кемлеге өчен – тулысынча, ә оныкларымның нинди булуы өчен – өлешчә җавап тотучы. Алар әлегә йөзгә кызыллык китермәде. Балаларым, инглиз телендә генә аралашырга яраган компаниядә эшләсәләр дә, дуслары урыс телле булса да, өйдә бары тик татарча гына сөйләшә, татар әдәбиятын белә һәм әлеге бай әдәбияттан йөз әсәрне генә укырга тиешмен дип аерып куюны бер ахмаклык саный. Балалар – безнең йөзебез дә, рухи яшәү чыганагыбыз да. Башкалардан таләп иткәнне мин иң элек үземнән, аннан балалардан һәм күпкә ныграк итеп сорыйм. Тәрбиянең дә бер генә юлы бар дип саныйм, бу – шәхси үрнәк. Мин менә, ни генә эшләсәм дә, әти белән әнине күз алдына китерәм, ә алар әле – миннән бик югарыда.



Ләбиб Лерон



# НУРИ АРСЛАНОВ васыяте

Башлыйм әле сүзне «Атлантида» белән:
Атлантида! Атлантида баткан!
Эз калмаган бөек халыктан...
Ә без – менә, без – бар, эз бар җирдә –
Без батырган саен калыккан.



«Атлантида» – рухи остазым Нури ага Арслановның мин иң яраткан, күңелемә аеруча хуш килгән шигырьләреннән берсе:

*Кем булгандыр бабам? Кыпчакмы ул,*
*Болгармы ул? Нинди аерма?!*
*Татар дигән исем йөртәбез без –*
*Татар каны ага тамырда!*

«Атлантида» шигыре 1969 елда, мин беренче сыйныфка укырга кергән вакытта язылган:

*Атлантида язмышы юк безгә,*
*Оныкларның ачык бабасы:*
*– Нәселең кем? – дип сорасалар әгәр,*
*Әйтерләр:*
*– Без – татар баласы!*

Нәкъ ун елдан соң мин шагыйрьләр мәркәзе булган Казанга килермен һәм язучыларның Бауман урамындагы Тукай клубында һәр атна саен бара торган әдәби-музыкаль кичәләрнең берсендә Аны – Нури аганы очратырмын. Әлбәттә, күрешү бәхетенә ирешә алмам әле ул вакытта... Олпат шагыйрь белән бары тик 1986 елның маеннан соң гына ныклап аралаша башлармын. Бу вакыт – Татарстан Язучылар берлегендә СССР Әдәби фондының Татарстан бүлеге директоры вазифасын башкарган чагым булыр...

Иң әүвәл бер истәлек-хатирәне яңартып алыйм әле. 1980 елның 30 октябре. «Шагыйрь Нури Арсланов белән очрашу». Зәңгәрсу тышлы «Истәлекләр дәфтәре»ннән:

«Әдәбият сөючеләр игътибарына!

30 октябрьдә «Татарстан яшьләре» газетасы каршында эшләп килгән «Яшьлек» әдәби берләшмәсенең чираттагы утырышы була. Көн тәртибе:

1. Яңа бюро составын сайлау.
2. Шагыйрь Нури Арсланов һәм язучы Барлас Камалов белән очрашу.
3. Яшь иҗат көчләренең яңа әсәрләрен укып тикшерү».

Декабристлар урамындагы Матбугат йорты. Сигезенче кат. «Татарстан яшьләре» газетасы редакциясе. Баш редактор бүлмәсе. Түрдә – Нури Арсланов белән Барлас Камалов. Бу очрашуга кадәр үк Нури аганы берничә мәртәбә күргәнем булды. Мәсәлән, соңгы тапкыр

мин аны Булат Сөләйманов белән Салисә Гәрәеваны Язучылар берлегенә әгъза итеп тәкъдим иткән секция утырышында күрдем. Нури ага анда Салисә Гәрәева турында бик матур итеп сөйләгән иде...»

Янә бер ай артка чигеп, әйдәгез, әдәби берләшмә утырышыннан шигърият секциясенә күчеп алыйк әле.

1980 елның 30 сентябрендә нәкъ кырык каләм әһле катнашында (Нури агадан тыш, анда Х. Туфан, И. Юзеев, Р. Фәйзуллин, Р. Гаташ (секция җитәкчесе), М. Әгъләмов, Рәшит Әхмәтҗанов, Р. Батулла, Р. Мингалим, Т. Әйди, Х. Гайнетдинов, Җ. Дәрзаман, Ш. Маннапов һәм башкалар бар иде) узган әлеге шигърият секциясендә Нури Арсланов болай дип чыгыш ясаган иде:

– Салисә (Гәрәева) үзенең туган ягыннан, Минзәләдән китсә дә (*С. Гәрәеваның Чиләбедә яшәгән чагы. –* ***Л.Л.***), иҗат итүеннән туктамады. Урал турында да шундый матур шигырьләр яза белде, ул туган ил горизонтларының гаять киң икәнен күрсәтте. Шигырьләре табигый, ясалма түгел (*мисаллар китерә. –* ***Л.Л.***). Йә, кайсыгыз болай әйтә белде?

Икенче ягы, бик оригиналь ягы шунда аның иҗатының – шигырьләре хатын-кызларга гына хас нәфислек, нечкәлек, эчкерсезлек белән аерылып тора (*мисаллар китерә. –* ***Л.Л.***).

Бу шигырьләр чын шигърият, чын художество әсәрләре:

*Күкрәкләре шыткан үсмер кызлар*
*Атлый тәүге яшьлек язына.*

Мин Салисәгә моннан егерме еллар элек өметемне баглаган идем. Аклады ул минем өметләрне. Салисәнең рәссамлык сәләте дә бар. Бу инде нур өстенә нур. Беренче җыентыгын (*«Уралым» (1979). –* ***Л.Л.***) бик яратып, ләззәтләнеп укыдым. Башка язучылардан да җылы фикерләр ишетеп торам. Бу да әһәмияткә ия. Шагыйрә иҗатын дәвам итә. Ул безнең арада булырга тиеш!

Берләшмә утырышына кабат әйләнеп кайтыйк:

«Әйе, түрдә Нури ага Арсланов утыра. Ап-ак чәчле, таза гәүдәле, нык бәдәнле аксакал шагыйрь. Ул үзенең иҗат лабораториясе турында, Барлас абый Камалов әйтмешли, иҗат пәрдәсен күтәрә төшеп, салмак кына сөйли башлады.

Шагыйрь Зөлфәт Нури агага мондый сорау бирде:

– Нури ага, сез ничек уйлыйсыз, язмый торган чагында, язылмый торган вакытта шагыйрь нишли?

Нури ага Арсланов җавабы:

– Шагыйрь кайчан язамы? Шигырь язмаган, язылмаган вакытта, минемчә, ул шигырь турында уйлап йөри.



Күңеленнән уйлый. Күңелендә шигырь туса, ул аны ак кәгазьгә төшереп куя. Мәсәлән, мин гел шулай итәм. Шагыйрь язасы шигырен үзе эзләми. Шигырь аны үзе таба.

Рәфыйк Юнысов белән Рашат Низамиев сорауларына да тәфсилле җавап биргәннән соң, Нури ага яшь иҗатчыларга киңәш итеп болай диде:

– Язган әсәрләрегезне матбугатта чыгарырга ашыкмагыз. Яздыгызмы, аны бер читкә куегыз – папкагамы, тартмагамы, кая да булса кыстырыгыз. Бер атнадан, булдыра алсагыз, бер айдан язмагызны кабат алып укып карагыз. Күрерсез – шигырь әле пешеп җитмәгән. Төзәтәсез, янә язасыз. Бер шигырь яздым да – эше бетте түгел, башкасын язуны дәвам итегез...»

Яшь иҗатчылар, дидем. Шулай дигәч, Нури аганың шәкертләрен (үзем белгәннәрен) хәтердән барлый башладым: Рәшит Әхмәтҗанов, Зөлфәт, Рифгать Закиров, Эдуард Мостафин...

Эдуард Мостафинга Язучылар берлегенә керү өчен Нури аганың тәкъдимнамә язуын да хәтерлим әле. Ул гына да түгел...

1989 елның җәй аенда (күңе истә калмаган) Эдуард Мостафин Татарстан Язучылар берлегенә (*ул вакытта СССР Язучылар берлеге. –* ***Л.Л.***) әгъза итеп кабул ителде. Шул уңайдан Эдуард абзыйның Язучылар йорты бакчасында җәһәт кенә табын хәстәрләгәне һәм ул табынның түрендә Нури аганың аксакалларча киңәшләр биреп утырганы бүген дә күз алдымда тора.

Үзара аралашкан чакларыбызда, яныбызда шәкерте Зөлфәт булса-булмаса да, Нури ага аны гел мактап телгә алыр иде. Җитмешенче еллар ахырында:

– Нури Арслановның шигърияттә икенче сулышы ачылды. Аның шәп шигырьләр язуында Зөлфәтләрнең, Мөдәррис Әгъләмовларның йогынтысы сизелә! – дигән сүзләр тел өстендә бик озак йөрде.

Шундый талантлы шәкертләрең булуы, аларның сине хөрмәт итүе, иҗатыңа уңай йогынты ясавы – остаз өчен зур бәхеттер ул, зур сөенечтер...

Мин бахырыгыз Әдәби фонд директоры булып эшләгән елларда (1986-1988), шулай ук «Салават күпере» журналханәсендә хезмәт иткән дәвердә дә Нури ага белән, бик еш ук булмаса да, вакыт-вакыт очрашып тордык. Бераз гына пирәшләп алгалаган чаклар да булмады түгел, булды.

Шундый көннәрнең берсендә Нури ага минем кулга бер конверт тоттырды. Тышына «Азат хатын» журналы (хәзерге «Сөембикә») логотибы төшерелгән ул конвертка «Язучылар Союзына, Арсланов Нури васыяте» дип язылган иде.

– Ләбиб, сиңа ышанып тапшырам. Бу – минем васыятем. Мин үлгәч ачарсыз. Конверт эчендә фоторәсемем дә бар. Кабер ташына беркетү өчен кирәге-мазары чыкса, дим. Сейфыңа куй, яме!

– Ярар, Нури абый, – дим.

– Ә, юк, туктале, – ди Нури ага. – Васыять кәгазенә мөһереңне сугып, берочтан имзаңны да сырла инде. Булгач-булгач, чын документ булсын!

Шуннан соң шул, дигәндәй... 1988 елның июлендә мин кабат «Яшь ленинчы» (хәзерге «Сабантуй») газетасы редакциясендә эшли башладым. Бер елдан соң Татарстан телевидениесенә, аннары ярты елдан «Салават күпере» журналханәсенә (журнал дөньяга чыга башламаган иде әле) эшкә күчтем. Әдәби фонд директоры булып миннән соң Шаһинур Мостафин эшли башлаган иде. Нури ага Шаһинур Сафа улы эшләгән чакта вафат булды.

Аксакалыбызны 1991 елның 12 апрелендә Яңа бистә зиратында җирләдек. Нури ага үлгән көнне кызы Зөбәрҗәт мондый төш күргән: имеш, төшендә мәрхүмә Әминә апа (*Әминә Бикчәнтәева – күренекле балалар шагыйрәсе, Нури Арслановның беренче хатыны, аларның уртак балалары – Зөбәрҗәт белән Илдар. –* ***Л.Л.***) әйтә икән:

– Бүген минем яныма ятарга үз мендәре белән бер ир-ат киләчәк!

Ышансаң ышан, ышанмасаң юк, дигәндәй... Нури ага Арсланов җәсәде элекке хатыны Әминә Бикчәнтәева кабере янәшәсендә җирләнде.

Әй васыятькә килсәк...

Аның бер нөсхәсен (*бәлки яңартылганын?! –* ***Л.Л.***) Нури ага Шаһинур Мостафинга да тапшырган булган икән. Миңа бирелгәне исә, Нури ага фотосурәте белән бергә, хәзерге көндә үземдә саклана. Урысча язылган васыятьнең татарчасын сезнең игътибарга тәкъдим итәргә булдым:

«Арсланов Нури Газиз улы васыяте

Вафатымнан соң минем оямны туздырмаска – хатыным Клавдия Тихоновна Арсланова үлгәнчегә тиклем милекне бүлешмәскә. Бары тик ул вафат булганнан соң гына минем варисларым: улым Илдар Нури улы Арсланов белән кызым Зөбәрҗәт Нури кызы Арсланова милкемне бүлешә ала.

Милеккә керә:

1. Җиде китап шкафы һәм җиде китап киштәсе. Якынча бер мең биш йөз китап.

2. Келәмнәр: берсе 2х3 метр, икесе – 2х1,5 һәм җәмгысы 10 метр булган идән келәме (дорожка).

3. Болгар серванты (чәй һәм өстәл кирәк-яраклары белән бергә).

4. Электр җиһазлары: «Таурас» телевизоры, «Регонда» радиоалгычы, «Нейва» транзисторы, «Спидола-230», «Свияга» һәм «Мир» суыткычлары.

5. Көзгеле болгар шифоньеры, безнең илдә эшләнгән өч бүлемтекле шифоньер, шудырмалы болгар өстәле.

6. Алтышар мендәрле ике диван.

7. «Эрико» маркалы язу машинкасы.

8. Архивымда: кульъязмалар, хатлар, котлау адресатлары, һ.б.

Югарыда саналган әйберләр хатыным үлгәнчегә кадәр аның карамагында булырга тиеш. Хатыным исә, аларны



файдаланган чакта, һәрберсенә сакчыл караштa булырга тиеш: сатарга һәм чит-ятларга өләшергә рөхсәтем юк.

Мин үлгәннән соң киемнәремне – кәчтүм, пәлтә, берничә куртка, күлмәкләр, аерым чалбарларны, аяк киемнәрен һәм шуның ише әйберләрне балаларыма – Илдар белән Зөбәрҗәткә хатыным тапшырырга тиеш.

Акча милке саклык кенәгәләрендә саклана.

Барлык хатын-кыз кием-салымы, аяк киемнәре, урынҗир кирәк-яраклары, караватһәм «Зингер» тегү машинасы Клавдия Тихоновна Арсланова милке санала.

Балаларыма булышу нисбәтеннән Язучылар берлеге исеменнән минем васыятемә таянып эш йөртү өчен Миңнуллин Фәрваз Мөхәммәдулла улына үтенечемне белдерер идем: ул минем балаларымны һәм гаиләмне яхшы белә. Минем әдәби мирасым буенча комиссия төзелә-нитә калса, аның составына шагыйрь Рәшит Хәниф улы Әхмәтҗановны кертүегезне сорыйм.

Мине искә алу мәҗлесен бары бер мәртәбә – мине җирләгән көнне генә уздырырга.

Элек язылган васыятемне яраксыз санарга.

1943 елдан (*«Татар әдипләре» китабында, нишләптер, «1946» дип күрсәтелгән. –* ***Л.Л.***) СССР Язучылар берлеге әгъзасы, сугыш һәм хезмәт ветераны Нури Арсланов. Казан, 1987 елның 10 августы».


Татарстан Язучылар
Союзы идарәсенә
Союз әгъзасы Нури Арслановтан

Гариза

Май, июнь айларында Бөек Ленин һәм Себернең Павлодар шәһәрендә Советлар власте урнашуы турында яшьләр-балалар өчен 250-300 юллар чамасы поэма яздым. Материалым бар, поэма черновой рәвештә язылган – эшлисе бар. Шуны җиренә җиткереп эшләр өчен Павлодар шәһәренә барып кайтырга кирәк. Бер айга иҗад командировкасы сорыйм. Әсәрне июль аенда китереп тапшырам. Әсәрнең «Романтика» дип атала.

Казан 7/IV 69.

Әлеге васыять астына мөһер сугып, мин урысча болай дип язып куйганмын: Подпись поэта Арсланова Нури Газизовича заверяю: директор Татарского отделения Литфонда СССР Л. Л. Леронов. Подпись. 27 августа 1987 года».

Миндә Нури Арслановның 1969 елның 7 апрелендә Татарстан Язучылар берлеге идарәсенә язган гаризасы да саклана:

«Татарстан Язучылары Союзы идарәсенә Союз әгъзасы Нури Арслановтан

гариза.

Май, июнь айларында Бөек Ленин һәм Себернең Павлодар (*татарлар һәм казакълар атап йөрткән борынгы исеме – Кәрәкәү. –* ***Л.Л.***) шәһәрендә Советлар власте урнашуы турында яшьләр-балалар өчен 250-300 юллар чамасы поэма яздым. Материалым бар, поэма черновой рәвештә язылган – эшлисе бар. Шуны җиренә җиткереп эшләр өчен Павлодар шәһәренә барып кайтырга кирәк. Бер айга иҗад (*автор орфографиясе сакланды. –* ***Л.Л.***) командировкасы сорыйм (*бу җөмлә астына кызыл карандаш белән сызылган. Иң өскә сул якка кемдер кызыл һәм күк карандаш белән «20 дней тв. командировки» дип язып куйган. –* ***Л.Л.***) командировкасы сорыйм. Әсәрне июль аенда китереп тапшырам. Әсәрнең (*әсәрем, дип укырга кирәктер. –* ***Л.Л.***) «Романтика» дип атала. Казан. 7 апрель, 1969 ел. Имза».

«Романтика» поэмасы 1971 елда әдипнең чираттагы яңа басмасында – «Моңсар» китабында үзенең лаеклы урынын ала...

Күптән түгел генә Казанның бер сәүдә-күңел ачу үзәгендә Нури Арслановның улы Илдар абыйны (ул бүгенге көндә танылган музыкант) очраттым. Сүз иярә сүз чыгып, Нури аганың әлеге васыятен искә төшердем. «Клавдия Тихоновна вафатыннан соң, әти васыятенә нисбәтле мәрәкәләнүләр булып алды инде, – диде Илдар абый. – Әти яшәгән фатирга Клавдия Тихоновнаның унҗиде яшьлек оныгы ия булды. Без судлашып йөрмәскә булдык...»

Без ныклап танышкан чакта Нури агага – 75, миңа исә 25 яшь булган икән. Кем әйтмешли, илле ел аерма! Ярый, мин, ятим үскән кеше буларак, әти җылысы эзләп гел өлкән агайларга тартылдым, ә менә Нури ага нигә, ни сәбәпле мине – оныгы яшендәге егетне үтә якын, үз иткән – бу миңа бүгенге көнгәчә сер булып кала килә. Бәлки... бәлки...

*12 август, 2017 ел*

Фәния Хуҗахмәт



# ИРАН – Арийлар иле

Үткән көз телевизордан Русия Федераль Җыенының Федерация Советы рәисе Валентина Матвиенконың, башына матур яулык ябып, озын, килешле күлмәктән Иранда йөргәнен күрсәттеләр. Сөбханаллаһ, дими чарам калмады. Югары дәрәҗәдәге сөйләшүләр Русия исеменнән барса да, Иран өчен Русия ул – татар халкы, мөселманнар да әле. Рәхмәт Валентинага, ул бик матур һәм акыллы иде. Сокландым да, кызыктым да. Минем дә Иранга барасым килә башлады. Ярый әле көнләшмәдем. Аллаһы Тәгалә: «Көнләшкәнгә түгел, кызыкканга бирермен», – ди. Бу кичерешләремне бөтенләй оныткан идем инде, ярты ел да үтмәде, Уфадагы дуслар шылтырата: «Әйдә Иранга», – диләр. Шулай итеп, унике ханым, унысы Уфадан, Казаннан без икәү – Татарстанның халык артисты Гөлзада ханым Сафиуллина һәм мин. Уфаның «Ихлас» мәчете имам-хатыйбы Мөхәммәт хәзрәт Галләм җитәкчелегендә ундүрт көн Иранда йөреп, күреп, аңлап, рухи азык алып, күңелебез яктырып, җан рәхәте тоеп, сөенешеп кайттык.

## ХАТЫН-КЫЗЛАРНЫ ЗУРЛЫЙЛАР

Мин Иранны бер дә белмәгәнмен икән, үзем өчен бөтенләй үзгә, кызыклы дөнья ачтым. Безгә бит ул, аңламаганнарга, белмәгәннәргә, кара чадра, башыннан аягына кадәр бөркәнчек ябынып йөрүче, бернинди хокукы булмаган, барысы бер төрле бик күп хатын-кызлар иле булып тоела иде.

Вакытыбызның күп өлешен Иранның башкаласы Тәһран шәһәреннән ерак булмаган Кум шәһәрендә үткәрдек. Безне Кумдагы Әл-Мостафа





кызлар университетының Асхар-Таха филиалында бик зурлап кунак иттеләр. Кунак дигәч тә, ашау-эчү бөтенләй күздә тотылмый. Алар булдыра алган кадәр күбрәк күрсәтергә, күбрәк сөйләргә, ә без исә күбрәк белергә, өйрәнергә, аңларга тырыштык.

Иран ул – Көнбатыш Азиядә урнашкан, кырык җиде миллион кешесе булган «Арийлар иле». Мин бит бу сүзне «һинд-аурупа телләрендә сөйләшүче халыклар» дип белә идем, ә ул «тулы хокуклы кешеләр» дигәнне аңлата. Иран – тулы хокуклы кешеләр иле. Алар менә шуны бар булмышлары – җаннары, тәннәре белән тоеп яши икән. Әгәр дә безнең күңел түребездә «Мин – татар» дигән якты бер хис булса, дөньялар бөтенләй икенче төрле булыр иде. Без үз илебезне, туган җиребезне яратмыйбыз икән бит. Хәтта Ватанны ярата белмибез. Хәдисләрдә дә: «Аллаһны яратмаган – үзен яратмас», – диелгән.

Ике миллион кеше яши торган Кум шәһәре – Иранның дини мәркәзе. Монда бик күп уку йортлары урнашкан. Аларның һәрберсе аерым бер шәһәрчекне хәтерләтә. Әл-Мостафа кызлар университетындагы китапханәләрне, заманча уку әсбапларын, техниканы күреп исебез китте. Бүгенге көндә Кумда илле меңнән артык егет, егерме меңләп хатын-кыз белем ала. Чит илдән килгән шәкертләрне дә бик теләп, бушлай укыталар, бирегә туксан илдән укырга киләләр. Бакуда консерватория тәмамлап, монда укучыларны да, бер елга тел өйрәнергә килгән кызларны да күрдек.

Тәһранда ун мең хатын-кыз укый торган, Иранда гына түгел, бөтен Якын Көнчыгышта данлыклы Әл-Зөһрә-Фатыйма исемендәге университет 1964 елда туксан студент белән, инглиз теле, хисапчылар һәм психологлар укыту белән башланып киткән. Бүген монда фәлсәфә, калям, фикъһ, ысул, хәдис, тарих кына укытып калмыйлар, политология, халыкара хокук, ислам психологиясен, ислам фәлсәфәсен алга чыгарганнар. Шуларны өйрәнәләр, фәнни хезмәтләр язалар, гыйльми эшләр

**Аятулла – «Аллаһның могҗизасы», «Аллаһ тамгалаган» дигән сүз һәм бик зур дәрәҗә. Ислам кануннарын, фикъһне (шәригать хөкемнәрен) яхшы белүе, зирәклеге, үрнәк тормышы белән мөселманнар һәм мөҗтәһидләр арасында танылган кеше генә андый бөек исемнәргә лаек була. Бу исем нәселдән нәселгә күчми, рәсми рәвештә дә билгеләнми.**




башкаралар, хезмәтләрен төрле телләргә тәрҗемә итеп тараталар.

Беренче гаҗәпләнгәнем, кызларны укытуга игътибарның зурлыгы булса, икенчесе – хатын-кызга хөрмәт. Уку йортларына, төрле биналарга хатын-кыз исемен биреп мәңгеләштерәләр. Иран-Гыйрак сугышында батырларча һәлак булган шәфкать туташының исемен дә университет эчендәге ашханәгә биргәннәр. Әл-Мостафа университетыннан безгә лекция сөйләргә килгән профессор да – Әхмәдия – үзенең фәнни хезмәтләренең җитәкчесе хатыны булуын, бик күп укырга мәҗбүр итүен сөйләп көлдерде.

Дөньядагы глобальләшү процессы бернәрсәне дә аямый, сытып, изеп, юк итеп бара. Ул иң йогышлы чир кебек бөтен өлкәләргә дә үтеп керә. Тарихыңны, мәдәниятеңне, мәгърифәтеңне юкка чыгара. Тулы бер комплекс белән алып барыла. Шунысы аяныч, бу бетерү «төзү – төзүче» дип атала һәм бетәргә тиешле халыкның, милләтнең үз кулы белән башкарыла.

Без үскәндә дөнья матур, дөнья киң иде. Бүген инде ул, дөньяга чыгып күз салсаң, ярыйсы ук тар һәм бик пычрак икән. Ә бит Аллаһы Тәгалә бик матур һәм матурлыкны сөя. Ул Үзе үк әнә шул матурлыкны саклауны, алар аша башкаларга да саклану юлларын иранлыларга күрсәткән. Мондый тискәре күренешләргә, глобальләшү процессына, исламга каршы кешеләргә, саташкан, адашканнарга, адаштырырга тырышканнарга бары тик югары дини һәм дөньяви белемгә ия яшь кешеләрне үстереп, тәрбияләп кенә ирешеп була.

## КИТАП КУЛЬТЫ

Иранның китап иле, бик күп башлангычларның туган җире, чишмә башы икәнен белә идем. Чын мәгънәсендә китап культы икән монда. Китапка табыналар. Иң элек алып барган җирләре дә ислам фәннәренең компьютер тикшеренүләре үзәге булды. Ул инде чирек гасыр дәвамында эшли, берничә мең кульязма һәм сирәк китапны, Коръән, хәдис, догалар буенча кулланырга уңайлы дәрәҗәгә җиткереп, дискларга күчергәннәр. Коръәннең бөтен төрен, бөтен тәфсирләрне, аңлатмаларны ике дискетка туплаганнар. Аларны бу зур эшкә Америкада Коръән яндыру мәҗбүр иткән. Коръәнне өйрәнү буенча бу үзәк мөселман дөньясында икенче урында тора. Аның егерме алты илдә бүлекчәләре оешкан. Ислам диненең казанышларын заманча ысуллар белән халыкка җиткерү өстендә күп эшлиләр.

Кум шәһәрендә аятулла Мараши Нәҗәфинең зур китапханәсе бар. 1989 елда мәрхүм булган аятулла туксан алты ел гомер кичергән. Яшьтән үк ул мөселманнарның зиһен ядкәре булган борынгы кульязмаларны чит ил кешеләреннән сатып алып, Аурупага алып китүләренә бик борчылган. Укырга, өйрәнергә, сакларга түгел, юк итәргә, юкка чыгарырга икәнен җаны белән сизеп, бик борчылган. Шуның өчен ул, дөге фабрикасында гади эшче булса да, китаплар җыю эшенә тотынган. Бар булганын шуңа багышлаган. Кайбер китаплар янында кызыклы аңлатмалар бар. Мараши бу китапны кем өчендер



ике ел фарыз уразаны тоткан акчага сатып алган. Кем өчендер намаз укыган, кем өчендер Коръән укыган. Китаплар шулай берәмтекләп һәм бик авырлык белән тупланган. Аның туйганчы ашамаган көннәре күп булган, бар булган керемен борынгы дини китаплар җыюга тоткан.

Бу урында китап җене кагылган Альберт Фәтхине искә алу тиештер. Ул да Мараши белән танышкан булгандыр кебек. Китап, кульязмалар өчен яна-яна, иртәрәк китте. Шул ук Әбрар Кәримуллин, Миркасыйм Госманов, Марсель Әхмәтҗанов, яшь галимнәребез Раиф Мәрданов, Ирек Һадиевлар бер сирәк кульязма өчен өч көн ач торырга да ризадыр. Бу фондта безнең китаплар да бар, диделәр. Хәтта гарәпләрнең дә борынгы язма әсәрләре, юкка чыккан, югалган мирасларының монда саклануын әйттеләр.

Мараши саклауханәсендә алтмыш мең данә кульязма исәпләнә. Ул, мөселман кульязма мирасын саклау буенча Истанбул һәм Каһирәдән бераз гына калышып, дөньяда өченче урында тора. Шунысы кызык: аятулла Мараши – милләте буенча төрки, бәлки әле татардыр да. Ул хикмәтле кеше укый-яза белмәгән. Гап-гади, укымаган, эшче Мараши аятулла булып киткән. Мин исә ислам революциясе лидеры Хомәйни һәм егерме томлык Коръән тәфсире язган, Коръән гыйлемендә шөһрәт алган, иң абруйлы белгеч Мәкәрим Ширази кебек шәхесләр генә аятулла була ала, дип уйлый идем.

Бүген китапханәне аятулла Марашиның җитмеш алты яшьлек улы Мәхмүд җитәкли. Хәзер инде ул китапханә генә түгел, зур фәнни үзәк булып тора. Монда кульязмалар фонды микрофильм рәвешенә китерелә, заманча технология буенча эшкәртелә, борынгы китаплар яңартыла, карантинга ябыла, дәвалана, төрле химик реагентлар ярдәмендә ныгытыла, тергезелә. Китапханә бик зур һәм анда биш йөзләп ир-ат эшли. Борынгы мираска, китапка алар җан өрә. Безне бер бүлектән икенчесенә йөрттеләр, һәр бүлекнең җитәкчесе үз эше турында яратып сөйләде. Татар кульязма мирасының бик бай булуын, әлегә кадәр китапларыбызның тәмуг газаплары кичерүен искәрттеләр. Бик күп урыннарга Мараши Нәҗәвинең рәсемнәрен элгәннәр. Бик матур кеше булган, елмаеп, канәгать булып карап тора.

Кумда да, Иранның башка шәһәрләрендә дә китап кибетләре күп. Аларны карыйлар һәм сатып алалар. Китаплар матур, аңламасаң, укымасаң да, кулга тотып кына карау да рәхәт. Иранга әле китаптан биздерү сәясәте килеп җитмәгән. Халыкта борынгы затлылык, ислам әхлагының барлыгы, мәдәниятлелек үзен гел сиздереп тора.

Соңгы көнне, аерылышу сәгатьләре якынлашканда җитәкчебез Хөҗҗәтидән сорадым:

– Сез безне бик зурлап, хөрмәтләп кунак иттегез, без ничек түләргә тиеш булабыз соң?

Ул бик акыллы кеше, уйга калды:

– Сез бездән яхшылык күрдегезме?

– Әйе!

– Сез Иранда матурлык күрдегезме?

– Әйе!

– Гомерегез буена яхшылык эшләгез, матурлык таратыгыз, – диде.



**Иранда дөнья кумыйлар, дөнья да аларны кумый. Алтын-көмешкә дә чуммаганнар, кием дә килешле генә. Ирләр бик матур, кара һәм ак чалма кияләр. Бер-берсен тикшермиләр, динне ничек тоту да һәркемнең үз эше.**



Энҗе Басыйрова

# АНЫҢ ӨЧЕН БАР ДӨНЬЯ АЧЫК

**Һиндстан диюгә, җыр-биюле, кайнар мәхәббәтле, хис-кичерешләрдән, күз яшьләреннән торган фильмнар күз алдына килә. Анда, гадәттә, ярлы егет бай кызга яки, киресенчә, берәр хәлле әфәнденең улы фәкыйрь тормышлы туташка гашыйк була да, бөтен вакыйгалар шул тирәдә куера. Ике яшь йөрәк язмыш сынаулары аша гына кавыша ала. Республиканың «Дуслык» йортында эшләп килгән Татарстан белән Һиндстан арасындагы мәдәни элемтәне үстерү үзәге җитәкчесе Иштиак Ахмад Гилькар белән сөйләшкәч тә, һинд егете белән урыс кызы мәхәббәте турында кино төшерерлек тарих ишеттем.**



*Иштиак*



*Ольга*

Тумышы белән Төньяк Һиндстанның Кашмир штатындагы Шринагар шәһәреннән ул. Зыялы, укымышлы гаиләдә тәрбияләнгән. Үзләрендәге Британия мәктәбендә унике сыйныф тәмамлагач, университетта биохимик һөнәрен үзләштерә. Кечкенәдән табиб булырга хыялланган, химия фәненә гашыйк Иштиак укуын шул юнәлештә Алманиядә дәвам итәргә тели. Ләкин моның өчен алман телен камил белү генә аз була, ә бакалавр гыйлеме җитми. Вәкиллектә эшләгән әтисе улына Русиягә китәргә тәкъдим итә. Егет дөнья картасын ачып карый да, «Русиядән Алманиягә ерак калмый икән бит», дип, безнең илгә килергә тәвәккәлли. Советлар Союзы космонавтларының галәмгә беренче очуы, нинди салкын Себердә дә нефть вышкаларының кара алтын суыруы, хәрби кораблар, су асты көймәләре сафка басу, самолетлар төзелү – болар барысы да Иштиакның аңында СССР – бөек инженерлар дәүләте, дигән уй тудыра. Әтисе әле: «Аларның бит «КамАЗ» машиналары бар. Америкадан кала тагын кайсы ил шундый автомобиль җитештерә», – дип, җилкенгән йөрәкне тагын да дәртләндереп җибәрә. Һинд егете дә бездә укып инженер булырга карар кыла. Горбачев фамилиясеннән башка бер авыз сүз урысча белмәгән егетне иң элек Кишинев шәһәренә телне үзләштерергә җибәрәләр. Аннары Луганск машина төзү институтын кызыл дипломга тәмамлый да, зур планнар белән үз ягына кайтып китә. Ә

язмыш исә үзенчә хәл итә: аны барыбер медицина өлкәсенә юнәлдерә. Озак та узмый, алман телендә иркен аралашкан яшь белгечне медицина җиһазлары белән сату итә торган оешмага эшкә – Русиядәге филиалларның берсенә кодалыйлар. Шулай итеп, 1994 елда Иштиак Ахмад Гилькар Казанга аяк баса. «Мин бирегә килеп төшкәндә сентябрь ае, яңгыр ява, юеш, пычрак, тирә-юнь бик соры иде. Мәскәүнең Шереметьево аэропорты да уңай хис калдырмады. Ярый әле, Төньяк Һиндстанда тугач, кыш куркытмый. Һич югы шунысы куандырды. Бездә мондагыга караганда да көчле җилләр дулый», – дип сөйли ул. Биредә урнашуга җиң сызганып эшкә керешә, урыс телен шомарту өчен күп аралаша, радио тыңлый, телевизор карый. Бераз эшлим дә китәм дип килгән егет ул чагында монда озакка тамыр җәячәген башына да китерми әле.

Үзе артыннан ук Казан медицина институтына укырга килгән сеңлесенең ахирәте Ольганы очратуга тынычлыгы югала аның. Өстәвенә, чибәр туташ әнисе кебек үк укытучы, инглиз теле белгече булып чыга. Сөйләшер сүз дә тиз табыла, уртак серләр дә барлыкка килә. Тимерне кызуында сугарга яраткан Иштиак өйләнергә карар кыла һәм сөенечле хәбәрне якыннарына җиткерергә туган ягына ашыга. Ни кызганыч, ике яшь йөрәкне бәхет диңгезендә гиздергән яңалык туганнары өчен генә тамакка утырган кылчыкка әйләнә. Ничек инде Аурупа йогынтысы үтеп кергән мәмләкәт гражданына өйләнә? Көнбатышта гаилә кыйммәтләре аяк астына салып таптала, Һиндстандагы кебек иң биек югарылыкта тормый, димәк, нәселебезгә хәрәм керә, ди гаилә киңәшмәсенә җыелган туган-тумача. «Бездә кәләшне җентекләп сайлыйлар, очраштык, яратыштык һәм кавыштык дигән алгоритм бөтенләй юк, – ди Иштиак. – Бер танышларым, кызның нәселендә шикәр чирле кешеләр булуын белгәч, улларын аңа өйләндерүдән баш тартты. Гаилә – дипломатик союз. Һиндстанда исә ул ишле, зур. Гаилә төшенчәсенә әтиәни генә түгел, бөтен икенче буын туганнар да, өченчеләре дә, калганнар да керә. Килен барысы белән дә уртак тел табып, матур мөгамәлә кора белергә тиеш». Ольга турында ишеткәч, әтисе канәгатьсезлек белдерсә дә, әнисе улы ягына авыша: үзе хәл итсен, аңа яшисе бит, ди. Ольганың инглиз теле укытучысы, ягъни гуманлы һөнәр иясе булуы да каршылыкның уңай хәл ителүендә зур роль уйный. Әлбәттә, Ольгага да мондый карарга килү җиңел булмагандыр. Сөйгәне аңа башта ук: «Минем туган җирем синең өчен дә Ватанга әйләнергә тиеш. Әгәр безгә анда китәргә туры килсә, син ризамы», – дип коры тора. Йөрәге мәхәббәттән илереп типкән кызга буйсынмый чара калмый. Туйлары Казанда тыйнак кына уза. Ләкин Иштиак әфәнденең йөрәге түрендә киләчәктә үз ягында бөтен кан-



*Уллары Фаисаль*

кардәшләрен, дус-ишләрен җыеп, зурлап мәҗлес үткәрү теләге әле дә яши.

Ике ил мәдәниятенең төрлелеге сукыр күзгә дә күренүгә карамастан, бу гаиләдә шактый мәсьәләләр күптән уртаклык тапкан. Ольга һиндларның милли ризыкларын яратып пешерә. Ире әйтүенчә, хәзер инде аларга караганда да тәмләткечләрне күп сала. Һиндстанда мондагы ашларны әзерләп, туганнарын сокландыра. Берсендә шулай, голубцы ясап, каенатасын шаккатырган. Ул итне кәбестәгә ничек төрә алдың, дип

**Ике яшь йөрәкне бәхет диңгезендә гиздергән яңалык туганнары өчен генә тамакка утырган кылчыкка әйләнә. Ничек инде Аурупа йогынтысы үтеп кергән мәмләкәт гражданына өйләнә? Көнбатышта гаилә кыйммәтләре аяк астына салып таптала, Һиндстандагы кебек иң биек югарылыкта тормый, димәк, нәселебезгә хәрәм керә, ди гаилә киңәшмәсенә җыелган туган-тумача.**

шактый аптырап йөргән. «Русиядә тел белү – проблема һәм бу хафага сала, – ди Иштиак Ахмад Гилькар. – Монда электән инглизчәгә игътибар булмаган, аны хәзер генә ныклап өйрәнәләр. Без исә туган телебезне дә, инглиз телен дә тигез дәрәҗәдә беләбез». Өйдә дә инглизчә аралашалар. Аңлыйсыңмы, юкмы, гаилә башлыгы әйтүенчә, анысы берәүне дә борчымый. Син инглизчә камил сөйләшергә тиеш.

Иштиак белән Ольга ике бала тәрбияләп үстергән. Уллары Фаисаль Русия гадел хөкем (правосудие) академиясендә юрист һөнәрен үзләштерә. Кызлары София мәктәптә белем ала, журналист булырга хыяллана. Иштиак үзе дәвалау оешмаларын медицина җиһазлары белән тәэмин итү өлкәсендә эшли – мондагы филиалны җитәкли. «Гаиләдә дүртебез дә төрле, – ди героем. – Улым бик тыйнак. Бергә җыелгач, әңгәмә юриспруденциягә кагылышлы булса гына кушыла, юк икән, авызыннан бер сүз тартып алам димә. Күрәсең, миңа охшаган. Үзем дә өйдә күбрәк башкалар сөйләгәнне тыңлыйм. Әтинеке шикелле холкым кырысрак, ул да салкын кеше, назга да, мактауга да саран. Тәртип яратам. Ниндидер уңышка ирешү өчен теләк булу гына җитми, дисциплина да кирәк. Әйтик, көн саен иртән биштә торып, сәгать ярым дәвамында йога күнекмәләре ясау егерме дүрт сәгатькә җитәрлек дәрт-дәрман бирә». Ике милләт, төрле мәдәният вәкиленең бергә кавышуын язмышка сылтый. «Ирнең дә, хатынның да геннары төрле, – ди ул. – Гомумән, кеше шәхес булып бала вакыттан ук тәрбияләнә. Шуңа да карамастан, мәхәббәттә, бер-береңне аңлап яшәргә, бер дулкын ешлыгында тибрәлергә кирәк. Гаиләдә мөнәсәбәт ачыклау – эш түгел. Без үскәндә әти-әни балалар алдында бер-берсенә канәгатьсезлек сүзе әйтми иде, бер-берсен битәрләгәннәрен ишетмәдек. Шул чагында гына авырлыклар чүпкә әйләнә».

Героемда тагын шул сыйфаты сокландырды: аның өчен бар дөнья ачык, илләр арасында чикләр юк төсле. Үзе дә, дөнья шултикле тарайды, ди. Казанда укып киткән бертуган сеңлесе хәзер Калифорниядә табибә булып эшли, икенчесе, Франциядә гыйлем эстәп кайтып, үзләрендә фәнни лабораторияне җитәкли, микробиолог. Абыйсы – электрон инженер. Икетуганы Малайзиядә электрон җиһазлар буенча эре компаниянең җитәкчесе вазифасын башкара, тагын берсе Бәһрәйнда күперләр төзи. «Без – барыбыз да профессионаллар. Аерма шунда гына: башкаларның төпле хезмәте бар, ә мин – малтабар. Гәрчә әти үзе кебек түрә итеп күрергә теләгән иде, әмма ирекле йөзәргә яратуым буйсынырга ирек бирми», – ди Иштиак әфәнде. Эшкуарлыктан тыш, әйткәнемчә, әлеге үзәк эшчәнлеген кайгырта. Һиндстаннан безгә ешрак студентлар килә һәм күбесе медицина университетында укый, барысын бергә санасаң, мең кешегә җыела икән. «Вәкиллек каршындагы әлеге үзәкне Жанна Даниленко исемле ханым ачты. Ул анда һинд биюләрен укытты. Моннан җиде ел элек, кияүгә чыгып, гаилә мәшәкатьләре белән иҗтимагый эшкә өлгерми башлагач, идарәне миңа тапшырды. Хәзерге вакытта алты-җиде бию төркемебез бар, Якшәмбе мәктәбе эшли, бәйрәмнәрдә, этник чараларда катнашабыз. Ике елга бер мәртәбә безгә Һиндстан вәкиле килә. Бу үзәкне элемтә чарасы дип атыйм, чөнки ике дәүләт арасын тоташтырып торабыз», – ди әңгәмәдәшем. Бу эшен дә ул яратып, чын күңелдән башкара. Чөнки «Дуслык» йортына килеп, эш бүлмәсендә утырганда уйларына чума, хыялында Һиндстанга кайтып килә. Безнең якка килеп төпләнгәнегезгә үкенмисезме, дигәч: «Үкенү – холкыма һич туры килми. Сагынсам, кайтып китәргә дә күп сорап тормыйм», – дип җавап кайтарса да, кендек каны тамган җир һәрчак йөрәгендә аның. Киләчәктә хәтта туган җирендә югары дәрәҗәдә хезмәт күрсәтә торган клиника ачу турында уйлана, үз халкына ярдәм итү теләге белән яна. «Минем туган штатыма игелек эшлисем килә, – ди. – Ул безне үстерде, укытты, ә без ташлап чыгып киттек. Менә шул бурычны кайтармыйча, җаныма тынычлык тапмам кебек». Казанга, республикабызга да гашыйк ул, татар халкының тырышлыгына, эшчәнлегенә соклана, безнең көйләрдә һинд музыкасының мотивларын эзли, охшашлыклар да таба. Кызының татар телен белүенә дә ихлас куана. «София – Татарстанда туган бала, мондагы телне белергә тиеш», – ди елмаеп.

> «Минем туган штатыма игелек эшлисем килә, – ди. – Ул безне үстерде, укытты, ә без ташлап чыгып киттек. Менә шул бурычны кайтармыйча, җаныма тынычлык тапмам кебек».

idel-tat.ru сайтында дөнья күргән ике язма. Сайтыбызны да укыгыз, дуслар!



Гөлүсә Шиһапова

# БИШӘҮ ЧЫКТЫК ЕРАК ЮЛГА!

Зур сәяхәтләр кечкенә адымнан башлана. Иртәнге кояш, өйдә ятмагыз, офисларыгызны үзегездән, үзегезне тынчу офислардан ял иттерегез, дип әйтә сыман. Ничек инде андый сүзләргә колак салмыйсың? Без, «Идел» журналы редакциясенең биш бөртек кешесе җәйнең матур көнендә шәһәрне бераз үзебездән ял иттерергә булдык. Безне «Сәләт Биләр 2017» форумы көтә иде.

Ерак юлларны яратам. Тәрәзәдәге күренешләр бер-берсен алмаштыруын күзәтеп барасың, йокыңны да туйдырасың, хезмәттәшләреңне дә яхшырак белә башлыйсың. Мин хәзер Радик абыйның балачак тормышы ишеген ярык кына булса да ачып караган кеше. Татфак укучылары иң күп яшәгән авылны да, кайсы җырчы кайда яшәвен дә беләм. Бик күп борчак ашасагыз, интегеп тормастан, нәрсә эшләргә кирәклеген Энҗе Басыйровадан сорый аласыз. Мин, ул сөйләгән картиналарны күз алдыма китереп, әле дә көләм.

Игътибар! Хәзер лирик чигенеш булачак! Юл буенда җил йөгерә. Әле бер машинага килеп бәрелә ул, әле икенчесенә. Ялгыш адашып, «юлдан яза», балакаем. Нинди генә юлга әле! Ике яктан ромашкалар үсеп утырган, каршысына киң колач җәйгән Чулман елгасының бер канатына килеп эләгә җил. Безне Чулман буена нинди җил ташлады дисәгез, нәкъ менә кояшлы чәчәкләр исенә исергән, бал кортларының дирижеры булган җил китерде. Исе, төсе, күзләргә сыеп бетмәс матурлыгы! Гомерең буе шул ромашкалар янында торсаң да, табигатенә сокланып туймассың, билләһи. Табигать кенә шулай сокландыра ала.

Барыр юлда шәмәхә төсле үләннәргә тап булдык. Гөлүсә апа аны «люпин» дип атады. Люпин! Аңлыйсызмы? Гарри Поттердагы профессор Люпин искә төште. Гади генә үләннәрдән дә тылсым исе килә башлады бит, җәмәгать. Кая әле минем тылсымлы таягым?!

Вингардиум Левиоса!

Биләргә беренче баруым булганга, Радик абый, бу бала кая барганын белми калмасын, дигәндәй, бу җирләрнең кыскача тарихын да сөйләп барды. Минем пәриемә бу бик ярап куйды инде. Күз алдымда без үткән юлларда атларның тояк тавышлары, кылыч чыңлавы, ук сызгырулары ишетелә башлады. «Менә нинди тарихи урыннарда йөрим икән», дип китапларның геройлары да күз алдымда пәйда булдылар.

Чишмәләрдән салкын суларны эчеп көч туплаганнан соң, без «Изгеләр тавы»на юл тоттык. Бу чишмә сулары безнең өчен эликсир булды. Ә көч безгә чынлап та бик кирәк иде. Агачлар арасында салынган баскычлар буенча без югары үрмәләдек. Бу сезгә Шаулинь тауларына гына меңү түгел (анда барганым юк, тик миңа шулай тоелды). Аяклар калтырый, сулыш буыла, баш әйләнә икән, димәк сез «Изгеләр тавы»на менеп маташасыз. Хәлкәйләребезне аңларга тырышып карагыз инде.

Биеккә менгән саен, тарих җилләре ныграк исә башлый. Үзең дә

сизмәстән, белгән догаларыңны укый башлысың, ә йолалар яфрак арасыннан пышылдый. Хәзер агач арасыннан Аксак Тимер гаскәре түгел, ә динозаврлар чыгар шикелле. (Кич белән укыган «И грянул гром» әсәренең тәэсире инде бу.) Анда да билгеләнгән юлдан тайпылырга ярамый. Куелган сукмактан читкә китсәң, киләчәкне үзгәртәчәксең. «Эффект бабочки» барлыкка киләчәк. Шундыйрак уйлар белән югары атладык. Үзебез белән алган чишмә сулары эликсирдай уңай тәэсир итте.

Менеп җиткәч, үзегезне чистарындыгыз, дип санагыз. Ә өстә безне «яңа ел» чыршылары, кара ташлар көтә иде. Ташлар тирәсендә җиде тапкыр әйләнергә кирәк икән. Нишлисең, йоласы шул. Ә карасаң, ул ташларны нефтьчеләр куйган булып чыкты.

Монда килгән һәр кеше чишмәнең салкын суларын өстенә коймыйча китми икән. Без дә киммени?! Коенабыз, дигән карарга килдек! «Ничек коенабыз соң?» – дигәч, Ландыш (Заһретдинова), үзе дә чын күңелдән ышанып, җитмәсә, мине дә ышандырып, «Чишенмичә үк өстебезгә коябыз», – ди. Бераз куркуга калсам да, чишмәгә барыр юлда, ничегрәк коенырмын икән, дип планнар корып йөрдем. Ландыш: «Бүген эссе, кояш тиз киптерәчәк», – дип, ә Энҗе: «Безнең бит алыштырырга калын киемнәребез бар», — дигәч, бөтенләй тынычландым инде. Мин генә андый хәлгә калмаган, янәсе.

Әлбәттә! Әлбәттә, коену өчен махсус әзерләнгән урыннар бар иде.

Менә нәрсә, дуслар! Биләргә баргагыз, өстегезгә бер, ммм, ике, юк, өч чиләк су коеп чыгыгыз һәм чинагыз. Соңгысы бик мөһим! Үземнән чыгып әйтәм. Биләрнең салкын суларын өстеңә сипкәннән соң үзеңне Брюс Всемогущий итеп тоясың...



Радик Сабиров

# РКАИЛ ЗӘЙДУЛЛАНЫҢ ЯШЬЛЕГЕНӘ СӘФӘРЕ

Шагыйрь Ркаил Зәйдулла белән Аксубай районындагы Иске Кыязлы авылына мөселман балалары Сабан туена кайтырга сөйләшкән идек. Әмма, «Идел» журналының Алексеевск районында эшләре барлыгын истә тотып, ул безнең белән бер көн алдан юлга кузгалды.

## «ТАТАРЧА ДА ЯХШЫ ПЕЛӘСЕҢ ИКӘН»

Алексеевск районында без Чуаш Майнасы авылындагы бәйрәм чараларында катнаштык. Биредә бу көнне чиркәү ачалар, бер абзыйның туксан яшьлек юбилеен уздыралар, «Уяв» бәйрәм итәләр. Машинадан төшүгә, бу авылның бер абзасы, безнең янга килеп, хәлләрне сораша башлады. Шунда Ркаил ага моның белән... чуаш телендә сөйләшә башламасынмы! Шагыйрьнең татарча да сөйләшүен ишетеп, теге абзый моңа: «Татарча да яхшы пеләсең икән», – әле дип көлдереп куйды. Кызык: танышларым белән рәхәтләнеп татарча сөйләшәбез. Ә бит алар татар теленең килеш кушымчаларын өйрәнеп утырмыйча гына тагын бер тел өйрәнә алган. Зәйдулла да чуаш грамматикасы белән утыргандыр, дип уйламыйм.

## ТАРИХЧЫ ҺӘМ ШАГЫЙРЬ ОЧРАШУЫ

Биредәге чараларны тамаша кылгач, күршедәге Татар Майнасы авылына да кереп чыгарга булдык. Дөресрәге, Ркаил абый үзе теләк белдерде: исеме шактый таныш Рафик Насыйровны күрергә теләген җиткерде. Тарихчы, мәктәп директоры, хәзрәт Рафик абыйны тиз таптык: ураза гаете алдыннан мәчеттә булуына шикләнмәдек. Шулай булып чыкты. Тарихчы тарихчы инде: авыл, төбәк үткәне хакында сөйли башлады. Тарихчы белән шагыйрь бик тиз уртак тел тапты. Мәчеттән соң безнең авылда гына булган «Шәһитләр һәйкәле»н дә күрсәттем кунакларыбызга. Һәйкәл тирәсендә үлән-кычыткан чабып йөрүче Госман бабай да куандырды – шагыйрьне танып алды, рәхәтләнеп аралашты.

## ДҮРТ ЕЛГА ТИҢ ЯРТЫ ЕЛ

Иске Татар Адәмсуы авылының хәләхвәле шәптән түгел. Йортлар сүтелә, нигезләр корый, мәктәптә балалар калмаган… Без бу авылга мәктәпкә керербез дә, бераз авылны әйләнеп чыгарбыз, дип кенә уйлаган идек. Мәктәп янына килеп туктадык. Ә анда… Шагыйрь юл буе «Рәфис Сәгыйров» дип сөйләнгәләп килгән иде, шул үзе көтеп тора безне! Майнадан инде хәбәр иткәннәр икән. Әлбәттә, кочаклашу, күзләрдә бераз яшь, хатирәләр, башкасы – хис-эмоцияләргә тукталып тормыйм.

…Берзаман шулай Зәйдулла Искәдәм (без шулай гына сүләшәбез) мәктәбендә укыта башлагач, моның янына берәү килгән. Баласы елый икән моның, кемдер бишеккә иске язулы китап куярга киңәш иткән (дога китабы дип уйлаганнар). Куйган, әмма бала елаудан туктамаган. Казаннан кеше килде, дигәч, Ркаил абыйга күрсәтергә булган моны. Тегесе – университетта берничә ел иске татар язуын укыган кеше – «җәгърафия китабы бит бу» дип җавап биргән, имеш.

Иске Адәмсуында Казаннан сөрелгән Ркаил Зәйдуллин военрук булып эшләгән. Бераз гына, мәктәп директоры декретка киткәч, тарих һәм җәмгыять белемен дә укытып алган. «Элеккеге военрук балаларга теория генә укыткан, бик сирәк кенә атканнар болар. Патроннар күп, менә дигән тир бар. И рәхәтләнде балалар, дәрес саен диярлек атабыз бит. Ә мин теория-фәләнен бик белеп бетермим шул», – дип искә ала бу елларны шагыйрь.

Спектакль дә куйганнар болар клубта. Юныс Сафиуллинның кайсыдыр әсәрен сәхнәләштергәннәр. Ркаил абый текстны артык хәтерләми, суфлер булуына карамастан, спектакльне үз сүзләре белән дәвам итә икән. Ә финалда, асылда әле спектакль тәмамланмаган була, бу шул ук винтовканы алып атып җибәрә дә, «спектакль тәмам» дип, тамашага нокта куя…

Рәфис Сәгыйров безне авылның йөз еллык мәчетенә дә алып килде. Озак еллар дәвамында бу мәчет бинасында клуб урнашкан иде. Теге спектакль дә шул клуб сәхнәсендә куела. Нигәдер үзгәртеп кору елларында да, аннан соң да мәчет әле клуб буларак эшләп килә. Кире мәчет булып эшли башлавына әле берничә ел гына… Без аның манарасына менеп, бушап калган авылга тагы бер караш ташладык. Ә авыл чыннан да таралып бара. Әлегә ул әнә шул Рәфис сыман, ат кебек эшләүчеләргә, туган төбәге өчен җан аткан кешеләргә генә кирәк кебек. Ул безне үзенең өенә дә алып барды. Баксаң, Ркаил абый бу авылга килеп төшкәч, нәкъ менә аларга чәй эчәргә кергән икән. Шагыйрьне Рәфис абыйның әнисе, туганнары, хатыны үз туганнарыдай каршы алып, янә чәй эчерттеләр…



Гөлүсә Закирова

# «ҮЗ ӨЕМДӘ ҮЗ КӨЕМ»

Күпләребез шәһәргә тамыр җәяргә тырышып азаплана. Шул вакытта авылда калып, нигез фәлсәфәсен тудырган яшьтәшләребез дә бар. Бөтендөнья татар конгрессының алтынчы корылтае кунакларын татар авылларына, анда яшәүче гаиләләргә алып баруларын ишеткәч, алар арбасына без дә утырдык. Менә ул – авылда яшәп, тормышларына рәхмәтле булган Гариповлар гаиләсе. Юлыбыз – Арчага, Мәмсә дигән авылга булачак.



## БАССЕЙН ДА БАР

Фәрит тә, Раилә дә – укытучылар, Арча районы Яңа Кенәр мәктәбендә укыталар. Димәк, авылның зыялы кешеләреннән. Ә авыл зыялылары гомер-гомергә хөрмәтлеләрдән саналган, үрнәк булганнар. Хәтта бер чорда мал-туар асраргa да рөхсәт ителмәгән мөгалимнәргә. Гариповлар да мал-туар асрамый, билгеле. «Мәмсәгә өй салып чыктык та, һәр хатын-кыз шикелле, хатыным йорт тирәсен чәчәккә күмде, – ди гаилә башлыгы. – Баштарак: «Дачниклар, – дип үртәделәр, – кышын чәчәк ашарга җыеналар булыр».

Чәчәкләргә хәзер дә күмелгән алар биләмәләре. Йортларына терәлеп диярлек ике теплица корып куйганнар.



Берсендә җәй башыннан ук кыяр-помидорлар өлгерсә, икенчесендә бассейн җәйрәп ята. Ишегалдында кое, чәчәкләр утырту өчен төрле сурәтләрдә бизәкләп ясалган гөл савытлары, яз башыннан ук самавырдан чәй эчәргә беседкалары тора. Осталар ялламыйлар, уллары Айбулат белән өчәүләп гел нидер кору, иҗат итү белән яналар. Инде менә утын белән ягып керә торган мунча салырга керешкәннәр.

Кышкы озын кичләрдә Раилә сәйләннән чигүне үзләштереп, бер як диварны кул эшләреннән күргәзмә иткән. «Бабайның энесе Гыйлемҗан абый бар иде, – дип сөйләп китә хуҗабикә. – Сугыштан бармакларын өздереп кайткач та музыка уен коралларын кулыннан төшермәгән, скрипкада уйнаган. Баянның уңын сул якка әйләндереп уйнавын әле дә искә алалар. Рәсем ясарга, фотога төшерергә дә оста булган ул.

Автор фотолары

Туганнан-туган сеңлем Эльвира – Мәскәү журналларында рәссам булып эшли. Менә алар белән горурланырга да була», – ди ул тыйнак кына.

Матурлыкны тудыру гына түгел, шунда тәмләп яши белү – үзе бер сәнгать инде.

## УКЫТУЧЫЛАР НӘСЕЛЕ

Гаилә башлыгы Фәрит Гарипов – тумышы белән Арчаның үзеннән. Әнисе Мәүлизә апа гомере буе районның мәгариф идарәсе системасында эшләгәч, укытучылыктан башка һөнәрне күз алдына да китермәгән. Күрше Шурабаш мәктәбендә укытканда, район күләмендә уздырылган җәяүле туризм ярышында Раилә белән танышалар. Ә Раилә – мәктәпне алтын медальгә, уку йортын кызыл дипломга тәмамлаган кыз. Аның остазлары, Казанда кал, дип аспирантурага тәкъдим итә, хәтта Мәгариф министрлыгында эш тә табыштырганнар. «Кызым, синең урының Казанда, кал», – дип әнисе Рузалия апа да кызына киңәшләр биреп, искәртеп тора. Ә кыз исә кырт кисә. Һәм, бөтенесен шаккатырып, авылына кайтып китә. «Минем шәһәрдә тыным кысыла, хәзер дә кешеләрне аралап куясым килә, – ди Раилә. – Менә үз өем, үз көем. Басу, бакчаларына бер карасам, сулышларыма кадәр киңәя».

Раиләнең дә нәсел-нәсәбәсе мөгаллимлек иткән. Әнисе Рузалия апа Насыйбуллина нәселнең педагогик шәҗәрәсен төзегән: гомум укытучылык стажы 235 елдан артып китә. Аның үз әнисе, әтисе, агасы да – Өчиле янәшәсендәге Иске йорт авылында мөгаллимлек иткән зыялы кешеләрдән. Хәер, Рузалия апа да төшеп калганнардан түгел, Ташкичү мәктәбендә биология укытып, озак еллар директор да булган кеше. Бүген кызы, кияве, килене Гүзәлия дә укытучы.

Ташкичү мәктәбендә җитмешләп бала белем ала. «Таттелеком» башлангычы белән Мәрҗани музеен булдырганнар, мәктәп каршына бөек мәгърифәтчегә мемориаль таш куйганнар. Шушы авылдан булган язучы Мәхмүт



Галәүне исә хәтерләми хәлләре юк – ярты авыл диярлек Галәүтдиновлар йөри, димәк, нәсел дәвам итә.

Тик, кызганыч, авыл бик олыгайган. Буш йортлар күбәйгән, тәрәзәсеннән тормыш уты күренгән өйләрнең дә күбесендә карт-коры гына.

Мәмсәдә хәлләр күңеллерәк әле. 117 хуҗалыкта гомер итүче 24 бала мәктәп яшендә, унбишләп сабый балалар бакчасына йөри.

## ХИКМӘТЛЕ САМАВЫР

Төрле кыйтгалардан килгән милләттәшләребезне тарихи самавырдан мәтрүшкәле чәй белән сыйлады Гариповлар. Нәселдән күчкән хикмәтле раритет икән. Рузалия апа сөйли:

– Мин Мәмсәгә килен булып төшкәндә, өч сандык бар иде. Ә алар әби-бабайлардан калган чигүле намазлыклар, сөлгеләр, камзуллар, Коръән китаплары... белән шыплап тулган. Күбесен музейга бирдем, былтыр экспедициягә килүчеләр дә төшереп алды әле. Менә бу ун литрлы самавыр биш пичәтле, 1905 елда Тулада бертуган Биташевлар ясаган. Аны чормадан табып төштем. Агарттым, юдым. Әнкәйне чәй эчәргә чакырдым. Ә ул: «Ул самавырны күрәсем дә килми», – димәсенме! Баксаң, каенанасы усал булган икән. Өч айлык баланы калдырып, Шекә басуына эшкә йөргәннәр бит элек. Кайткач, үкереп елап яткан бала янына килергә ярамаган. Иң беренче эш итеп, әнә шул самавырны кайнатып, каенанасына чәй эчерткәннән соң гына баланы имезә алган. «Ярар, әнкәй, аның каравы киленең әйбәт, шушы самавырны сыкканчы чәй эчик», – дип күндердем.

Чәйдән тыш, Мәмсәдә иң дәрәҗәле ризык – гөбәдия икән. Бәлешне дә үзләренчә – итне иттарткычтан чыгарып, дөге белән пешерәләр. Бәйрәмнәргә кабарып торган камырдан паштет әзерлиләр.

Фәрит белән Раилә ике яктан да нәсел-нәсәбәне туплап, бергәләп ял итү гадәтен дә яңартып җибәргән. Бәрәңге утыртуга, берничә машина төялешеп, Хәтнә чишмәсенә баралар, догалар укыйлар, ярның икенче ягына чыгып, ашлар, пылаулар пешереп сыйланалар, төрле спорт ярышлары үткәрәләр.

Авылда күркәм гомер итү – бердәм, бер гаилә булып яшәү фәлсәфәсе дә, рухи гармониядә дә чагыла, күрәмсең.



*Конгресс корылтаена килгән кунаклар белән*

Рөстәм Байбулат



# Сак булыгыз: СПИННЕР!

Бер уен белән кызыксыну кими, аның урынына икенчесе барлыкка килә. Менә берничә ай инде спиннер популярлашканнан-популярлаша. Аны бармагында әйләндерүчеләрнең күплеге тирәлекне бимазаландыра ук башлады.









Май башында вак-төяк сатучы киоскларда, тәмәке ларекларында гына күренгәләгән спиннер инде кием кибетләрендә дә, хәтта азык-төлекнекеләрнекендә дә очрый. Астан эш йөртүче рекламачылар гына түгел, яңа төшенчәнең мәгънәсен аңлатучы күпләр, бәлки, аны ясаучыларга ияреп, әлеге уенчыкны нервлары таушалганнарны, тынычсызларны дәвалау, хәтта тәмәке тартудан, тырнак чәйнәүдән, баш кашудан һәм алардан да көчлерәк башка яман гадәтләрдән коткару чарасы кебек тәкъдим итә. Моңа җитештерүчеләр һәм аларның продукциясен таратучылар белән сүз беркеткән табиблар да кушыла. Алар, спиннерны бигрәк тә офисларда булырга тиеш, бергә эшләүчеләр арасына тынычлык алып килә, талашулардан коткара, кешенең фобияләреннән азат итә, игътибарын эшкә юнәлтә, рәвешендәге чүпчарларны язып кына тора.

Бүгенге көндә Америкады иң күп сатылган уенчык спиннер икән, кайбер штатларда балаларга алынган егерме уенчыкның унҗидесе спиннер, имеш. Ә нигә соң ул вакытта бигрәк тә укучылар сәламәтлеге өчен борчылган психологлар, невропатологлар, инде алар артыннан ук укытучылар да әти-әниләрне модага кергән уенчыкны сатып алмаска чакыра?

Бармакларга тренажер рәвешендә уйлап табылган гаджетның төзелеше бик гади, аны куллану исә тагын да гадирәк: спиннерны үзәгендәге подшипникларын тотасың да калган бармакларың белән шул үзәк тирәсендә әйләндерәсең. Төзелешенә, материалына карап, әйләнү вакыты – төрлечә, кайберләреннеке ике минуттан артмый, ун минутны уздыра торганнары да юк түгел. Спиннерны балаларга файдалы дип табучылар, вак детальләре юклыгын, шомалыгын, төрле, шул исәптән табигый материаллардан да эшләнүен, төсләргә байлыгын, игътибарыңны борчулардан алып китүен яисә үзенә теркәвен, сөйләмне камилләштерергә булышуын һәм башкаларны сәбәп итә.

Америкалы Кэтрин Хэттингер егерме дүрт ел элек уйлап тапса да, ул дөньяга ныклап торып бу елда гына, апрель-май айларыннан таралды һәм илле миллионнан артык сатылган инде. Димәк, таралыш мондый кызулык белән барса, бәләкәй баласы булган күпләр аны алырга

мөмкин дигән сүз. Гаджетны рекламалаучылар бездә дә беренче көннән үк, ул кыбырсык балаларны – тынычка, ата-ана игътибары җитмәгәннәрне – игътибар җиткәнгә, аутистларны акыллыга әйләндерә, дип сөйләргә тотынды. Уенчык алырга ниятләгәннәр бигрәк тә аларның Кэтрин Хэттингер үз кызын көчле бәдән йомшаклыгы хасталыгыннан шуның белән дәвалаган дигән сүзенә кызыга. Әле кайчан гына бик кыйммәт торган гаджетның хәзер очсызлы пластиктан эшләнгән йөзйөз илле сумлыкларын да очратырга була.

## СПИННЕРДАН КЕМГӘ ЗЫЯН?

Америкада спиннер апрель аенда ук тыела башлады. Аурупага якынрак Украинаның кайбер шәһәрләрендә аны сатуны ук тыйганнар. Бу тыюлар күп кенә илләргә кереп барса да, Русиягә күчкәне юк. Яңа төр продукцияне күпмиллионлы тиражда тарату мөмкинлеге булган илебез җитештерүчеләрне торганнан-тора ымсындыра, инде ул кытайлар уйлап тапкан хәерсез спиннерлар белән тула башлады. Табибларыбыз гына, гадәттәгечә, балаларыбызга куркыныч яный, дип чаң сугарга ашыкмый.

Гаджеттан янаган куркынычларны искә алып узыйк. Җитештерүчеләр һичбер зыянсыз дип игълан иткән спиннерларның берничә илдә ватылу, Америкада детальләрен балалар йоту очраклары теркәлгән. Бигрәк тә бәләкәчләргә аны бирү ярамый: подшибниклары коелырга мөмкин. Ә сабыйлар андый түгәрәк әйберләрне авызга алырга гына тора. Укытучылар, спиннер телефонга караганда да зыянлырак, балалар дәресне тыңламыйча, шуның белән уйнап утыра, дип зарлана. Телефонны сүндертергә, алып куярга мөмкин, ә спиннерны яшереп тә уйный алалар. Бөтен класс белән спиннерда уйнап, дәресләр өзелгән мәктәпләрдә аны тулаем тыю чарасын кайгырта башлаганнар да.

Ниһаять, кайчан гына аны яклап язганнар да, уенчык игътибарлылыкка өйрәтми, киресенчә таркаулык тәрбияли, дигән фикергә килә башлаган. Тавышлы спиннерлар да бар бит әле. Аларның олыларның да ачуын чыгаруын әйтеп тору кирәкме икән?! Тавышсызларыннан чыккан кытырдау-кыштырдаулар исә үзе спиннер белән уйнамаган балаларны дәрестә генә түгел, башка урыннарда да бик бимазалый, шунлыктан алар тирәлегендә үзара бозылышып китү очраклары ешайган. Спиннер аккумуляторларының инструментларсыз да җиңел алынганнары бар, балалар телләрен тидерергә һәм зыян күрергә мөмкин. Кечкенәләр өчен чыгарган теләсә кайсы уенчыкның батареялар чокыры шөрепле капкачлар белән ябылырга тиеш тә югыйсә...

Укытучылар спиннерда уйнаучы балалар дәрес хәзерләми, ә шуның белән чирләгән ата-аналар аларны тәрбияләү җаваплылыгын онытты, дип тә зарлана. Кайберәүләр хәтта интернетка да керми башлаган йә киресенчә интернетта утырганда, шуны әйләндереп, дөньясын гомумән оныта икән. Дәрестә спиннерларын тартып алганда, аны бирмәс өчен яисә укытучыга ачулары килеп, укучылар зур агрессивлык күрсәткән, педагогларны кыйнаучылар, хәтта үтерергә омтылучылар булган. Шуның нәтиҗәсендә, спиннер таралган илләрнең кайбер мәктәпләрендә аны дәрескә алып килүчеләрне укудан ук чыгара башлаганнар. Спиннердан бигрәк тә аллергиклар һәм астма белән чирләүчеләр зур зыян күрә, чөнки ул, составындагы кургаш аркасында, әлеге авыруларны көчәйтә, көтмәгәндә балаларны хәтта тынсыз калдырырга да мөмкин.

Укучым, инде сайла: спиннер кирәкме сиңа, юкмы?



**Без бәләкәй чакта, баланың теле ачылсын, камилләшсен дип, бармак уеннары уйнаталар, бармак такмазалары өйрәтәләр иде. Баш бармак бау ишә, имән бармак имән кисә... Хәзер әлеге ике бармак подшипник үзәген тота, урта бармак утын ярмый, чәнти бармак та чәй эчеп кенә дә ятмый, чигү дә чигә белми – ул инде спиннер әйләндерә.**



**НӘСЕР**
*Либераль Ләйлә*



**ША-ЯРЫШ**
*Наласа мәзәкләре*




**УКУЧЫ МӨНБӘРЕ**
*Язучы Марат Кәбировка ачык хат*

# Әдәбият

*шигърият*



*Эльвира Ирфан кызы Сафина тумышы белән Чүпрәле районы Яңа Кәкерле авылыннан. Бүгенге көндә Татарстан Фәннәр академиясенең Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтында лексикография бүлегенең өлкән фәнни хезмәткәре. Төрле типтагы сүзлекләр төзү белән шөгыльләнә. Филология фәннәре кандидаты. Студент елларыннан ук төрле матбугат чараларында хикәяләре, мәкаләләре, шигырьләре басылып килә. Күп кенә шигырьләре көйгә салынып, популяр җырларга әверелеп өлгерде.*

## Эльвира Сафина

## КЕШЕ БӘХЕТЕНӘ КЫЗЫКМА

***

Ачылырга бер дә яратмадым,
Йөрәк түрләрем шул гел бикле.
«Үз хәлеңне үзең бел», – дигәннәр,
Чынлап аңлаулары бик шикле.
Кайнап торган казанмы йөрәгем,
Сүнеп бара торган учакмы?
Үз-үземә хуҗа кешеме мин,
Кеше кулындагы курчакмы?
Читтәгеләр күрми, сизми аны,
Бураннарым – офык артында.
Үзем генә басып торам менә,
Һава сулап... шушы салкында...

### АЛМАГАЧ

Туйлар узгач, бакчабызга,
Утырттык без алмагач.
Алмагачны мактый-мактый
Сайрый көн дә сандугач.
Матур сүзләр әйтә-әйтә,
Алма белән сыйлыйсың.
Ел артыннан ел үтсә дә,
Яратып һич туймыйсың.
Алма кебек тәгәрәшеп,
Үсеп килә балалар.
Алма ашаган балалар
Үзләре балдай алар.

### АРАЛАР ЕРАК ТҮГЕЛ

Якын яшәгәннәр кайчак
Еллар буе күрешми.
Үз дөньясы белән яши,
Хәлләрен дә белешми.
Уйлар-хисләр уртак булса,
Ара ерак була алмый.
Ерак тоелган юлларга
Хәтта тузан куна алмый.
Якыннар янда булганда
Күңелләр канатлана.
Бергә чакта бик тә рәхәт,
Ерагаймасын ара.

## ЯШӘҮ КӨЧЕ

Шатлыгы да, сагышы да була,
Бар да була гомер иткәндә.
Күп тойгылар югалып та кала,
Еллар арты еллар үткәндә.

Кайгы килгәч, югалып калмаска,
Яшәү көче булсын йөрәктә.
Гомеребез бары бер генә лә,
Ике килми, елап йөрсәк тә.

Булсын әле, шатлык та, сагыш та,
Шул чакларда яшәү кадерле.
Һәммәбез дә яши алсак иде,
Югалтмыйча булган кадерне.

## ТАТАР ГАРМУНЫ

Һәр чорның да үз көе, үз моңы,
Яшьләрнең дә бүтән җырлары.
Ә шулай да үзәкләргә үтеп,
Сихерле бит гармун моңнары.

Югалмыйча еллар төпкелендә
Мирас булып калыр бар моңнар.
Һәр йөрәккә ишеттерә алса
Татар көен тальян гармуннар.

Җырлаганда гармунга кушылып
Онытабыз ару-талуны.
Алмашынып торса да буыннар,
Картаймасын татар гармуны.

## РӘХМӘТ...

Юлыбызда күпме кеше очрый,
Кайберләрен бүтән күрмибез.
Җылы сүзе, ярдәмнәре өчен
Рәхмәт әйтү җаен белмибез.

Яхшылыклар җирдә ятмый, диләр,
Игелекне беркем онытмый.
Күңелдәге иң җылы хисләрне
Саклый алсак иде суытмый.

Бер рәхмәт тә җанны җылыта ала,
Канат куя ала кешегә.
Чын күңелдән кат-кат әйтик әле,
Болай да бит җаннар өшегән.

## КЕШЕ БӘХЕТЕНӘ КЫЗЫКМА

Без дә төрле, юлыбыз да төрле,
Төрлелеге белән кызык та.
Үз рәхәтен тоймый яши икән,
Кеше бәхетенә кызыккан.

Яшәү дәрте булсын күңелләрдә
Ике түгел, гомер бер килә.
Кабатланмас һәрбер мизгелеңне
Бу – куаныч диеп билгелә.

Гөлләрнең дә чәнечкесе була
Язмышлардан юк шул узмышлар.
Сынмый гына узып сынауларны
Рәхмәт әйтеп яшик язмышка.

***

Яшьлектәге ярлар иң матуры,
Иң яхшысы кебек тоела.
Еллар үткәч күрсәң – әллә ничек...
Агачлардан яфрак коела.

***

Яхшы кешеләргә тартылам мин,
Эчкерсезгә, чиста күңелгә.
Матур алмаларда кортлар күреп
Түгелмәче, күңел, түгелмә...

## СӘЛАМ БИРӘДЕР...

Иртә. Метро. Таныш түгел берәү
Карап бара миңа нигәдер.
Бәлки берәр кая күргәне бар,
Бәлки танышасы киләдер.

Ә бит була шулай: бер үк кеше белән
Һәр көн саен юлың кисешә.
Гадәтләнгән вакыт, күнегелгән сукмак...
Меңнәр шулай юллар бүлешә.

Яңа йөзләр (яңа таныш йөзләр!)
Җыеп кайтам һәрбер сәфәрдән.
Бер карасаң, күпме таныш хәзер,
Төрле авыл, төрле шәһәрдә.

Иртә. Метро. Таныш түгел берәү
Карап бара миңа нигәдер.
Бәлки берәр кая күргәне бар?!
Эчтән генә сәлам бирәдер...

## КАРА ҖИЛЛӘР

Тыныч кына гомер кичергәндә,
Ата башлый кайчак туплар да.
Гомер озынлыгын үлчәгәндәй,
Сызгырышып оча уклар да.
Сугыш узган җирләр көлгә кала,
Кала көлгә күпме гомерләр.
Көл астында калган гөлләребез
Кояш нурын кайчан күрерләр?!
Якты итик илнең киләчәген,
Куанышып шунда яшисе.
Балаларның өзмик өметләрен,
Тоймасыннар тормыш әчесен.
Дөнья – матур, дөнья шундый якты,
Эх, һәр кеше шуны аңласа.
Сугыш дигән кара җилләр исеп,
Күңелләргә шомнар салмаса!

***

*Нигә акыл соңлап килә икән?*
*Күп әйберне соңлап аңладым.*
*Г. Бәйрәмова*

Кызуында, янып көлгә кала,
Әй, борчыла адәм баласы.
Бар да үтә, үтә барысы да,
Йөрәк аны ничек аңласын?!
Күп әйберне соңрак аңлыйбыз шул,
Асылына соңрак җитәбез.
«Эх, шул чакта моны белгән булсам!»...
...Күпме юллар инде киткәнбез,
Шәм түгел лә йөрәк, янган саен
Алып булмый аның яңасын.
Яши-яши акыл кирә дә бит,
Вакытында каян аласы?

***

Үзгәртмәде инде
Сине еллар.
Нигә өметләндем аларга?!
Куркак идемме соң,
Нигә кирәк булды
Синең капкыныңа
кабарга?
Ә мин үзгәрдемме?
Бәлки...
Карбыз түгел, ярып карарга.
Шул халәттә күпме гомер үтте,
Рәхмәт диимме соң аларга?
Ә шулай да, куркам бугай әле,
Куркам бугай артка карарга...

# Рифә Рахман

*Рифә Рахман мәхәббәт һәм яшьлек шагыйрәсе буларак танылса да, соңгы елларда вакытлы матбугатта күбрәк прозаик һәм публицист сыйфатында чыгыш ясады, укучыларны шигъри әсәрләренә бик сусатты. Аеруча туташларга һәм егетләргә якын булган «сөю»ле шигырьләре. Алар хатын-кызны чынлап яраткан ир-атның һичничек онытылмавы, килүе, җиңүе, китүе турындагы бер кыйсса булып күңелгә уза сыман.*

## ИРЕННӘРЕМ СУСЫЛЛАНЫП КИТӘР, КЕРФЕК ОЧЛАРЫНА ИЕЛСӘҢ...

### ТАГЫН БЕРАЗ ТОРСАМ

Тагын бераз торсам, тагын бераз,
Соңга калам, дисең, автобуска.
Юкка гына төшкән икәнсең син
Яшьлек исмендәге тукталышка.

Тын тор бераз, кирәк кайчагында
Уйланулар гомер уртасында.
Артык түгел мондый тукталышлар
Каршы алыр кешең бар чагында.

Кирәк кайчак тукталышларның да
Озаккарак сине туктатканы.
Яшьлек еллар буе көткән ләса
Шуны аңлап синең бу кайтканны.

Тагын бер кич, дисең, тагын бер кич –
Озаккарак калу, озаккарак.
Булмый ла ул гомер мизгелләрен
Кирәк чакка гына туктаткалап.

Кирәк шундый тукталышлар ясау
Әле минем сине көткәнемдә.
Теләсәң дә, бәлки, күралмассың
Бу дөньядан арып киткәнемдә.

Туктат, диеп, кенә тукталышлар
Ясый алмас синең автобусың.
Гомереңнең ахыр көннәрендә
Минем турда булмас тукталышың.

### ОНЫТЫЛГАН ЧАГЫҢДА

Онытылган чакта бөтенләй үк
Синең йөзең, гәүдәң, тавышың,
Барысын да бүләк итте миңа,
Кассетага язып, танышым.

Синең җырга колак салчы, диеп,
Белдерде ул миңа теләген.
Мин куймаган әле уйнатырга
Аның көтелмәгән бүләген.

Тыңларгамы аны, тыңларгамы
Син җырлаган җырны тагын бер?
Ни качсаң да, сиңа язган сүзләр
Эзләп таба икән барыбер...

### ЯТАК...

Ятак сүзләрендә ят сүзе,
Ике караватта ят инде...
Әйдә, диеп, минем кочакка,
Юрган очларыннан тарт минем!

Ятак сүзләрендә так сүзе,
Син пар булып миңа ятсаңчы.
Бер ятакта яткан ят булса,
Үзеңә тиң мине тапсаңчы.

Ятак сүзләрендә ак сүзе,
Саф мәхәббәт, зинһар, тап сүзе.
Күңеленә ак төс ят булса,
Тәнгә гөнаһ эшләр так сүзе.

* * *

Нигә киттең инде, үртәгәндәй,
Тәмәкеңнең бии исләре.
Син килгәнне миңа хәтерләтә
Җыелмаган өстәл өсләре.

Юылмаган савыт, җыелмаган
Син йокламый яткан урыннар.
Миннән җиңел генә китәсең син:
Әйе, синең китәр җирең бар.

Әйе, синең сөяр кешең дә бар,
Сөйгән кешең дә бар һәр төндә.
Ул гашыйктыр хәтта тәмәкеңнән
Борын ярып кергән төтенгә.

Исләреңә синең йокыдагы,
Төшләреңә синең еш күргән.
Синнән китте, диеп үртәгәндәй,
Буш бүлмәдә бии төтеннәр.

Син киткәнне миңа хәтерләтә
Син вакытын куйган сәгать тә.
Китеп барасың син уфтанмыйча –
Җиңел генә кием сәдәфләп.

Җиңел генә сөйләп хушлашуның
Елатырлык хәтта сүзләрен.
Төне буе төтен сөйгәнмени,
Хәтта булганыңны сизмәдем.

Төне буе төтен кочканмынмы
Еллар буе ялгыз кочакта.
Кайчан күзне төтен яшьләндерсә,
Сине искә алам шул чакта.

## ГӨЛ БӨРЕСЕ

Әй мин сиңа үпкәләмим,
Үпкәләсен әнә гөлләр,
Яфраклары сабагыннан
Өзелгән бит авыр сүздән.

Таҗчыклары бөреште дә,
Ачылмады бөрем, дисен.
Җитмәсә, син миңа да бит,
Бөреләнгән гөлем, дисең.

Әй мин сиңа үпкәләмим.
Үпкәләсен гөл бөресе...
Касәсенең хәле киткән,
Төсе качкан иренлесе.

Үпкәләр дә – миңа бүләк
Икәнлеген белә ләса!
Аңа рәхәт булыр микән,
Минем күздә яшь уйнаса?!

Аңа бер дә кызык булмас,
Кәеф китсә минем кичен.
Җитмәсә, син, рәнҗеткәндә,
Елак-мылак гөлем, дисең.

Әй мин сиңа үпкәләмим,
Иренемне бөрештермим,
Мин аларны бу кичемдә
Синең белән үбештермим.

Мин гөлне дә, моңсулатып,
Синең белән көрештермим.
Синең төртмә сүзең белән
Гөл күңелен ирештермим.

Үпкәләми генә, көлеп
Яшәсен ул вазасында.
Кайда шаян гөлем, дисең,
Шакып, ишек ачасың да.

Кайда алсу гөлем, дисең,
Кәефләрең яхшы чакта.
Гөл яшәрә, бөре ача,
Файдаланып шул форсаттан.

Алсу иреннәрен суза,
Синең миңле иренеңә.
Син аңарга бары, бары
Матур сүзләр генә сөйлә!

## КАЙТКАН КЕБЕК БУЛЫР

Еллар атын аргамакка тиңләп
Шигырь язган чагым бар иде.
Иреннәрем әле сусыл иде,
Керфек очым әле бал иде...

Сине сөймим, диеп язган каләм
Шигъри күңелемә яр иде.
Сөелсәм дә, сөйми үпсәләр дә,
Арган чакларымда ял иде.

Чабышкылар бер әйләнеп кайта,
Гомер аты гына юк икән.
Иреннәрем сусылланып китәр,
Керфек очларына иелсәң.

Бит алмасы алсуланып китәр,
Әдәпләрен белеп үрелсәң...
Яшьлек кире кайткан кебек булыр,
Яшьле керфек аша күренсәң.

Сагыш баса кебек йөрәгемне,
Бу дөньяда сөю юк, дисәм.
Ул да кире кайткан кебек булыр,
Кыяр-кыймас кына бер килсәң.

## УЙНАК КУЗЫ

Нинди сафлык, дисең, еллар буе
Мине онытмаган күзләреңдә –
Онытканнар алар, онытканнар,
Сине көтү төшкән үзәгемә.

Нинди чиста дисең тавышларың,
Элеккечә икән, элеккечә, –
Бик үзгәргән инде аваз моңым,
Син әйткәнчә иде әле кичә...

Нинди татлы, дисең, иреннәрең,
Минем өчен калган кебек татлы–
Әче алар мин теләгән кадәр,
Баллы түгел сиңа кирәк чаклы.

Нинди алсу дисең көләч битең,
Кыз чактагы кебек, кыз чактагы–
Сикергәндер синең ялганнарың
Кузы кебек уйнак уачактагы...

* * *

Өсләрен гел сөрткән көзгеләрдә
Синең төсләр беткән бөтенләй.
Калдыр, диеп, шуның яңаларын
Юк шул минем сиңа үтенгән.

Мин бит беләм: тагын югалырсың,
Берни булмаган күк арада,
Син килмәссең тагын икенче кат,
Еллар ятмый торып арага.

## ҖАНДА – СӨЮ ХИКМӘТЕ

Сөю хәлен белә сөйгән генә,
Сөю хикмәтләре – җанымда.
Корам хәйлә сине каратырга
Һәм үзеңнән тартып алырга.

Караттырам әле, яраттырам,
Андыйга мин яшьтән булдырам.
Тыныч кына яши бирүчегә
Сөю бураннары туздырам.

Сөю яңгырлары яудырам да
Хәл алырга ара калдырам.
Акылыңа килдем дигәч кенә,
Мин аңардан тәмам яздырам.

Сөю хәлен белә сөйгән генә,
Нигә әле сиңа сөймәскә!
Мин шагыйрә булыр идеммени,
Гашыйк иттермәсәм күргәч тә!

* * *

Тәм-томнарсыз ярар микән, дисең,
Синең янга барып килергә.
Ашамаска әзер, яшәмәскә –
Суламаска әзер шул төндә!

Риза хәтта телсез торырыңа,
Йоткан кебек аны килгәндә.
Ризык-тәгам көтеп ятамыни
Сөю түшәгендә бер бәндә?!

Үлем көткән кебек халәттә мин –
Син киләсен белгән мизгелдән.
Оят кочагында җан биргән күк,
Оят качкан өчен йөземнән.

## ЭЛЕККЕЧӘ КАЛСЫН

Шылтыратмасаң соң! Шылтыратма!
Яшәдек бит әле сөйләшмичә,
Зарланмыйча гына шул яшәүдән,
Безне сөйгәннәрдән көнләшмичә.

Яшәдек бит әле көрешмичә,
Онытмадым сине, диешмичә.
Ә сөйләшсәк, булыр элеккечә.
Ул кешечә булыр, бик кешечә.

Шылтыратмасаң соң. Шылтыратма!
Тиеннәрең калсын үз яныңа.
Кәнфит алырсың йә хатыныңа,
Ипи алырсың йә казларыңа.

Яшәдек бит затлы кәнфитләрнең
Киемнәрен яклы салдырмыйча.
Кәнфит кебек йоткан иреннәрнең
Иреннәрдә тәмен калдырмыйча.

Шылтыратмасаң соң – шылтыратма.
Хәл белешү булыр бик кешечә.
Кешеләрчә булу бармый безгә.
Барсы калсын әйдә элеккечә.

* * *

Басып торган идек кайчандыр без
Көзге каршысында кочаклашып.
Еламсырап караганың истә,
Көтмәгәндә күңелләрең ташып.

Басып торган идек кузгалалмый,
Кымшанырга куркып бер мизгелгә.
Тормыш йөген күтәралган кадәр
Өйгән кебек ике иңебезгә.

Хуш, диюең җитте кузгатырга,
Һәм шул мәҗбүр итте озатырга.
Шул үк көнне ваттым көзгеләрне.
Син еракта – кулны озайтырга.

Син еракта үпкә белдерергә,
Һәм инде ул хәзер кемгә кирәк?
Ватмаска дип элгән көзгеләрдә
Китмәскә дип төшкән башка сурәт.

* * *

Безнең яшьлек сиңа бик тә тешле –
– Синнән китмим мәңге!–
Димәгәнсең.
Картаюың бик тә үкенечеле –
Ярый әле мине сөймәгәнсең.
Назлар, хисләр... –
Сиңа чит бер нәрсә!
Сөйләшә дә улчак белмәгәнсең!
Ә мин менә һаман элеккечә.
Җиңел холык,
Җиңел кием – өстә.
Күзеңә генә пар эзләгән кебек,
Дисең:
Синең алар нинди төстә?
Нинди иде, дисең, синең чәчең?
Толымнарың, диген, толымнарың.
Нинди толым?!
Син бит оныткансың
Толымымнан тарткан болының барын.
Яшьлек сиңа әнә шуңа үчле –
Хәтерләрең бик тә кыска икән.
Иренеңнең татын беләм диеп,
Шомартырга гына оста икән.
Белмисең син мине, белмисең син!
Син тилмертмәс идең әгәр белсәң!
Кайтмас идеңмени болыннарга,
Үпкә калкыр идемени җанда,
Таулар итәгендә аткан гөлгә
Язгы җил күк
Назлы бер иелсәң...

## СӨЙЛӘШҮГӘ СУСАУ

Сөйләр сүзләр мәңге бетми икән,
Истәлектән хисләр кабынгач та.
Дертләп китәм, синең дымлы тының
Колак очларына кагылгач та.

Син читкә куй мине назлавыңны,
Сөйләшик гел, бары сөйләшик гел.
Мәхәббәтнең була мең төрлесе.
Тәнгә тими сөю кадерледер.

Күздән узган хисләр хислерәктер,
Минем сөю шуның ишерәктер.
Шундый сөю уятырлык сүзне,
Мине тыңлап, искә төшерә тор.

## ӘГӘР БЕЛГӘН БУЛСАМ

Әгәр белгән булсам югалганны
Көтмәгәндә кабат табармын дип,
Бик күп ялгышлыклар эшләмичә,
Ялгыз гына яши алганмын бит.

Әгәр белгән булсам чын уеңны
Яшьлегемдә менә минем хакта,
Мин түзәргә әзер идем дә бит,
Бергә-бергә хәтта кыйналсак та.

Әгәр белгән булсам югалганны
Табуның да шундый авырлыгын,
Мин тукталып уйлап торыр идем
Башларында сиңа илткән юлның.

Мин тукталып сорау бирер идем,
Кирәк микән дип бу миңа хәзер.
Инде белгәч шуның авырлыгын,
Аны ялгыз күтәрергә әзер.

## ҖЕПШЕКТӘ

Яз исләре килә инде кардан,
Үлән исе килә җепшектә.
Язны сулап, тәмам онытырга
Телим бик тә сине бу кичтә.

Мөмкин булса икән онытырга,
Синсез язларымны уйлап кына.
Башкаларга хисне яңартырга –
Синсез һаваларны сулап кына.

Яз исләре килә көнбагышка
Очып төшкән карга баласыннан.
Ирлек гайрәтләре – әткәсендә,
Сөю исе килә анасыннан.

Алар берни аңлатмыйдыр, беләм,
Сиңа гашыйк түгел кешегә.
Их яз исе, нигә борын ярып,
Сине генә искә төшерә?!



Рәзилә Рәшид кызы Газизова – Әтнә районы Күңгәр урта мәктәбенең 11 сыйныф укучысы. Өч тапкыр республикакүләм «Алтын каләм» бәйгесендә катнашырга да өлгергән. Буш вакытында Мәдинә Маликова белән Марат Кәбировның китапларын укырга ярата. Каләме – өметле, яңадан-яңа әсәрләр көтеп калабыз.

## Рәзилә Газизова

# ЛИБЕРАЛЬ ЛӘЙЛӘ

*Хикәя*

«Тагын яңгыр ява...» Ләйлә, шул уйлар белән караватыннан иренеп кенә торып, тәрәзәгә бакты. Пыскып яуган яңгыр кызның ачуын китерде. Ник тиз генә явып үтми икән ул? Яңгыр да аның ачуы килүен сизде ахры, котырткандай ява бирде. Ләйләнең кәефе һава торышына бәйле. Табигать «еласа», кызның кәефе бер дә булмый инде, шуңа күрә караватыннан «сул аягыннан тора» да мәктәптә юньле билге алмый. Ә менә иртән кояш битне иркәләсәме?! Гадәттә бик уңышлы була ул көн. Әллә туры килә, әллә чынлап, билгеләре дә «дүртле», «бишле»ләр генә эләгәме шунда. Шуңа да аны дуслары «Либераль Ләйлә» дип үртәргә ярата. Атна буе болытлар кунаклап йөри әле аларның авылында. Шуңа да бу атна Ләйлә өчен бик авыр иде.

Тешләрен чистартуга, тиз генә чәйләп алып, киенәсе итте кыз. Карале, әнисе дә йокыдан тормаган бит. Кайчакларда әнисе йокы симертергә ярата аның. Менә бүген дә шундый хәл. Бүген әнисе Ләйләне түгел, ә Ләйлә әнисен уятты:

– Әнием, тор әйдә, тор. Соңга калуыңны теләмим.

– Тукта, соңга каламмы?! – дип йокылы-уяулы кабатлады Йолдызның әнисе. – Сәгать ничә соң, кызым?

– Нәкъ җиде!

– Әәәә? Шушы вакытка кадәр йокларлык ни эшләдем соң кичә?.. Бигрәк соң икән инде, – дип ашыгырга тотынды. Һәм Ләйләгә ишетелерлек итеп:

– Рәхмәт! – дип кычкырды.

Ниһаять, алар әниле-кызлы ашыга-ашыга киенеп, урамга атылдылар. Бүген гадәттәгечә акрынлап, сөйләшә-сөйләшә түгел, ә кызу адымнар белән йөгерә-атлый бардылар. Аяклар да үзеннән-үзе атлаган сыман иде. Әле ярый, Йолдыз ханымның хезмәттәше Таһир абыйлары очрады. Боларны күргәч, туктамый уза алмый иде инде ул. Бу юлы, туктап, көлемсерәп кенә:

– Такси чакырттыгызмы? – дип сорады.

– Исәнме, Таһир абый! Вакыты белән генә йөрисең.

– Сәлам, кызлар. Ашыгуыгызга караганда, соңга каласыз бугай.

– Әйе шул, әле ярый кызым бар уятырга. Әгәр ул да тормаган булса, бүген эшкә киләсе кеше түгел идем мин, – дип сөйләп китте әнисе. Бара торгач, Ләйләнең мәктәбенә дә килеп җиттеләр. Җәяүләсә, өлгерми иде ул. Җәяү егерме минутлар тирәсе үтә, машина белән тиз шул. Кыз, рәхмәт әйтеп, машинадан төшеп калды.

– Мәктәптә «бишле» генә ал! – диде әнисе.

«Мәктәптә бишле генә ал!» – Ләйләнең инде күптән бу җөмләне ишеткәне юк иде. Башлангычтан бирле! Тугызынчы сыйныфта гына укыса да, әнисенең аны әйткәне булмаган ич. Чынында алырмы ул «бишле»ләрне мондый яңгырлы көн-

дә? Бу атнада тәмам «дүрт»кә чумды. Бәлки, уңыш та елмаеп куяр?..

Мәктәпкә килеп керү белән, каршысына очраган бар ягымлы күз аңа елмая иде. Һәрберсенә «Хәерле көн!» дип кенә торасы килә. Тагын бер гаҗәпләнде: Ләйләдә бу хиснең атна башыннан бирле булганы юк иде ләбаса! Яңгыр явуга да карамастан, елмаясы гына килә.

Беренче физика дәресе иде. Роберт Наилевич тугызларга яңа дәрес аңлатырга кереште. Кемнәрдер аңлый, кемнәрдер юк. Чөнки 9 Б — мәктәптә авыр сыйныф булып санала. Укытучылар фикеренчә, анда барысы да «башлы ялкаулар». Роберт Наилевич көтмәгәндә темадан читкә китеп, үзе дә сизмәстән, экология турында сөйли башлады. Үзләренә якын тема күбесенең күзендә чаткы уятты, ә кайберәүләр һаман да үзләрен йокы белән сыйлаган караватын уйлый иде әле.

— Укучылар, күрәсез, глобаль проблемалар күбәя дә күбәя. Экология турында ишеткәнегез бардыр инде. Бу темага җитдирәк карарга тырышыйк әле, арткы рәттәге егетләр! — дип искәрмә ясады да сүзен дәвам итте. — Без — үзебез чүп чыганагы. Менә, мәсәлән, кесәдә кәнфит бар, ди. Без аны ашыйбыз, ялтыравыклы кәгазен җиргә атабыз да бәрәбез! Ул ялтыравыктан җиребез матурланмый, ямьсезләнә генә бит. Кесәдәге бар чүпне җиргә атып бәрергә димәгән. Өегезгә кайткач ташлап була бит. Моңа игътибар итәргә кирәк...

Көтмәгәндә кыңгырау шалтырады. Кабинетта Ләйләдән башка берәү дә калмады. Аңа Роберт Наилевичның сүзләре тынгы бирмәде. Иске кибет каршында чүптән дә күп нәрсә юк. Инде ул чүплеккә дә әйләнеп бара. Ә бит барысы да шул ялтыравыктан башлана.

— Зарипова, нәрсә булды? Берәр җирең авыртмыйдыр бит?

— Юк, Роберт Наилевич, барысы да тәртиптә. Сез әйткән сүзләр...

— Күрәм, сиңа да бу тема тынгы бирми.

— Әлбәттә! Кешеләр үзләренең гамәлләрен контрольдә тота алмый. Ә бит бу озон катлавына да йогынты ясый. Ә озон катлавы бетсә, кешелек бетә дигән сүз түгелме соң?

— Йә, Ләйлә, беренчедән, тынычлан. Икенчедән, син бик тирән фикер йөртәсең. Тик барысы да үзебездән тора. Бар, дәресеңә соңга кала күрмә.

Киләсе дәрес — биология. Бүген күзәнәк төзелешен үтәчәкләр. Ләйлә өчен авыр тема булды ул. Кая хәтерләп бетерсен: аның төзелешендә нинди генә компонент юк! Бөтен исемнәрен, аларның нәрсәгә кирәклеген, җитмәсә функцияләрен ятлап утырасы килми иде кызның. Җаны тартмаганын әллә каян күреп алды укытучылары.

— Ләйлә! Син дәрестә утырмыйсың, уйларың, хәтта кабинетта та түгел! — дип дорфа итеп эндәште биология укытучысы Чулпан Фәритовна.

— Гафу итегез. Чыгып керсәм буламы?

— Синең берәр җирең авыртамы әллә?

— Әйе, бераз башым әйләнә. Саф һавага чыгып керим әле?

— Бар, бар. Ә без дәресне дәвам итәбез.

Ләйлә биология дәресеннән чыгып китәргә мәҗбүр булды. Аның башы нәкъ менә митохондрия белән лизосомалардан авырта иде. Нәрсәгә инде ул аңа? Барыбер медицина буенча китәргә җыенмый. Дәрестән чыккач, саф һавадан баш тартмады Ләйлә. Бераз саф һава аңа комачау итмәс. Ә бит шушы саф һава ничәдер елдан соң бетә дә ала. Һәм кешеләр скафандрлардан йөриячәкләрме? Аллам сакласын, дип уйлады Ләйлә.

Дәресләр тәмам. Ниһаять, Ләйлә өенә кайта. Тик кайтыр юлы бүген ураурак булырга охшап тора. Кыз беркем җыештырмаган иске кибет каршына тукталды. Бу тирәдән үтәсе дә килми икән бит. Борылып караган саен күңел әрни иде. Кинәт, бер карарга килеп, Ләйлә тиз-тиз генә өс-башын алмаштырып килде. Үзе белән капчыклар алган иде. Чүп-чарны капчыкларга тутырырга кереште ул. Кемдер еракта гына: «Алла куәт бирсен!» — дип кычкырып узды, үзе ярдәмгә килмәде.

Ләйлә барысын да чистартырга ашыкты. Үтеп китүчеләрне ул күрмәде дә. Аңа тизрәк бу чүптән котылырга кирәк иде. Унберенчедә укучы Мансур гына мәктәптән кайтышлый, аны урап уза алмады. Әллә намусы борчыды, әллә йөрәге.

— Сәлам, Ләйлә! Бу чүплекне җыештырырга булдым дисең, алайса? Куштылармы? Әллә үз теләгең беләнме? Яңгыр ява бит... Пычранасың!

— Сәлам. Әйе, үз теләгем белән. Пычрак җыештыру һава торышына карамый. Яшәгән җирең, өең, урамың гел чиста булырга тиеш. Чүпне бит кояш чыкты, чүп ташлыймчы дип, беркем дә уйланып тормый. Ташлый да китә. Ә җыештыруга килгәндә, һава торышы, ди... Моннан үткәндә тыныч күңел белән китә алмыйм мин. Нигә әле мин аны, ике кулым, ике аягым була торып, җыештырмыйча китим ди?

– Ләйлә, син гаҗәпләндерә беләсең.
– Рәхмәт.
– Үзеңә рәхмәт. Мондый кешеләр аз була. Хәзер, киемнәремне генә алыштырып килим.
– Аңарчы бетәр инде.
– Кая әле, капчыкны тотып торчы.
– Әллә чынлап булышмакчы буласың?
– Ә сиңа мин комачау итәмме?
– Юк. Перчатка биримме?
– Бир соң.

Шулай итеп, алар икесе кибет каршын чүп-чардан арындырдылар. Менә хәзер карарга да ямьле. Яңгыр да туктады. Табигать үзе үк шатлана ахры. Кояш та чыкты. Барысы да әйбәт.

Күпмедер вакыттан соң район газетасында чистартылган иске кибет турында мәкалә дә чыкты. Штаттан тыш хәбәрче Мөнир абый: «Алар булмаса, кем?» дип, баш исем дә куйган. Шулай итеп, Ләйлә һәм Мансур «батырлыгы» турында авыл гына түгел, район халкы да хәбәрдар булды. Алар белән хәзер ерактан ук исәнләшәләр. Линейкада директор да мактап алды, икесенә дә бар мәктәп алдында дипломнар бирделәр. Ә киләсе атнада алар бар мәктәп белән авылларын җыештырырга чыктылар.

Ул көнне район телевидениесеннән Алия исемле бер сөйкемле апа килгән булып чыкты.

– Менә ул безнең Ләйләбез. Уку алдынгысы... – дип сузып китте директор, ул Алия апасы яныннан узып барганда.

– Исәнме, Ләйлә. Менә без сине төшерергә килдек. Әгәр бераз сораштырсак, каршы түгелдерсең?

Кыз югалып калды:

– Исәнмеееесеез...

Ни сөйләргә дә белмәде. Нәрсә эшләде инде шул чаклы? Кибет каршын чүптән арындырган иде, инде бар районга шушы сүз чыгарга тиешмени?!

– Юк! Мин каршы, – дип җавап бирде ул журналистка.

– Аңламадым. Димәк, без район үзәгеннән юкка килгән булабызмы, хөрмәтле директор әфәнде.

– Зарипова, яныма кил әле, – дип, директор Ләйләне бер читкә дәште. – Ләйлә, кадерлем, минем сине мәҗбүр итәргә хакым юк, ләкин журналист бик таләпчән. Әгәр безне шулай каршы алдылар дип бар районга белдерсә, әйбәт булмас, минемчә. Йә, уйладыңмы?

Район телевидениесе килеп китүе булды, республика журналистлары килеп төште. Алар килгәндә, Ләйлә математика дәресендә мәсьәлә чишеп утыра иде. Берзаман ишектән мәктәп директоры белән журналистлар килеп керде. Барысы да шаккатып, аларны күзәтте. Математика укытучысы Гүзәлия Илсуровна журналистлар үзләре генә булса, дәресне бүлдердегез, дип ачуланган булыр иде, ә бу юлы директор белән бит... Укытучы канәгатьсез генә ризалашты. Гүзәлия Илсуровна үз фәнен бик ярата. Аны тыңласаң, математикадан калган фәннәр икенче баскычка төшә дә бетә.

Директор сүз башлады:

– Алсу туташ, менә бу тугызынчы сыйныф укучылары. Ләйлә Зарипова бас әле. Журналистлар белән әңгәмә корып алырсыз.

– Ярар, тик минем математикадан мәсьәлә чишеп бетерәсем бар...

– Менә бит. Алсу туташ, ул риза.

Класстан Ләйлә чыгып киткәч, шаулаша башладылар. Аларның да республика журналистлары белән аралашасы килә булыр. Ә кемнең килмәсен? Авылга журналистлар бик еш килми шул.

Ләйләнең әнисе – Йолдыз апа эштән кайтып бара иде. Соңгы арада аның белән беренче булып исәнләшәләр. Әлбәттә, баштарак сәеррәк тоелды, аннан ул да ияләшеп китте. Менә бүген урамның түбән очында яшәүче Хәдичә апа очрады.

– Йолдыз сеңлем, син бик әйбәт әни икән. Үзең генә шундый кыз үстергәнсең бит. Машалла! – диде. Ерак китәргә өлгермәде, күршеләре Таһир абый куып тотты.

– Кызың герой икән бит, – ди. Йолдызның «Ләйлә тагын нәрсә эшләгән икән» дип борчыла башлаганын күреп, болай дип тә өстәргә ашыкты, – Бүген телевизор карадым, аның турында тапшыру күрсәттеләр. Әллә карамадың?

– Юк, бөтенләй берни аңламый йөрим әле бу арада.

– Алайса, мин сиңа хәзер аны интернеттан күрсәтәм, – дип телефонына үрелде ул. Йолдыз ханымга рәхәт булып китте.

Менә шулай кызы аңа кибет алдын җыештыруы хакында сөйләгән иде, ә телевидение турында ник бер сүз әйтсен! Шулай да әйбәт кыз үстергән ул. Чын кеше! Димәк, Ләйлә җәмгыятьтә югалып калмаячак. «Әле ярый кызым бар, – дип уйлады әнисе, горурланып. – Начар сүзләр түгел, әйбәт сүзләр генә ишетергә насыйп булсын».

Ә Ләйлә чыннан да акыллы кыз!

# Гомәр Даутов

## ТӨШ

*Хикәя*

Артем бүген аеруча җентекләп кырынды, чөнки Коръән ашына барырга җыеналар. Гаҗәп, үзе урыс милләтеннән булса да, мулланың укыганын тыңларга ярата ул. Сүзләре аңлашылмый, ләкин көйле аһәң, сузып, басым ясап әйтелгән тартыклар каядыр ашыккан җирдән туктап торырга, артка әйләнеп карага чакыра сыман. Әйтерсең лә нәрсәнедер, бик мөһим һәм кирәкле әйберне урап узгансың, нәрсә икәнен искә төшерә алмыйсың. Хәзрәтне тыңлаганда бу хис Артемны бөтен барлыгы белән билэп ала, ул бик игътибар белән тыңларга, серле сүзләрнең нәрсә аңлатканын аңларга тырыша.

Мулланы беренче тапкыр булачак хатыны, Гөлдания белән никахлашканда ишетте, шушы беренче ишетүдән үк гади булмаган кызыксыну билэп алды.

Гөлданияне беренче тапкыр әти-әнисе белән таныштырырга алып кайткач, әнисе кызга бәяләүчән караш ташлады да улының өйләнергә теләвенә һич каршы сүз әйтмәде. Ләкин никахлашу йоласы турында ишеткәч күтәрелеп бәрелде:

– Венчание, никах түгел, – диде кистереп.

Әтисе олы гәүдәле, инде корсагы чыга башлавына карамастан олпатлыгын җуймаган, тыныч кеше, һәрвакыттагыча сабыр һәм хәтта, битараф иде:

– Әйдә, никах булсын, – дип килеште дә артык чәпчи башлаган хатынын ике сүз белән бүлдереп:

– Барабыз, сынок, – дип, залга чыгып китте.

Валя белә, сүзен әйткәч, диванга ятып телевизорын кабызган Степан кире кайтмаячак, хатынының чебен кебек безелдәвенә игътибар да итмичә йоклап китәргә дә мөмкин. Бик ачуы чыкканда кузгалырга мөмкин урыныннан, ләкин бу хәерлегә булмаячак, шуңа күрә Валя билгеле бер чикне узмый. Яшь чагында бер узып карады инде, маңгаендагы җөйне агара башлаган чәчләре генә каплап тора.

Гөлданияләргә кайткач, Артемның игътибарын ике нәрсә җәлеп итте: капка төбеннән башланган чисталык һәм урамга ук чыккан тәмле ризык исләре. Техникумда, институтта укыганда татар егетләре һәм кызлары белән аралашканы булса да, татар мәҗлесләрендә, ислам дини йолалары үтәлгән җирләрдә булганы юк иде. Аннары, укыган җирдә бит алар барысы да студентлар, анда барысы да сессия-семестр законнары белән, башка мәнфәгатьләр белән яшиләр. Мәгълүмати технологияләргә синең татарлыгың ни дә, урыс, француз булуың ни. Кем әйтмешли, компьютер ул интернационал. Тигезләмәләр дә милли үзенчәлеккә түгел, барысы өчен дә уртак булган математика законнарына буйсыналар. Дөрес, татар егетләре аз сүзле, алар күбрәк тыңларга яратучан һәм эшенең асылын аңларга омтылалар. Ләкин гомуми фонда бу артык күзгә ташланмый, күзәтүчән Артем гына игътибар итте моңа. Аннан тагын бер нәрсәне искәрде: татар кызлары ашханәне бик өнәп бетермиләр, тулай торакка кайтып, үзләре әзерләп ашауны өстен күрәләр. Гөлданиянең нәкъ әнә шул гадәте араларны якынайтты да: Артемга рәхәт иде бу тыйнак кыз белән тыныч, ыгы-зыгысыз гына бүлмәдә кичке ашны әзерләп туклануы.

Кереп утырышкач, Артем өстәлне күздән кичерде, ирләр барысы да ак яки ак төс өстенлек иткән күлмәкләрдән, башларында түбәтәй. Хатын-кызлар, шулай ук, нигездә ак, аксыл-зәңгәр төстәге яулыктан. Килештереп бәйләгәндә яулык хатын-кызның йөзен каймалап алып, аны тагын да ачып җибәрә икән. Мулла сүзне алуга, барысының да йөзләре, юк, җитдиләнеп кенә калмады, сагыш белән өртелгән тантаналы җитдилек алды. Шушындый төсмерне Артем армиядә, алар полкының присяга бирү тан-

танасына кунакка килгән фронтовик генерал йөзендә күргән иде.

Шушы никах мәҗлесеннән соң Артем төш күрә башлады. Гадәттә, зур бер эш башларга әзерләнгәндә яки дулкынланып берәр вакыйга көткәндә керә ул төш.

Имеш, Артем атта чаба. Үзе генә түгел, җайдаклар ташкынында. Алар шулхәтле күп, меңәрләгән тояк астында җир тарттырылган тире кебек гүләп тора. Артем, хәтта, йөзгә бәрелгән тыгыз җирле, ат авызыннан чыккан күбекнең биткә ябышып калуын тоя. Тоташ ирләрдән торган бу масса ниндидер бер тыеп булмаслык ярсу һәм алга бару омтылышы белән берләштерелгән. Бу агымны – моны Артем физик тоемлау дәрәҗәсендә сизә – тыю, туктату мөмкин түгел. Тәннең бөтен күзәнәкләре уянган, ул үзенең гаять зур эшләргә сәләтлелеген, көч һәм җитезлекнең биниһая югарылыкка ирешүен тоя. Һәм аңа рәхәт, кулындагы кылыч аның кулының дәвамы, сул яктагы калкан һәр мизгелдә аска, йә өскә, йә теләсә кайсы якка хәрәкәт итәргә әзер.

Тагын шуңа игътибар итте ул: аның һәм янәшәдә нәкъ шундый хис белән орган салып җилдерүче аркадаш ирләрнең уң җиңнәре җилкәгә хәтле сызганып куелган. Башта моның ник шулай икәнен аңлый алмый интекте, соңрак, очраклы рәвештә, В. Ян псевдонимы белән иҗат иткән В.Г. Янчевецкиның «Нашествие монголов» дигән трилогиясеннән, засадада торган татар сугышчыларының, ыргылып чыгып, инде паникага бирелгән, куркудан үзен белештермичә кача башлаган дошман өстенә ташланып, турый башлагач комачауламасын өчен җиңнәрен сызгануларын белеп, исе китте.

Мондый төш күргән иртәләрне Артем күтәренке күңел белән уяна һәм көне буе арыны белмичә эшли, катлаулы мәсьәләләрне дә җиңел генә, уйнап кына хәл итеп ташлый.

Гөлдания белән яши башлагач, Валя тегеләй дә, болай да гаеп табарга тырышып карады. Барып чыкмады. Килен уңган иде, чисталык ярата, пешергән ашлары тәмле иде. Каенанасы белән әйткәләшмәде, «әти», «әни» дип авыз тутырып эндәште, елмаюын кызганмады, һәр нәрсә белән килешеп, «ярар» дип кенә торды. Бары бер тапкыр Гөлданиянең иреннәре кысылды, зәңгәрсу күзләре хәрәкәтсез калып, яшел төскә керде. Олы уллары туып, Валя исемне «Иван» дип тәкъдим иткәч булды бу хәл.

– Юк, – диде килен тыныч, әмма хәвефле тавыш белән.

– А почему, – дип гадәтенчә чәпчи башлады Валя, – что, Али, Мали будем называть?

– Юк, – дип кабатлады Гөлдания, – Эдуард. Роберт мөмкин, Альберт ярый, татарча да, урысча да булмасын.

Һәрвакыт тыныч Степан урыныннан кискен кузгалды:

– Гульдания дөрес әйтә, – башка вакыттагыча Гуля димәде, – Гульдания дөрес әйтә, аныңча эшлибез.

– Нигә син гел аны яклыйсың? – Валя да кире кайтмады, – венчание булмады, исем дә әллә нинди. Нинди җен утыра синдә?

– Татар җене, – Степан сүз беткәнне аңлатып, залга юнәлде, – әти ягыннан бабай татар булган минем. Әнә, – хуҗа Артемга ымлап, елмаеп куйды, – ничек диләр әле татарлар: җан тартмаса да, кан тарта. Малаең, татар килене алып кайтты бит…

Ренат куштылар. Борынгы римлыларда киң таралган исем булган. Авылга кайткач, Артем Ренатның атларга озаклап карап торганын күргәне бар. Атлап йөрешләре үзгәрә малайның, песи кебек сак баса башлый, үзе исә тегеләй-болай йөргәненә йөренә һаман атка якынлаша.

Кан тартамы, җанмы…



*Алмаз Хәмзин 1947 елның 18 сентябрендә Түбән Кама районы Ташлык авылында туа. «Зәйтүнәм», «Өмет», «Миләшкәем», «Туган көн», «Сине көтәм» кебек популяр җырлар авторы соңгы елларда чәчмә әсәрләр дә иҗат итә. Аларның кайберләре «Идел» журналында басылып та чыкты. Бу көннәрдә 70 яшен билгеләп үткән Алмаз абыйның укучыларыбызга бүләге бар: яңа гына табадан төшкән «Себер Мәҗнүннәре» повестен тәкъдим итә.*

## Алмаз Хәмзин

# СЕБЕР МӘҖНҮННӘРЕ

*Әдәби-биографик бәян*

### КЕРЕШ СҮЗ

Казан. Бишбалта бистәсе. Алмазлар ишегалды. Өстәл. Мул табын. Рөстәм белән Алмаз шашлык кыздыра, Хәмзә исә Данил белән Азатны тыңлап утыра. Тегеләр шулхәтле үзәкләрне өзеп, елый-елый сөйләшә, хәтта Хәмзәнең дә күзләрендә яшь бөртекләре чагыла. Данилнең җаны бигрәкләр өзгәләнә:

– Барачакмын мин аның янына! Ул минем мәңгелек мәхәббәтем! Оныта алмыйм, күз алдымнан китми…

Хәмзә берни аңламыйча Азатка карый.

– Кая барырга маташа ул, кем янына?

– Себердә калган мәхәббәте инде…

– Һаман шуны сагынамы?

– Күңеле нечкәргән чакларда гына…

– Шулхәтле матур идемени соң ул кыз?

– Дөресен әйткәндә, гаҗәп иде!

Данил, онытылып, һаман өстәлне төя:

– Яратам мин аны, яратам!!!

Азат:

– Хәзер хатынын мактый башлый ул. Дөресен әйткәндә, хатыны күпкә чибәррәк аның!

– Кылана гынамы?

– Шайтан белсен…

Азат аны юатырга керешә:

– Бетеренмә әле, Данил, хәзер ул син күргән кыз түгел инде. Егерме җиде ел үткән бит! Егерме җиде ел! Кияүгә чыгып, тәпән хәтле тазаргандыр, мыек та чыккандыр үзенә… Биш баласы, ун оныгы бардыр…

– Юк, алай димә, ул мине көткәндер…

– Әйе, көтте ди! Син аңа бер хәбәр бирмә, ә ул сине көтеп ята, ыһы!… Әнә, мин дә шулай уйлаган идем үземнекен. Чакырдым Казанга. Самолеттан каршы алырга бардым. Төшүчеләр арасыннан эзлим – юк аңа охшаган кеше. Башта ук янымa бер юан хатын килеп туктады. Инде самолеттан чыгучы калмады – минеке юк. Ә теге хатын тора да тора.

– Кого встречаете? – ди.

– Одну девушку, – дим.

– Девушке сколько лет? – ди.

– Около сорока, – дим.

– Как вас зовут? – ди.

– Азат, – дим.

– Ә минеке – Зөлфия, – ди.

Менә сиңа мә! Танымадым мин аны. Ул да миңа шикләнеп карап торган иде, нинди мужик икән бу, дип… Чүтеки чирек гасыр вакыт үткән бит! Гел яшь калып булмый… Каян танысын ул мине – бүксәле ирне. Теге чакта бит мин

сөлек кебек утыз яшьлек буйдак егет идем... Әйтәм ич, үзем дә танымадым. Ресторанга кереп ашап-эчеп, сөйләшкән булып утырдык та, кире самолетына озаттым. Аны да, әйтер идем инде, нәрсә өмет итеп килгән ул бу хәтле җиргә?.. Башсыз хатын дип әйтмәс идем үзен — Түбәндәге бер район роносында эшли икән. Өч баласы буйга җиткән, кайсы өйләнеп, кайсы кияүгә чыгып тормыш корганнар. Үзе ялгыз калган — ире авариягә эләгеп харап булган... Җәлләп утырдым инде — аһ-ваһ килеп...

Азатның сүзе беткәч, барысы да тынып калды. Кемне кызганырга белмәссең — Себердән нәрсәдер өмет итеп килгән ханымнымы, әллә, үзе сөйләгән хикәятеннән моңсуланып калган Азатнымы?.. Язмыш нечкәлекләре дип әйтик тә, үткәннәрне һәм алда күрәчәкләрне язмышка сылтыйк. Шулай юатыйк үзебезне.

Рөстәм барысына караганда да җәмгыятькә уңайрак җайлашкан. Университетта алган белеме буенча филолог булса да, хәзерге профессиясе башка — ул юл төзү оешмасы җитәкчесе. Көн-төн эштә, авторитеты югары. Әмма кайберәүләр кебек борын чөеп йөрми. Әле дә менә яшьлектә Себердә концерт куеп кайтулары турында китап язуларын үтенә.

Бүген дә, кыздырган шашлыкларын өстәлгә куйгач, шул турыда тагын бер мәртәбә сүз кузгатты:

— Мин китап язуга җаваплы карарга кирәк дип уйлыйм, — диде ул. — Безнең яшьлектә мавыгуыбыз, без яшәгән еллар һәм үткән юллар, үзебез өчен генә түгел, киләчәктә безне алыштырачак яшьләргә бик тә әһәмиятле булыр иде. Без үзенчәлекле музыкаль төркем булдык. Безнең милли эстрадага үз карашыбыз бар иде. Без аны үзебезчә барлыкка китердек. Безне яраттылар, ә бәлки, безнең язмыш белән кызыксынучылар да бардыр... Хәмзә абый, әйдә, алын әле шушы эшкә!

— Мин каршы түгел, — диде Хәмзә. — Чынлап та, бу сезнең балаларыгызга, оныкларыгызга, туганнарыгызга кирәк. Сез бит, үзегез дә сизмәстән, зур эш башкарган егетләр.

Шулчак Азат, гадәтенә туры килмәгән тыйнаклык белән, кулын күтәреп сүз сорады:

— Ә Уйфикер белән Гөлчәчәкне нишләтәбез? Себергә барганда безнең төркем составында алар да бар иде бит...

— Әйе, Хәмзә абый, сиңа бу кешеләр белән очрашып алырга кирәк булыр.

— Кемнәр инде алар?

— Аларны табып булырмы икән хәзер, — дип шикләнеп куйды Алмаз. — Уйфикер — Фәннәр Академиясендә халык авыз иҗаты белән шөгыльләнүче фән кандидаты. Шунда микән ул, әйтә алмыйм... Ә Гөлчәчәкне табып була, ул Казан мәктәпләренең берсендә завуч. Аның белән проблема килеп чыкмас — адресын бирермен.

— Сезнең белән Себердә ни эшләп йөрде инде алар?

Сүзгә Данил кушылды:

— Гөлчәчәк — ансамбльнең төп җырчысы иде. Чибәр... Бик моңлы тавышлы, безнең белән бергә университетта укыган студент-филолог.

— Ә Уйфикер?

— Анысы Татарстанның кояш чыккан, Башкортстанның кояш баткан ягындагы районның бер авылыннан Казанга килеп, Мәдәният институтында сигез ел укып та һаман шуны бетереп җиткерә алмаган, әмма галим булырга хыялланучы бер адәми зат иде. Төгәлрәк итеп әйтсәк, халык авыз иҗаты җыеп йөрүче...

— Сузма инде, турысын әйт, Данил, — диде Азат. — «Аферист!» диген.

Көлештеләр. Килештеләр.

Данил: «Хәзер сүземне бетерәм», — дигән шикелле ишарә ясады да тагын берничә җөмлә өстәп куйды:

— Безгә килеп эләгүенең сәбәбе — Гөлчәчәкнең сөйгән егете иде ул. Себергә бергә баруны кирәк тапканнардыр. Дүрт егеткә ышанып чыгарып җибәрергә курыккандыр Гөлчәчәкне әти-әнисе. Шикләнмәслек тә түгел шул — егетләрнең асыллары җыелган ансамбльгә — йә берәрсе Гөлчәчәктән хатын ясап куймас дип кем ышандыра ала?!

— Казанда ук кармак салучылар булды инде кызга... — дип Данилнең сүзен бүлде Рөстәм, Данилнең үзенә карап.

— На что намекаешь? — диде Данил, серле көлемсерәп. — Үзеңне бел! Син дә кысылып йөрдең әле анда!

— Кайда?

— Гөлчәчәктән күзеңне алмый идең инде. Онытылып, авыз суларыңны агызып карап

торган чакларыңны күп мәртәбәләр күргән булды.

– Юкны сөйләмәсәнә! Карап торсам ни булган? Мин аның сылулыгына гына соклана идем…

Үртәшүне Алмаз туктатты:

– Дөресен әйткәндә, Гөлчәчәккә беребез дә битараф түгел идек, шулай бит, Азат абый?

– Шулай… Мин үзем дә…

– Нигә тынып калдың?

– Фольклорчысы артыннан ияреп йөрмәгән булса…

– Ну, ну…

– Университетын укытып бетереп…

– Нишләр идең?.. Нишләр идең?..

– Фольклорчысын бик яратса да…

– Әйтеп бетер инде?!

– Туй үткәрер идек…

– Кем белән?

– Кем белгән…

– Уф, алла… ну шушы Азат абыйны!

– Уйфикере белән! Ярамый кеше арасына керү, егетләр, ярамый! Һәм кермәдек тә… Безгә дә булмады, фольклорчысына да, авылына кайтты да, беренче сөйгән яры белән ярәшеп, әнә, Казанда ду килеп балалар үстереп яшәп яталар. Молодец Гөлчәчәк!

Хәмзә язылачак әсәрнең сюжет җәелешенә һәм эчтәлегенә бай материаллар булачагын тоеп, куанып утырды. Ара-тирә егетләрнең сүз көрәштерүләренә кушылгалап, көч-куәт биргәндәй, эче катып көлгәләде, җитди сораулар биргәләде – шуларны язгалап утырды.

## СЕБЕРГӘ СӘЯХӘТ. ПОЕЗД КУЗГАЛДЫ.

1990 ел. Август. Поездга утыруга, Рөстәм ниндидер аңлашылмаучанлык халәтендә куаныпмы, әллә пошыныпмы, сүз башлады:

– Себергә барабыз, егетләр! – дип баш бармагын күтәреп күрсәтте. Шәп эш кылабыз, барысы да әйбәт булачак дигән ишарәсе ул аның. Озак та үтмәде, имән бармагын селкеп тора башлады. Нигә шулай иткәнен сүз белән аңлатмый. Бәлки… саграк булыйк, җәмәгать, диясе киләдер…

Аппаратураларын пассажирларга комачау итмәслек урыннарга урнаштырып бетергәч, юлга алган ризыкларын өстәлгә бушаттылар да уфылдап урыннарына аудылар.

Алмаз сумкасындагы тавык йомыркаларын кая куярга урын таба алмагач әйтеп куйды:

– Күкәй ашатырмын дигән идем, монда бар икән инде…

– Иртәгә әрчербез, – диделәр аңа.

– Бозылыр дип куркам.

– Ике тәүлек чуртым да булмый аңа, – диде Азат, яткан җиреннән.

– Ярар, алай булгач, торсын!

– Шикләнсәгез, үзем ашармын, – дип кабатлады сүзен Азат.

Вагондагы пассажирлар шау-гөр килеп урын-җир көйли. Проводницадан җәймәләр алалар. Күрше бүлемтектә урнашкан Гөлчәчәк белән Уйфикер дә шул эш белән мәшгуль. Әле берәүнең дә ризыкка нәфесе юк. Егетләр мамыгы чыгып торган тишек-пошык, таплы матрасларын җәйгәннәр дә, тышсыз мендәргә башларын тигезмәс өчен кулларына ятып уйланалар. Һәркем үз дөньясына чумган.

Азат телгә килде:

– Себергә, заманында татарның иксез-чиксез дәүләтенең бер почмагына барабыз! Күчем ханның кырык ел падишаһлык иткән җирләренә!

– Ә сез беләсезме, «себер»нең татар сүзе икәнен? – дип сүзгә кушылды Данил. – Мин аны Һади Атласиның «Себер тарихы»ннан укыдым.

Әлегә кадәр аппаратураларның кайсы кайда икәнен тагын бер мәртәбә барлап йөргән Азат, вагонның коридорыннан ук җавап кайтарды:

– Мин дә күз йөртеп чыктым ул китапка. Анда Әбелгазый исемле бер елъязмачы фикеренчә, Себер исеме белән аталган җирләр бар. Мәсәлән, Әбелгазый «Әбир-сәбир» дигән икесен атап үтә. Кыргыз җирләрен шуңа кертә. «Әбир-Сәбир» дип йөртелгән урыннар Селенкә, Енисей, Амур елгалары тирәсендә булырга тиеш.

Озак кына бу сөйләшүгә катнашмый утырган Алмазның да тавышы ишетелде:

– «Әбир-Сәбир» – хуҗасыз җир мәгънәсендә булырга тиеш. «Әбил-Сәбил» дип кыстырып куя торган «тегенди-мондый» әйтелешле сүзләр татарда бар бит ул…

Азат аның җөмләсе тәмамлануын көтеп тә тормыйча сөйләп китте:

– Атласи фикеренчә, Сибирия дип аталган өлкәнең көньягында яшәүче төрки кабиләләр кешесез булган төньяк тарафларын Әбил-Сәбил дигәннәр…

Күптәннән эндәшми утырган Рөстәм йодрыгы белән өстәл төеп утыра башлады:

— Сак булыйк, егетләр! Сак булыйк! Себер — Себер инде ул — Әбил-Сәбил булып куймыйк...

Башкалар аңа, бу сүзләрең белән ни әйтмәкче буласың, дигәндәй карап тора башлады. Рөстәм бераз егетләрне карашы белән сөзеп утырды да:

— Күчем ханның язмышын беләсезме? — дип сорап куйды.

Азат аңа җиңелчә генә карап:

— Беләбез, беләбез, — дип җайлы гына котылмакчы иде.

Рөстәм:

— Ермакны кайда үтерделәр икән? Шул төшне күрәсе иде... — диде.

— Нәрсәгә инде ул бандит сиңа? Юлбасар! — дип җаваплады Азат. — Суга баткан ул, тончыккан! Ермак иң әүвәл Дон, Идел, Хәзәр диңгезе буйларында халыкны талап йөргән. Соңрак Кама буйлап югарыга сәфәр иткән, Строгановлар утарына килеп җиткән. Ул еллардагы иң бай токымнар алар. Строгановлар аны, талавыннан куркып, яхшы кабул иткәннәр. Ермак ярты ел чамасы шунда яшәп, андагы халыклардан Себер хакында күп нәрсәләр ишеткән. Менә шушы хәбәрләр Ермакта Себерне талап шактый байлык җыярга мөмкин икән дигән уйны тудыра. Һәм ул Чусовая елгасы буйлап югары таба — Сибириягә сәфәр итә.

— Сибирия шул Әбир-Сәбирме инде ул? — дип әңгәмәгә әле моңа хәтле Гөлчәчәге белән мавыгып утырган күрше бүлемтектәге Уйфикер килеп кушылды.

— Әйе, шул инде. Ермакның башында Сибирияне Русия кул астына кертү уе бөтенләй булмый. Аның нияте — фәкать ул җирләрне талау, баеп йөрү генә... Йөри торгач, Ермак Чусовая елгасының бер кушылдыгына ялгышып кереп китеп адаша һәм шуннан чыга алмыйча азаплана. Шунда кышларга туры килә аңа. Ермакның үзе белән өч йөзләп казагы була. Ул аларны бүлеп-бүлеп, тирә яктагы авылларны талау өчен җибәрә башлый. Таланган байлык исәбенә казаклар кышны җиңел кичерә. Ләкин сугыш кораллары Строгановта гына була һәм Ермак кире шунда кайта. Шулхәтле күп кешене ашату һәм коралландыру бик авыр булуын аңлатып, Строганов каршы килеп маташа. Әмма сораган нәрсәләрен бирмәгән очракта казаклар Строгановның үзен һәлак итәчәкләрен уйлап, риза була. Бу турыда Иван Грозныйга ишеттерәләр. Патша, Строгановка бик ачуланып, ярлык җибәрә... Ярлыкта нәрсә язылганы безгә мәгълүм түгел. Сизүемчә, гел сүгенүдән торганга, аны берәүгә дә күрсәтмиләр булса кирәк...

Азат стакандагы чәен йотып алды да сүзен дәвам итте:

— Ермакка Чусовая елгасы буйлап сәфәр итү бик авыр була. Чөнки елга сай, сәфәр — суга каршы. Ул төрле кушылдыкларга кереп-кереп карый, аңа башта Тубыл елгасына, аннан Иртешкә чыгарга кирәк була. Йөдәп бетә. Инде гаскәре дә биш меңнән өч меңгә кала. Аның сугышчылары авылларга еш бара һәм ашамлыкларын талау белән генә канәгатьләнмичә, халыкның әйберләрен дә алып кайта башлыйлар. Чакырылмаган бу кунаклардан котылу өчен ул тарафлардагы җирле халык — вогуллар һәм татарлар бергәләшеп хәрәкәт итәргә карар бирә. Шул тирәләрдә тереклек итүче бер татар мирзасы татар һәм вогуллардан төзелгән гаскәре белән казакларга һөҗүм ясый һәм аларны качарга мәҗбүр итәләр.

— Русия салкыннары Наполеон белән Гитлерны да дөмектерде, Себернеке — Ермакны куыргандыр, — дип куйды Рөстәм.

— Каты салкыннар гына түгел, кайбер татар бәкләренең гаскәре дә Ермакка тынгы бирмәгән. Ләкин татарларның уклы-җәяле сугышчылары утлы мылтыклы Ермак юлбасарларына каршы торырлык көчкә ия булмаганнар. Хәтта мылтыкның коры тавышы гына да татарлар белән вогулларны качырыр өчен җиткән.

Ниһаять, Ермак Чинки дип аталган татар шәһәренә килеп җитә. Ишеткәнегез бармы андый шәһәрне?

— Юк, — диеште барысы да.

— Белмисез шул. Хәзерге Төмән ул. Ермак менә шул Чинкины да басып ала. Ул анда кышларга ниятли. Төрле якка казак төркемнәре туплап җибәреп, татарлардан азык-төлек һәм башка кирәк- яракларны алып кайтырга куша. Җибәрелгән казакларның кайберләре Тубыл елгасы буендагы «Тархан Кала» шәһәренә чаклы киләләр.

Менә шул чагында Күчем хан казакларга каршы торыр өчен гаскәр җыярга керешә. Яз

башында ук Ермакка каршы алты татар морзасының кешеләре Тубыл белән Тора елгасы кушылган җирдә аны сагалап торалар. Сугыш берничә көн дәвам итә. Ермак җиңә. Чиксез зур малга ия була. Үзләре белән йөртерлек нигъмәтләр галәмәт күп булганлыктан, күбесен җиргә күмеп калдыралар.

Күчем ханның Ермакка чынлап әһәмият бирүе менә шушы хәлләрдән соң башлана.

– Нигә шул бандитны җиңәрдәй көч җыеп булмасын ди инде? – дип, Данил кызып китте. – Җә, ярый, мылтыклары булмасын ди, берничә тапкыр күбрәк гаскәр белән пыр туздырып атарга була бит. Кара болыт кебек ябырылып киләсең дә бөтенесен таптап изәсең…

– Изәрсең, бар… – диде Азат. – Тиздән Ермакныкылар Күчем ханның Таузан исемле бер түрәсен әсирлеккә төшерә. Ермак аннан Күчем хан хакында мәгълүмат җыюга ирешә. Моны Күчем хан белеп ала да бик тирән хафага төшә. Һәм үзенең башкаласы – Искерны ныгытырга керешә. Татар, вогул, остяклардан зур гаскәр җыя, аның башлыгы итеп Мөхәммәткол исемле кешене билгели. Күчем Мөхәммәтколга Ермакны Сибириягә кертмәскә әмер бирә.

Бу вакытта Ермак Баба Хәсән исемле татар авылына килеп җитә. Менә шушы урында Мөхәммәткол идарәсендәге татар гаскәре казакларга хөҗүм итә. Әмма татарлар ничек кенә тырышмасын, урыслар барыбер өстен чыга. Мөхәммәткол качып котыла.

Шуннан соң урысларга талау өчен тагын да күбрәк мөмкинчелекләр ачыла. Карача исемле бер шәһәрчекне кулга төшерү алар өчен бигрәк тә уңышлы була – монда Ермак бик күп алтын-көмеш һәм асылташларга юлыга. Ә бит бу чакта Ермак кул астында биш йөздән аз гына артык казак калган була.

Ниһаять, Күчем бөтен гаскәре белән, елга аркылы сай җирдән чыгып, төн караңгысында казаклар өстенә һөҗүм итә. Урысларның барысын кырып бетерәләр. Шулар арасында, һич шөбһәсез, Ермак та була.

– Уф, ниһаять, башына җиткәннәр! – дип җиңел сулап куйды һәммәсе.

– Еллар үтә тора, – дип дәвам итте Азат. – Инде монда Мәскәүдән җибәрелгән Иван Мансуров фамилияле чукынган татар җитәкчелегендәге гаскәр килеп, урыс тәртипләре оештырып йөри. Инде падишаһ Фёдор Себер бае Лугай идарәсендә булган алты шәһәрчектән ясак алмаска ярлык бирә. Чулков дигәненә Искердән ерак булмаган урында бер кала төзергә әмер бирелә. Бу шәһәрне төзү максаты – урысларны татарларның һөҗүменнән саклау һәм киләчәктә Себердә эшләнәчәк эшләр өчен нык таяныч итү. Боерыкны җиренә җиткерер өчен Чулков Иртешнең уң кыриенда, Тубыл тамагының каршы тарафында, Искер шәһәреннән ничә генә чакрымнар түбәндә бер кала төзи башлый. Менә шушы кала хәзерге Тубыл шәһәре инде.

– Казанны яулар өчен дә Явыз Иван Свияжск каласын төзи бит. Боларга да шундый ысуны кулланган икән.

– Шулай булып чыга инде… Себердә, татар ханлыгы уртасында Тубыл шәһәре барлыкка килә. 1590 еллар инде бу… Ә бу вакытта Күчем хан үзенең бәхетен тагын сынамакчы нияттә берничә мәртәбә урыслар белән орышмакчы була. Бер тапкыр ул Тубыл шәһәре янына бик якын килсә дә, шәһәргә һөҗүм итәргә батырчылык кылмый. Фәкать шул тирәдәге татар авылларын талап, аларда яшәүчеләрнең күбесен үтерә.

Күчем ханның татарларга мондый мөнәсәбәте аларның урысларга буйсынулары өчен килеп чыга. Ул бу гамәлен башка бик күп җирләрдә дә башкара.

Күчем хан урыслар өчен әле ун елдан артык иң дәһшәтле дошман булып, аларга һич тынгы бирмичә, сугышлар алып бара. Инде аның бу вакытта барлык туганнары да әсир ителеп, Мәскәүгә җибәрелгән була. Шулар арасында Күчемнең биш улы, сигез хатыны һәм күп санлы кызлары, оныклары да бар.

Күчемнең соңгы хәлләре турында тарихта төгәллек юк. Фәкать шунысы гына мәгълүм: ул үзенең падишаһлык кылган урыныннан ерак булган бер урында тизлек белән вафат булды диелү генә бар…

Егетләр, Азатның лекциясеннән канәгатьлек алу хисендә урыннарына түнделәр. Арылган, ләкин берсенең дә күзен йокы алмый. Себер турындагы мәгълүмат аларның йөрәк тибешен көчәйткән иде. Әйе, уйланырлык та, гыйбрәт алырлык та тарихы бар икән шул татарыбызның. Менә шул чордан исән калган кавемнең

дәвамчылары янына баралар алар. Уйнап кына башлаган эшләренең барышы зур миссия икән бит!

### ДАНИЛ

Данил плацкарттагы өске ятагына менеп кунаклау белән уйга батты. Беренчедән, Азатның шулкадәр мәгълүматлы булуына сокланса, икенчедән себер татарларының нихәтле аяныч язмыш кичерүләре җанын телде, өченчедән, эти-әнисенә Себергә китеп баруы турында хәбәр итмәве борчыды аны. Кирәк бит шундый ахмаклык эшләргә! Әнә, Алмаз поездга утыру белән хат язып салды. Аның кебек, борчылып ятмауларын үтенеп, бер-ике сүз белән генә булса да, кая китүләре турында хәбәр әмәлләсә, җүнле кеше эше булыр иде дә бит, югыйсә. Җә, ярый, соң түгел, берәр җирдә — юл уңае мин дә шулай итәрмен әле, дип үз-үзен тынычландыргандай итте. Ә менә Бөек Себернең хафалы еллары аны еларлык дәрәҗәдә тетрәндерде. Бер уйласаң, безнең Казан ханлыгы язмышы кабатланган сыман бит анда да. Кара инде, алардагы ханлыклар да таркау, бер-берсенә ярдәм итешү юк. Ук белән мылтыкка каршы барып булмый шул. Аннан соң җанын, тәнен, динен, милләтен сатучылар бездә дә күп булган. Кара инде, безнекеләр ханбикәсен көймәгә утыртып урыс патшасына биреп җибәргәннәр бит! Мөлкәтләрен, байлыкларын саклап калмакчы булудан килеп чыккан иң мыскыл гамәл ич бу…

Данил капылт кына стена ягына борылды да йокламак булып күзләрен йомып карады, тирән сулыш алды, йокы ритмына борынын көйләде… Юк… Йокы алмый. Кире әйләнеп, түшәмгә карап ятты. Андагы тишек-тошыклар авылдагы өйләренең түшәм тактасындагы ботак эзләрен хәтеренә төшерде. Үзен белгәннән бирле алар аңа таныш. Ул алардан әнисенең күзләрен төсмерли иде, әле бер тактасында әтисенең колагына охшаганын да тапкан иде ул.

Кисәк балачагы искә төште. Әтисе баянчы иде. Данил ул вакытта башлангыч сыйныфта укый. Балалар үсә, бәлки менә минем уйнаганны күреп өйрәнеп китәрләр дигән ният белән алгандыр инде ул баянны. Баштарак баянда уйнауның кызыгын тапмады Данил. Әтисен тыңлап утыра иде инде. Өченче сыйныфка күчкәч, кызыксыну килә башлады ахрысы, әтисеннән әле бер көйне уйнап күрсәтүен, әле икенчесенең төймәләренә басып, бармакларын ничек йөрткәнен өйрәтүен үтенә иде. Әтисе дә иренми. «Менә бу телгә фәлән хәтле басасың, менә монысына фәлән тапкыр, шуннан килеп чыга «Әпипә», — ди торган иде. Шулай әкрен-әкрен кереп китте ул баянга, яратты аны.

Кызыксына башлавының сәбәбе бар. Район смотр-конкурсларында катнашырга мәктәптә баянчылар ансамбле оештырдылар. Менә шунда катнашып, дуслары белән бергә уйныйсы килде аның. Биш-алты малай иде инде алар. Утырсалар, баяннан әле башлары аз гына күренеп тора. Сәхнәгә башта баяннары чыга, аннан, баянга ияреп, үзләре күренә. Шулай итеп, Арча районының Пионерлар йортында чыгыш ясый башладылар. Шуннан үсә-үсә, яшүсмер яшенә җиткәч бер-берсе белән ярыша-ярыша кызлар биеттеләр. Кызлар да кем уйнаганга чыгарга сайлана. Монда язылмаган законнар китә — кем матуррак уйный көйне, шул — ас! Кызлар мактап та ала үзләрен.

Күрше малае Фердинанд исенә төште. Ул хромкада шәп итеп уйный. Сыздырып «Тамчыгөл» не уйнап җибәрүе була — берничә малай кушылып җырларга тотына. Авыл яшьләренең шулай төннәр буе җырлап урам әйләнүенә кызыгып эшләде инде алар аны. Күршеләрендә генә Мәрьям апа яши. Ул чыгып: «Оятсызлар, көпә-көндез, урам егетләре кебек, әле борын астыгыз да кипмәгән көе!..» дип сүгеп ыргытты. Чынлап та, алар бит әле мәктәп балалары гына… Мәрьям апаларының ачулануы, бәлки, аның ул чакта кәефе юктан яки авырып торганнан гына булгандыр. Бәлки малайлар ямьсез итеп җырлаганнардыр… Югыйсә, алар үскәндә кич белән клубтан кайтканда, гармун уйнап капка төбендә җырлап утыру гадәте бар иде. Су буйларында, тыкрыкларда егетләр-кызлар бер-берсенә такмаклар әйтеп, ярышып уйныйлар иде. Авыл халкы менә шул чакларны сагына хәзер.

Аннан соң авыл туйларында икешәр гармун белән җырлату модасы китте. Туйга чакырганда кияү егет көчлерәк уйнаучыларны сайлый. Ул вакытларда әле туйлар өйләрдә үтә. Шулай икешәр гармун яки баян белән мәҗлесләр үткәрү күңеллерәк, дәртлерәк иде.

Менә шундый музыка юнәлеше педучилищеда да дәвам итте аның. Сигезенче сыйныфны бетергәч андагы баян классына барып керде. Атаклы «Егетләр» вокаль ансамблендә училищены тәмамлаганчы йөрде.

Монда килүе укытучы буласы килүдән түгел иде инде. Әтисе шулай теләде. Әйтергә кирәк, әтисенең улын кем итү фикере гел үзгәреп торды. Заманасы да әллә нинди буталчык булгангамы шунда... Ул Данилне хәрби итәргә дә уйлады. Ә менә сигезенче сыйныфны тәмамлагач «Арча педучилищесы белемне бик әйбәт бирә, башта шунда укырсың, аннан соң үзең карарсың, югары уку йортының көндезге бүлеген бетерерсеңме, читтән торып укырсыңмы — синең эш, ләкин педучилищедан диплом алып чыгасың!» — диде.

Ни дисәң дә, «Егетләр» ансамблендә йөрү Данилгә беркадәр дан-шөһрәт бирде. Анда ул ике тапкыр Бөтенсоюз халык иҗаты фестивальләре лауреаты исемен алды. Телевидениедә чыгышлар ясады. Халык аны күрде, таныды. Кызлар да аңа икенче төслерәк — ягымлырак карыйлар сыман тоела башлады. Ничектер, артларыннан ялынып йөрүләр бетте, үзләре өерелеп йөриләр, сайланасың... Ләкин беренче күз төшергән кызлар барыбер истә кала. Мәктәптәгесе... Була бит шундый балалык мәхәббәте. Ул чакта мәхәббәт дип аталган нәрсә кызларның чәчен тартудан башлана. Аның ул бервакытта да чәчен тартмады, чөнки ул алгы партада утыра иде. Матур кызга бөтенесенең күзе төшә. Кызлар иртәрәк өлгерә. Хәтерендә эле, ул кыз борылып-борылып аңа карый иде...

Аннан соң хәтерендә калган: фотога төшерәләр иде Арчадан килеп ул чакларда. Мәктәптәге балалар бер-берсе белән фоторәсемнәрен алышалар. Данилнең күзе төшкән әлеге кызга бер классташ малай фотосын биргән. Ай, аның күңеленә тиде бу хәл! Аңа күп малайлар фотоларын тәкъдим иткән, ләкин ул берсенекен дә алмаган, ә тегенекен алган һәм... Данилнекен. Их, сөенгәнен күрсәгез! Гәрчә ул кызның кулын да тотып караганы булмады бит. Сөйләшергә дә ояла иде. Ул кыз аның әнисенең туган авылыннан иде. Алар гомер буе аралашып яшәде, соңрак әлеге кыз аның белән университетта бергә укыган егеткә кияүгә чыкты. «Без бит соң өлгерәбез» дип үзен тынычландырырга ярата торган булып китте Данил, йөргән кызларының бер-бер артлы кияүгә чыгып баруларына көенеп...

Әйләнеп-боргаланып ята торгач, Азат белән Алмазның моның янына беренче мәртәбә килеп танышулары искә килеп төште. Әйе, ул тулай торак бүлмәсендә үзе генә нәрсәдер уйланып ята иде. Көндезге вакыт. Ишек шакыйлар. Керегез, диде. Ике егет килеп керделәр дә, «менә, ансамбль төзергә исәп, син баянда уйныйсың икән, фәлән-фәсмәтән...» дип сөйләп киттеләр. Ризалыгын сорадылар. Ул шундук, ярар, диде. Алар, аңа «барабанчы кирәк» дигәннәр иде диюен. Ну, ярар...

Данилнең ул вакытлардагы Нурәхмәт Мөхәммәтҗанов җырлап йөргән «Болгар» ансамблен, «Заман» ансамблен күргәне һәм ишеткәләгәне бар иде инде. Шуңа күрә, Азат белән Алмаз киткәч, шулар кебек җырлап, уйнап популяр булачагына хыялланып, куанып йөрде. Өзелеп репетицияләр көнен көтә башлады. Әкренләп алары да килеп җитте. Азат аңа барабанда кагарга тактларны өйрәтте. Данил өйрәнгәнен лекцияләр барган вакытта, башкаларга ишетелмәслек итеп суккалап утыра торган иде. Аяк-кул шакылдатып инде. Шыпырт кына. «Туйдырдың инде, достал!» — дип аңа кисәтү дә ясыйлар иде янәшәдә утыручы кызлар кайчагында.

Кызлар дигәннән, аның күз алдына педучилищеда йөргән бер кыз килде. Өч ел йөрделәр алар. Танышулары икенче курстан ук иде. Яз айлары, Даниләр бер спектакль уйнадылар да, ике кыз, киемнәребезне өске каттан алып төшәбез дип, менеп китте. Күзе төшкәне берсе генә. Көтә-көтә, юк та юк болар. Көткән чакта Данил бер фикергә килде: «Кайсы беренче төшә — шуны озатам!» Икесе дә матур бит!.. Карый, көткәне түгел, икенчесе төшеп килә. Ул аңа, әлбәттә, беркайчан да күз атканы да, игътибар итәрлек бернәрсә дә белдерткәне булмады. Шул беренче төшкәне белән китте дә барды. Шуның белән училищены тәмамлаганчы йөрделәр. Аннары — Казан. Университет. Кыз училищеда калды. Аралашулар кимеде...

Данил университетта үзен бөтенләй башка дөньяга килеп кергән кебек хис итте. Аның әле ул вакытта өйләнү турында уйлап та караганы



*«Себер Мәҗнүннәре»: Рөстәм Кубиев, Азат Низамиев, Алмаз Гыймадиев, Данил Гыйниятов һәм Ландыш Шәяхмәтова*

булмады. Кызлар бу мәсьәләдә тирәнрәк уй йөртә. Аларга яхшы егетне эләктереп, тизрәк кияүгә чыгу беренче урында тора. Кая аңа: әле укуны бетерергә кирәк, эшкә урнашу, торыр урын көйләү — шуларны җайламыйча гаилә кору һич мөмкин нәрсә түгел. Бәлки менә шушы уйлар — әле өлгереп җитмәгәнлек, күңелдә ныклап тупланмаган булса да, барыбер булган инде ул. Шуңа күрә тәүге мәхәббәт кала да кала… Үкенечләре, сагышлары белән…

Аннан соң тагын бер бәләкәй генә сәбәп — ул Арчада укыганда фатирда апаларында яшәде. Дүрт ел буе. Ул бит тулай торакның тәмен күрмәгән, тоймаган — кеше мондый чакта ирекле түгел. Кызлар белән йөрсә дә һәрвакыт вакытында кайтырга кирәк. Ул — контрольдә. Ә монда, Казанда ул бәйдән ычкынган эт кебек йөрде. Тулай торакта тора башлау аның өчен үзенчә яшәү мөмкинчелеген арттырды. Баянчы кешегә мондагы кичке уеннарда бармакларың кабарып, беләкләрең суелып беткәнче уйнап кызлар биетү, урыс әйтмешли — «первый парень деревни» инде. Һәм ул чыннан да шундый дәрәҗәдә иде. Җитмәсә, үзе җырлый да… Кызлардан «отбой» булмады.

Шуңа күрәдерме, беренче мәхәббәт белән мөнәсәбәтләр онытылды. Беренче курска яңалар килә… Барыбер күңелгә ошаган яңа кыз табыла. Университетның Ирнис Рәхимуллин хорына да йөри бит әле Данил. Анда да чибәр кызлар күп…

Азатның матур итеп гырлый башлавы йогышлы булды ахрысы, ул йокыга талды…

## АЛМАЗ

Ләкин бу тавышның моңлы яңгыравы, инде ике сәгатькә якын черем итеп алырга өлгергән Алмазны уятты. Бер уянсаң, йокы кача инде ул. Җитмәсә поезд нигәдер туктаган, станциягә микән — вагонда тынчу. Аны уйлары үткәннәргә алып китте. Әй малай чаклар, үсмер чаклар! Кайларда калдыгыз?!.

Алмазга унике яшь. Авылы Битаманда гитарада уйный белүче бик сирәк. Гармунчылар байтак, ә менә вокаль-инструменталь ансамбль дигән нәрсәне бик белеп бетермиләр. Ул вакытларда андый дөбердәтеп уйный торган ансамбльләрне халык бик өнәп тә бетерми иде. Аларга шул баян да гармун булсын! Ләкин яшьләрнең күңелен инструменталь музыка били башлаган чор давыллап, авылларга хәтле килеп җиткән иде инде. Яшүсмерләргә шундый «җен» кагылды. Әле ансамбльгә исем табу беркемнең дә уенда юк. Исем түгел, әле кулларында бас-гитара булып та, аны уйный белүчесе юк. Тагын ике электрогитара бар. Аның берсендә Казаннан авылга «кеше булсын» дип кайтарылган Марат уйный. Алмазның әтисе дә оста баянчы. Алмаз үзе дә баян тарткалый, тальянда да шактый сиптерә, ә менә аны аеруча гитара кызыктыра.

Менә шулай клубта көйләр дөбердәтеп маташа болар. Үзләренә бик ошый. Ватылса, ап-

паратураларын төзәтә беләләр — нәрсәләредер янса, эретеп ябыштырып та куялар. Әле хәтерендә, күрше авылда концерт куярга кирәк булгач бер малайны махсус алып бардылар. Усилитель эшләми башласа, шул малай корпуска йодрыгы белән сугып торырга тиеш иде. Чынлап та, җырның урта бер җирендә усилитель үкерә башлады. Тегесе — шап — йодрыгы белән!

Ансамбльгә кушылып Лилия җырлый:

*Туй атлары килә, туй атлары,*
*Кыңгыраулы көмеш тояклар…*

Барабанчы егет таяклары белән барабан кырыен текелдәтеп утыра, әйтерсең лә атларның тояк тавышларын чыгара…

Тора-бара ансамбльгә исем дә табылды — «Яшьлек»!

Аннан соң мәктәпләренә пианино алып куйдылар. Анда берәү дә уйнарга өйрәнә алмады. Әмма Битаманның кайбер тәртипсез малайлары, пианиноның капкачын ачып, артлары белән дөбер-шатыр сикерә-сикерә клавишларына басалар иде. Бетте ул шулай ватылып.

Клуб мөдире — элеккеге ферма мөдире. Аңа малайлар бер ярты куялар да клуб аппаратурасын теләсә-кая алып китәләр: мәктәпкә, авылларга. Соңга таба аларның чехолларын да тотып аттылар.

Мәктәптә уза торган күп чаралар да алар кулында иде. Әти-әниләре дә куана — начар юлда йөрмиләр ләбаса. Ләкин Алмазның әнисе аның бу мавыгуын бик яратып бетермәде. Ансамбльдәге малайлар тәмәке тарта, кәрт суга торган булгангамы, улы өчен борчылды. Билгеле, мәктәптәге концертларына барысы да сокланып туя алмыйлар иде.

Клубта тирес исе аңкый, чөнки концерттагы апа-абыйларның кайберләре туп-туры фермадан килгән. Силос исе дә дулкын-дулкын булып борынга бәрелә, сыер савучылар тирәсеннән җылы сөт тәме сизелә, ян-як эскәмияләргә сырылган яшь җилкенчәк кызлардан хушбуйназына коенышлы. Рәхәт. Кинәнеп уйныйсы, җырлыйсы килә. Берзаман, концерт сузыла башлый, арттагы егетләр, абзыйлар тәмәке тартырга клубның «веранда»сына чыга, клуб ишеген ябып тормыйлар… Эчтә нинди икәне билгесез бер ис барлыкка килә. Ансамбльгә барыбер, алар күнеккән инде, аларга һаваның нинди булуы мөһим түгел — кул гына чапсыннар. Һәм чабалар да!.. Алар яшьлегенең бәхете түгелмени бу!

Әйе, Алмаз кебек мыегы чыгып килә торган егетләр бәлки күпләргә үрнәк булганнардыр. Бәлки, мондый концертлар карагач, идән чүпләп симәнке ашаучылар, пәке белән дермантин урындыкларны кисүчеләр кимегәндер. Концерт барган чакта: «Давай, нитегез әле анда!» — дип кычкырып җибәрүчеләргә, пәрдәләрне йолкып төшерүчеләргә, клубка керүче-чыгучыларга кычкырып, мәсхәрәләп торучыларга авызларын бераз йомып торырга мәҗбүр булып, оят дигән нәрсә кергәндер. Ул елларда клуб тирәсендә бер сәбәпсезгә сугышуларның очы-кырые, саны-чуты юк иде бит.

Аларга карата ямьсез мөнәсәбәт әлләни күренмәде. Чөнки ансамбльнең башлыгы — Казанның шома егете Марат. Бәйләнмәделәр.

Берзаман авылга Азат абыйлары кайтып төште. Университетта укучы студент. Ул да Битаманнныкы. Марат Алмазга шылтырата: «Чыгыгыз клубка — Азат абый кайткан!» Азат Алмаздан ун яшькә олырак. Алмазларга хәтле авылда ансамбльләр оештырып, дискотекалар үткәргән бик кызыклы егет ул. Аның Айдар абыйсы авылга «Ява» мотоциклы белән кайткан кеше! Себердә шундый мотоцикл алырлык акча эшләгән дип сөйләделәр. Мең тәңкә тора икән бәясе. Аңа бөтен малайларның күзе тонган иде ул чакта. Авыл өчен дә бик зур вакыйга иде бу.

Җыелдылар клубка. «Нәрсә, бас гитарада уйнаучыгыз юкмыни? — ди Азат, аптырап. — Давай, Алмаз, ал гитараны. Давай, давай ал! Бернәрсәсе юк аның, өйрәтәм».

Азат Алмазны иң беренче Фирзәр Мортазинның «Ява карлар»ына өйрәтте. Ул җырда гитараның өч кенә төшенә басып торасы иде…

Алмаз бас гитарага чын мәгънәсендә гашыйк булды. Тавышы көчле басның, бөтен уйнаучыларны күмеп китә…

«Яшьлек» ансамбленең гомере кыска булды. Мәктәп елларының соңгы мизгелләре сизелми дә үтеп китте.

Алмаз университетка укырга керде. Анда бәрелеп, монда сугылып инде бер елы да узып бара. Начар укымый. Миркасыйм Госманов, Гомәр Саттаровлар, Мөхәммәт Мәһдиевләрдән

белем эстәү — үзе бер дәрәҗә. Инде менә Миркасыйм абыйның булышлыгы аркасында алган аппаратура белән Себергә сәфәр кылалар. Әллә нинди татлы хатирәләрне искә төшерәсе килеп ятса да, күз кабаклары авырая башлады аның.

…Кичен биш стакан чәй эчкән Рөстәм исә урынында боргаланып ятты ятты да, бәдрәфкә юл тотты. Аның үтеп барышлый өстәлдәге кашыкны кулы белән идәнгә бәреп төшерүе Алмазның уйларын үзгәртте — башында Рөстәмгә бәйле сюжетлар кайнаша башлады. Болар — студент. Туксанынчы еллар. СССР таркалган. Илдә кризис. Бөтен нәрсә талонга. Стипендия аз. Киенергә кирәк, ашарга… Акча табарга кирәк. Кемдер вагон бушата, кемдер редакцияләрдә эшли. Алар Рөстәм белән — ипи заводында. «Цивилизованный» эш табарга кирәк. Чүтеки алар Казан дәүләт университеты студентлары бит. Рөстәм Алмаздан ике яшькә зуррак. Армиядә булып кайткан.

Ипи бушаткан вакытта боларның башына бер уй килде. Төнге сменада эшләгән вакытлары. Бу уй, Рөстәмнең алагаем зур камыр мичкәсен кырырга дип шуның эченә кереп киткәч тагын да ныгыды. Мичкә чамадан тыш зур булып чыкты. Рөстәмнең шуны кырып чыккандагы кыяфәте бик куркыныч иде: «Без гомер буе шушындый пычрак эштә эшләрбезме икәнни инде?» — диде ул…

### РӨСТӘМ

Рөстәм әлеге дә баягы идәнгә төшкән кашыкны үзе дә сизми тибеп җибәрде. Кашык плацкартның түрендәге тимер җылыткычка бәрелеп бүлектәге бөтенесен уятты.

— Нишләп йөрисең? Йокла! — дип Рөстәмгә ачуланып куйды Азат. Бераз торгач вакытны сорады.

— Әллә тагын… — диде аңа Рөстәм җайлы җавап табып. — Сәгатем юк.

— Сәгатең булса студент булмас идең, — диде аңа Азат. — Тегеләр нишли?

— Кемнәр?

— Мәхәббәт күгәрченнәре.

— Уйфикер белән Чәчәкне әйтәсеңме?.. Тыныч кына гөрелдәшәләр.

— Әле йокламаганнармыни?

— Әллә йоклап уянганнар инде, әллә бөтенләй күз йоммаганнар…

— Бераз йоклап алсалар комачауламас иде, алдагы көн мәшәкатьле. Син дә ят, әле торырга вакыт күп.

Рөстәм, ике кулын да баш астына куеп, аякларын чалыштырып урынына сузылып ятты. Хәзер йокыга талып буламы соң? Йөрәк кузгалган, күңелгә борчу кергән. Борчу дип, ипи заводында интегеп эшләп йөргән вакытлар түгел инде түгелен. Ни дисәң дә, чиста эш, җанга ятышлы. Ләкин алда билгесезлек — Себердә аларны ни көтә? Моңа җавап табу кыен — алдагысын бер Ходай гына белә. Ни булса да дуслар янәшә: рәхәте дә михнәте дә уртак булыр. Күчем вакытындагы Ермак шикелле бандитлар юктыр әле. Заман башка… Үзебезнең татарлар янына барабыз — күңелләрен күрергә. Себергә изге миссия белән барабыз бит дип куанып куйды ул. Дуслары шәп, менә дигәннәр! Инде кайчаннан бирле аларның ярдәмен тоеп яши Рөстәм.

Алмаз белән дуслашуы шул икенче курста булды. Аңа хәтле ул университетның өстәмә группасында укый башлаган иде — татар бүлегендә. Алар ундүрт малай, ун кыз иделәр. Менә шушы малайларны, бер ел үткәч, җыеп армиягә алып киттеләр. Һәм болар, хезмәт срокларын тутырып, Алмазлар группасына кайтып төште. Алмаз ансамбль оештырырга маташып йөри, ләкин кеше табалмый иде.

Рөстәмгә дә карап-карап йөрде дә Алмаз, беркөнне сүз катты:

— Син берәр инструментта уйный беләсеңме?

— Беләм, — диде тегесе. — Хромкада. «Алмагачлар»ын уйныйм.

Рөстәмнең зур плюсы бар — акча эшләргә маһирлыгы, үҗәтлеге җитәрлек. Мишәр егете бит. Ипи заводына эшкә урнашулары да шул акча өчен иде инде. Алмаз Рөстәмне бас гитарада уйнарга өйрәтмәкче булды: «Берние юк аның, үземне дә өйрәттеләр». Рөстәм башта ышанмыйчарак торды. Аннан ризалашты: «Ярар, идеяң кызык», — диде. Бәләкәй генә буйлы булуга карамастан, дуслары күп Рөстәмнең. Шул чәтрәннәр баскан бөтен физфакны, геофакны. Тулай торак тулы чәтрәннәр. Рөстәм Алмазны үзе ашыктыра башлады. «Әйдә, музыкантлар эзлик инде», — диде. Менә шунда инде Алмазның исенә Азат абыйсы килеп төште.

Киттеләр болар Азат янына. Идеяләрен сөйләделәр. Алмаз университетта иске аппаратуралар барлыгын әйтте. Рөстәм «ремонтласаң, уйнарга була» дип өстәде. «Ярар, мин сезне өйрәтермен дә аннан соң үзем юкка чыгармын», — диде Азат. Ул төнне алар бик озак сөйләштеләр һәм шуның нәтиҗәсе — Рөстәм Азат бүлмәсендә торып калды. Акча түләмичә генә яши башлады ул шунда. Рәхмәттән башка сүзе юк Рөстәмнең Азат абыйсына.

### АЗАТ

Рөстәмнең шундый уйлар белән йоклый алмый яткан чагында Азат, юрганын башыннан бөркәнеп, буйдак тормышының озакка сузылуын һәм аның сәбәпләрен анализлый иде.

Югыйсә, музыка белән җенләнүе шул кызлар каратыр өчен иде бит. Гел аның өчен дип тә әйтеп булмый. Гитара — кыз түгел, әмма үлеп шуңа гашыйк булды ул.

Авылда дәү әнисенең курае бар иде. Кемдер алып килгәнме аны… Берәү дә белми, хәтта дәү әнисе үзе дә. Агачтан ясалмаган ул, нәрсәдән икәнен дә ачык әйтеп булмый — флейта. Ниндидер язуы бар тышында — нимесчә. Берәү дә уйный белми шунда. Азат берәүгә дә белгертми шунда уйнарга өйрәнде. Бервакыт кунаклар килгәч, сүз иярә сүз чыкты, кем курайда уйный белә, диләр.

Азатның уйнавын күргәч, кунакларның күзе маңгайга менде. Әбисе соңыннан шул курайны үзенә бүләк итте.

Аннан соң аны беренче класста укыганда ук гармунга утырттылар. Әтисе дә уйный белә. Әнисенең әтисе Сәләх бабасы да бик яхшы гармунчы булган. Ике яктан да — каннан килгән ахрысы. Үсә төшкәч аның күзе гитарага төште. Ул ансамбль дип хыялланып йөри башлады. Берзаман авылларында ансамбль дә оешты. Абыйсы башлап йөрде инде.

Шул вакытта Казаннан кайткан студентлар авылда сыерларга комплекс төзи башлады. Азат кебек сигезенче-тугызынчы класс малайлары боларны күзәтеп йөриләр иде. Студентлар кичен урамга чыгып гитарада уйный. Алардан кызыгып, Азатның абыйсы Айдар әтисеннән гитара алуны сорады. Алдылар. Абыйсы уйнамаганда тик тора бит инде ул. Гитараның буш чагын күрде дә Азат уйнагандай итте. Беркөнне абыйсы кайтып керсә, энесе әллә ниләр кыланып, кылларын чиртеп утыра. Тотты да бу, гитарасын бикләп куйды. Яшерен әйбер гел кызыктырып тора бит ул. Шунда абыйсы гитарасын биккә куймаган булса, бәлки Азат аңа әйләнеп тә карамас иде. Ачкычын табып ачты да уйнады, ачты да уйнады. Абыйсының кайтып килгәнен күрсә, өеннән чыга да кача иде.

Тора-бара ул абыйсына караганда остарак уйный башлады.

Берзаман абыйсы мәктәптә ансамбль оештырам дип хыяллана башлады. Директорга керделәр. Ул вакытта моңа ике мең сум чамасы акча кирәк иде. Мәктәпкә каян килсен ул хәтле сумма? Ярты машиналык акча бит бу. Шуннан инструментларны үзләре ясарга тотындылар. Пионер барабаннарыннан барабан әмәлләделәр. Тәлинкәләрне болай ясадылар. Фермада төзелеш гөрли. Анда сыер абзарларына һава суыра торган торбалар куялар. Менә шуның калайларын кисеп, эретеп ябыштырып, уйнарга яраклы тәлинкә килеп чыкты. Әле җилләтү өчен кулланыла торган суырткыч калаеннан зур барабан ясамакчылар иде. Анысы килеп чыкмады.

Аннан соң авылда «Айфара» дигән ансамбль туды. Бу 1977—1978 еллар. Башта аның исеме «Айфәри» иде. Абыйсы Айдар, Фәрит, Ришат исемнәреннән алынган баш иҗекләрдән.

Азат шул ансамбль тирәсендә кайнашып йөрсә дә, аны анда алмадылар. «Елап беттем, үзем боларны барабанда уйнарга өйрәтәм, гитарада аккордларны ничек басарга икәнен күрсәтәм», — дип искә ала ул шул чакларны. Инде ахырдан, үгетләп-нитеп бик озак җәфалангач, алдылар тагын. Азат, малайлар белән кибетләргә йөреп, «звукосниматель»ләр сатып алып, аларны гитараларга куеп мәш килделәр. Менә шулай итә-итә интегеп җыйды алар ансамбльне.

Аннан соң университетка укырга килде, андагы атаклы Ирнис Рәхимуллин хорына йөрде.

Ә бервакыт, укырга йөрмәгән өчен, Азатны университет тулай торагыннан кудылар. Мондый тәртипсезлек буенча беренче урында Ркаил Зәйдулла, икенчедә — Ләис Зөлкәрнәй, өченчедә — ул иде. Әле дүртенчесе дә бар — Ләбиб Лерон. Куалар инде, гомумтәртипне санламагач. Җитмәсә, КПССка да кермәгәннәр. Шуннан соң ул якын танышы — Галимҗан Гыйль-

манов ярдәме белән, Калинин урамындагы икенче трест тулай торагына урнашты. Шунда оешкан ансамбльгә йөрде — барабанчылары булмаганга, аны барабанга утырттылар. «Менә шулай такылдатып утыр», — диделәр.

Тиз өйрәнде ул ритмны. Ритмны гына түгел, барабанда уйнауның үз рәхәтен, тәмен һәм бик күп мөмкинчелекләрен ачты үзенә Азат. Бер уйласаң, кайчак башкалар кушылып уйнамаган чакта да, барабаннарны суга-бәрә, тәлинкәләрен чыңлатып, җырлап утырырга була икән бит.

Синтезаторына да үз тырышлыгы белән өйрәнде ул. Аннары ансамбльгә Вахит исемле егетне алдылар. Ну тавыш та инде үзендә! Әгәр чын-чынлап вокал белән шөгыльләнсә халыкара конкурсларда лауреат булыр иде. Физик, шул өлкәдә җенләнә.

Тиздән ансамбль зур бер фестивальдә чыгыш ясады. Уйнап җибәрделәр, Вахит гөрселдәтеп тавышын салды. Жюриның тыңлыйсы да килми торган, арыган чагы иде. Башларын боларга таба борып, авызларын ачып, нәрсә бу дигәндәй, шаккатып карап тора башладылар. Егетләр тагын тавыш өстәделәр — өч тавышка яңгыраталар! Вахит сыдыра гына әлеге «Пастушок» дигән урысча җырны. Азат аңа яхшы гына аранжировка ясаган иде. Аннан соң итальянча җырлап җиппәрделәр. Шул җырга тулай торак мужиклары алга чыгып типтерә башлады, бераз тамак чылатып алганнар ахрысы, бииләр, сызгыралар. Жюри әгъзалары шаккатты. Ләкин беренче урынны барыбер аларга бирмәделәр. Гран-при биргән ансамбльдәгеләр бөтенесе профессионаллар иде.

Университетның татар бүлеген тәмамлаганнан соң аны юллама белән туган районына җибәрделәр. Аспирантурага керергә дә исәбе юк түгел иде Азатның. Укытучысы Альберт Яхин да: «Ник кайтасың?» — дип муеннан алгандай үгетләп тә карады, югыйсә. Ул бит мифология буенча бик шәп итеп диплом яклаган иде. Яклавы булды — шундук югалтты да. Урлаганнар. Соңыннан белде ул аның кем эше икәнен…

Шуннан соң Азат Биектауга укытучы булып эшкә урнашты. Аннары Рөстәм, Алмаз… Хыяллары тормышка ашты — тәки оешты «Сердәш»!

«Сердәш» белән беренче концертлары ул замандагы сугыш чукмарлары оясы — Коркачыкта булды. Анда аларның дусты, Илдус исемле мишәр малае да барды — үлеп сугышырга ярата, теләсә кайсы вакытта, бәйләнсеннәр генә! Яхшы сугыша. Илдус билет сата. Группировкалар чоры. «Текә» малайларның бушка керәсе килде. Гадәтләнгәннәр. Ничек итсә итте, кертмәде аларны Илдус.

«Төп әйбер — юмор! — диде Азат. — Кешегә юмор кирәк, кеше күңелле итеп ял итәргә килә, җырлыйсың-нитәсең — анысы бик важный түгел…»

Халык дәррәү кул чапты, егыла-егыла көлде. Скетчлары да берсеннән-берсе кызык иде: «Бетләр», «Һәйкәл», «Солдат»…

Концерттан соң Коркачык малайларының берсе болар янына килде:

— Сез магнитофон җибәрдегез! Фонаграммага җырладыгыз. Нишләп алай итәсез?..

Килүен үзе генә килде, әмма артында — иллеләп группировщик тора иде.

Рөстәм һич курыкмыйча каршына чыкты моның:

— Әйдә, бәхәсләшәбез! Аппаратураны яңадан корабыз да…

Рөстәм теләсә нинди конфликтны бизнеска бәйли. Теге сугыш чукмары эшнең кая баруын чамалады бугай — сүрелде. Аппаратураны кабат корырга туры килмәде… Егетләр Коркачыктан исән-имин кайтып җиттеләр.

Шул концерттан соң хәйран гына итеп акча өләшкән иде Азат аларга. Егетләр икенче көнне университетка укырга такси тотып барганнар. «Хәерчеләр баеган», — дип уйлап куйган иде Азат ул чагында үзалдында көлемсерәп.

Уйфикер белән Гөлчәчәкнең бертуктаусыз күрше бүлектә пышылдашып ятулары Азатның чын-чынлап эчен пошыра башлады. Әйе, кемдер гырлый, кайсыдыр саташа, уфтана, кемдер бәдрәф юлын таптый — аларга игътибар салмыйсың. Ә болар, үзеңнекеләр, һаман такылдыйлар. Инде Гөлчәчәкнең тавышы ишетелми дә — тегесе, үрдәк шикелле — бак-бак-бак! Ичмасам, күршеләрендәгеләр кисәтү ясасыннар иде. Хәер, аларга ике дөнья — бер морҗа дигәндәй, кичен байтак кәеф-сафа корып утырганнар иде бугай шул. Шуның тәэ-

сиредер — кымшанып та карамыйлар. Бәлки әле бу, ике гашыйкның төне буе чөкердәшүе, күгәрчен гөрләшүе булып, йокыларына шифа гынадыр. Шулай бит, кайберәүләр йоклаганда радио куялар, шуның тавышына изелеп йоклап китәләр, сүндерсәң — шундук уяналар.

Азат, ахрысы түзмәде, торып яннарына барды: «Давай, йоклагыз!» — диде. Тегеләр йокладылар дисезме? Юк. Аерым-аерым үз уйларына күчтеләр…

### УЙФИКЕР. ГӨЛЧӘЧӘК.

Уйфикер әле генә Гөлчәчәккә сөйләгән сүзләрен кабат анализлап ятты. Ул Азатның Себер ханлыгында кайнаган вакыйгаларга бик үк объектив булмаган карашын тәнкыйтьләде. Ягъни мәсәлән, Ермакның үтерелү вакыйгасы дөрес түгел, диде. Урыс елъязмаларында Ермак үлми, ул исән кала диелгәнне бердәнбер дөрес факт итеп, бераз мактанып алды. Гомумән, Азат тарихта бик сай йөзә, әле ярый, Казан ханлыгы турында сөйләмәде, югыйсә бөтенләй наданлыкка баткан булыр иде дип, Гөлчәчәкнең колагына пышылдый-пышылдый дәрәҗәсен күтәрде.

Әмма бу сүзләргә карап кына Гөлчәчәкнең Азатка булган яхшы карашы тамчы да үзгәрмәде. Уйфикернең сүзләрендә ул бары тик көнчелек хисләре генә тойды. Әйе, Гөлчәчәк соңгы елларда Уйфикердән читләшүен, яшьрәк вакыттагы акылын югалтып сөю тойгысының кимүен сизә. Ул бервакыт бөтенләй бетәр, мөгаен… Инде өч ел йөриләр, бер-берсен яхшы ук беләләр дә кебек. Гөлчәчәк Уйфикерне барлык кимчелекләре белән яратса да, ахрысы, берсен кичерә алмас — нигә ул «Әйдә, өйләнешик» дими? Югыйсә, кияүгә чыгачак бит инде ул аңа… «Әй, язмыш ни язган — шул булыр», дип Гөлчәчәк, Уйфикер ятагына арты белән борылды да стенага карап күзен йомды.

Уйфикер исә бик озак йокыга китә алмады. Ул үзен Гөлчәчәккә ияреп баручы ролендә итеп кенә тоя иде. Иртәгесен, Тубылга барып җиткәнче, Азат кебек, халык авыз иҗаты темасына галимнәрчә лекция укыячагын мәҗбүриләп куйды. Әйе, Уйфикер бу мәсьәләдә байтак тәҗрибә туплаган кеше. Гомеренең беренче көннәреннән үк халык иҗатын белеп, күреп, шул дөньяда кайнаган малай. Хәтерендә, авылларының Түбән очында, кичкырын, маллар көтүдән кайткач, сыерлар савылып эш беткәч, апа-әбиләр капка төбенә чыгып утыралар иде дә, балаларын, оныкларын авыз гармунына «Әннәгидер геннәем» дия-дия такмаклап биетәләр иде. Кемнәрнеңдер радиосы бар. Җәйге кичтә тәрәзәне ачып куялар да, Казаннан кичке концертны көчәйтеп, урамга яңгыраталар. Алар өе каршына, урындыклар куеп, халык җыела. Зифа Басыйрова, Рәшит Ваһапов, Гөлсем Сөләйманова җырларын тыңлап, аларга кушылып җырлыйлар иде.

Үсә төшкәч, әтисе аңа гармун алып бирде. Күрше аксак Рәхимҗан абыйсы янына барып, «Әпипә», «Бишле биюе»н өйрәнде ул. Аннан соң аның белән бергә күп мәҗлесләрдә, концертларда парлап уйнап йөрде әле алар. Мәктәптә дә аңа тиңнәр булмады гармунда уйнарга. Ләкин шул гармуннан башка бүтән музыка уен коралын үз итә алмады шул. Әмма халык авыз иҗатына мәхәббәте кимемәде. Сигезенче классны тәмамлау белән Алабуга культура-агарту училищесына барып керде. Исәбе — клуб директорлыгына уку иде. Бетерде ул аны. Авылына кайтып клуб мөдире булып эшләде. Ләкин авыл советы рәисе Җәмил белән килешә алмау сәбәпле, Казанга юл тотты, мәдәният институтына укырга керде. Һәр җәйдә Себернең төрле өлкәләренә экспедицияләргә чыгып, халык авыз иҗаты җыябыз дигән булып, концертлар куеп йөрделәр. Студентка акча кирәк бит. Шулай җәйләр буе акча эшләп йөрисең дә, кышын шул акчага яшәп ятасың. Ягъни, сыер кебек, көне буе карынга азык җыясың, ә кичен шуны күшисең.

Узган ел атаклы фольклорчы, композитор Котдус Хөснуллин җитәкчелегендә Пермь өлкәсенең Барда якларында бер төркем язучы, журналистлар белән йөрделәр. Язучы, Барда якташлык җәмгыяте җитәкчесе Рәшит Ягъфәров, фәннәр Академиясеннән Сәлим исемле галим, шул як кияве — «Шәһри Казан» газетасы баш редакторы Хәлим Гайнуллин, композитор Марат Хөснуллин да бар иде. Бик хозурланып, бик горурланып, бик шәп булачагын, ашкынып көтеп торачакларын ишетеп чыгып киткәннәр иде алар анда. Хәтерендә: килеп төштеләр районга, ни каршы алучылар күренми, ни ашатучылар… Йөриләр болар авылдан

авылга. Әлбәттә, халык әйбәт, клуб тулы тамашачы. Тик сәхнә артындагы өстәлдә, ашыгып әзерләгән такы-токы кибет прәннекләре, карамель конфетлары…

Уйфикер Рәшит Ягъфәровка:

— Син монда кунакчыллыкның чиге булмаячак, дигән идең, бер дә андый гамәлләр күзгә чагылмый әле. Ягъфәров түгел син — Җафа-һәров булып чыктың, — дип төрттергәләп тә йөрде.

Чарасызлыктан кызык табарга гына торган Хәлим Гайнуллинга да Уйфикердән эләкте. Ул аны:

— Син дә күкләргә чөярлек бөек Гайнуллин түгел — син, гомумән, «Нуль-лин» — диде.

Авыр магнитофонга да эләкте. Инде өченче көн авыллар буйлап чабуга карамастан, әле бер генә дә күңелгә ятышлы фольклорга юлыкмады ул. «Михнәтәфон», — дип атады аны Уйфикер.

Ләкин көн-төн яңгыр яуганнан соң иртән ялт итеп кояш чыккан кебек, район администрациясеннән Сәлим исемле кыяфәткә бик тә ыспай ир-зат килеп тапты боларны. Күрешү белән:

— Нигә башта үзәккә килмәдегез, нигә мине күрмәдегез, нигә шылтыратмадыгыз, фәлән-төгән… — Сүкте боларны. Менә Казанга кайткач зарланып язарсыз әле. Каршы алмадылар, ашатмадылар, дип…

— Юк ла инде… Алай зарланырлык очракларга юлыкмадык бит әле. Фатирлар табалар, чәй, тәм-том һәрвакыт каршыбызда.

— Кибетләрегез дә бай, — дип өстәп куйды галим Сәлим. Канәгатьлелеге йөзенә чыккан, хәер, андый гадәти кызыллык аның йөзеннән инде өченче көн китми. Сәлимнең йөзе — кәефенең әйбәтлеген билгели торган лакмус кәгазе…

Барда Сәлиме күреп тора бит инде. Шундук боларны җыеп бер өйгә алып барды. Баксаң, бу аның туган авылы булып чыкты. Зур гына иркен бүлмәле әлеге йортта аның әти-әнисе тора икән. Исән-саулар. Боларны таныштыргач, Барда Сәлим кунакларны мул ризыклы өстәл артына чакырды. Нинди генә ризык юк монда! Калҗа-калҗа ит, турап-турап куелган тозлы балык, уылдык, ягып-ягып куелган ак майлы ак ипи, алма, чия, кыяр, помидор… Уртада пар чыгарып, бәлеш утыра. Кыстаучы кирәкмәде, бәлешкә үрелү үзеннән-үзе килеп чыкты.

Сәлим, күрешү хөрмәтенә, алдагы көннәрдә Барда җирлегендә очрашуларның уңышлы үтүенә ышаныч белдереп, тост тәкъдим итте.

— Юк, эчәргә ярамый, кичен концерт, — димәкчеләр иде дә, нигәдер әйтмәделәр. Рюмка күргәч үрелергә гадәтләнгән куллар, баштагы уйны тыңлап тормады. Чөнки ачылган авыз хыялга кергән рәхәтлекне төкерек рәвешендә өч мәртәбә йоткан иде. Голт ителгән тавыш кына ишетелеп куйды. Юри чырайны сыткан булдылар, әйтерсең лә беренче тапкыр эчәләр — Барда Сәлимен хөрмәт итеп кенә. Шулай да икенче тостны Казан Сәлименнән башкасы ныгытмады…

Әлеге авылдагы концерт аеруча күтәренке рухта узды. Барда Сәлим, ахырдан сәхнәгә күтәрелеп, рәхмәт сүзләрен әйтте дә, әле бу бригаданың район эшчәннәре алдында, барлык авылларда диярлек концертлар куячакларын белдерде. Әлеге хәбәрне алар үзләре дә белмиләр иде — аптырадылар, шаккаттылар. Ни шатланырга, ни еларга белмәделәр.

Барда Сәлим концерттан соң кунакларны кабат өйләренә алып кайтып сыйлады да Бардага алып китте. Анда аларны кунакханәгә урнаштырып саубуллашты. Үзе дә арыгандыр, өенә кайтып китте.

Уйфикергә аерым бүлмә бирелгән икән. Ул бераз хәл алып уйланыбрак утырды да, башкалар ни хәлдә икән дип, аларны тикшерергә китте. Бүлмәләр һәрберсенә дә аерым булып чыкты. Казан Сәлиме нигәдер боеккан, нидер җитеп бетми ахрысы. Хәлим белән Рәшит, соң булса да, туганнарына шылтыратып булмасмы икән дип почта эзләп киткәннәр икән. Сәлим, Уйфикер юкка гына кермәгәндер дип, сорап куйды:

— Әллә?..

Уйфикер:

— Шулай шул… — диде.

— Берәр җирдә сатмыйлар микән соң?

— Ресторан бар бугай монда?

— Соң, әйдә!

— Кайда?

— Әнә бит, тәрәзәдән утлары балкып тора…

Киттеләр шунда. Кайтып та керсәләр, караватларында ике кыз утыра. Көлешәләр.

— Ә без сезнең кемнәр икәнегезне беләбез, — дип берсе сүз башлады.

— Каян беләсез? Сезне монда кем кертте?

— Анысы неважно, — диләр. — Сезнең икенчегез кайда?

— Күрше бүлмәдә.

— Керсен монда?..

— Юк инде, керсәк аңа керәбез. Безнең эчемлек тә бар.

— У-һу, это великолепно!

Сикереп тордылар да, Уйфикерне ияртеп, Сәлим бүлмәсенә кереп киттеләр һәм караватка менеп, мендәргә кунакладылар. Ха-ха, ха-ха килиләр. Шулвакыт бүлмәгә көтмәгәндә Барда Сәлиме килеп керде.

— Ах, сез инде түргә үк менеп кунаклагансыз! Марш моннан икегез дә! — дип кызларны куарга тотынды.

Тегеләре дә яшен кебек тиз генә ялтырап алдылар да сүзсез-нисез чыгып шылдылар.

Уйфикер белән Казан Сәлиме, берни аңламаган хәлдә калдылар. Ай күрде — Кояш алды булып чыкты. Барда Сәлим егетләргә карап торды да аңлатырга керешге:

— Шулай булыр әле дип уйлаган идем. Ялгышмаганмын икән. Йокларга яткан җиремнән торып, йортына ут капкан кеше сыман чыгып йөгердем. Ярый әле җитештем. Шундый кызлар йөри монда. Килгән-киткән кешеләрне момент эләктерәләр. Соңыннан клиентларының кесәләрен чистарталар. Ярый, тыныч йокы сезгә! — диде дә Барда Сәлим кайтып китте. Егетләр җиңел сулап куйдылар. Казан Сәлим галимнәрчә фикер әйтеп куйды:

— Алла бар ул — Барда Сәлим булганда!

...Соң гына йокыга китсә дә, Уйфикер әллә нинди төшләр күреп бетерде. Нигәдер аны, кулларын артка каерып, Данил белән Рөстәмгә охшаган себер сугышчылары Күчем хан сараена алып кереп, хан тәхете каршына җәелгән келәм өстендә кертеп ташладылар. Башын күтәреп караса, тәхеттә Азат утыра. Киемнәре алтын-көмештән чигелеп төрле төсләрдә елкылдый, башындагы таҗының нурлары күзне камаштыра, карашы усал — шәфкать көтәрлек түгел. Янәшәсендәге гүзәл ханым — Гөлчәчәкне хәтерләтә, әйе, хәтерләтә генә түгел, нәкъ үзе икән. Әллә ул аның турында әйткән тискәре фикерләрен ханга җиткердеме икән? Уйфикер бөтенләй каушап калды. Нигә аны монда алып килгәннәр? Ни гаебе бар? Нигә бер сүз әйтмиләр? Тынлык. Озынча зал. Дивар кырыенда кораллы сакчылар.

Ниһаять, Азат хан телгә килде:

— Әйт минем ялгышларымны?

«Нинди ялгышлар? Нинди өлкәдә? Ханлык белән идарә итүдәме, әллә Себер тарихындагы елъязмаларда булган ялган фактлар турында сорыймы бу?» — дигән уйлар бөтерелеп алды Уйфикер башында. Ул, үтенеп, ярдәм көткән сыман, Гөлчәчәккә карады. Гөлчәчәк, горур башын югарырак күтәреп алды да иреннәренә мыскыллы елмаю чаткылары ясады. «Аңлашылды...» — дип үзалдына әйтеп куйды Уйфикер. Моңа хәтле үз фикереннән беркайчан да тайпылмаган егет:

— Сезнең беркайчан бернинди ялгышларыгыз булмады! — дип куйды.

Ләкин хан, баш бармагын аска төбәп:

— Ялганлыйсың! — диде. Аның ачулы көчле тавышы зал буйлап аргы почмакларга хәтле таралды. — Алып китегез! Дөреслекне аңлатканчы...

Ханның соңгы сүзләрен ул тыңлап та, аңлап та бетермәде. Аны дөмбәсли башладылар. Ул кычкырырга тотынды.

— Коткарыгыз!..

— ...Нәрсәгә кычкырып ята бу? Уян әйдә, тор! — дип Данил белән Рөстәм аның кабыргасына төрткәләүгә уянып китте Уйфикер.

— Нәрсә акаеп карап торасың? Безне танымыйсыңмы әллә, төн чикерткәсе? — диеште егетләр көлешеп. — Гөлчәчәгең юыну бүлмәсенә китте.

Әле һаман җүләр кеше шикелле акаеп торган Уйфикергә Азат:

— Здрасьте! — дип әйтеп карады. Башкалар да аныңча исәнләшеп алдылар. Уйфикер өстендәге юрганын алып атты да:

— Төш күреп, саташып беттем. Аллага шөкер, исән икәнмен әле, — дип тастымалын алды да, өйдә киеп йөри торган җәйлы башмагын алырга онытканга күрә, ботинкасының үкчәсенә басып, лаштор-лоштыр сөйгәне янына китте. ■

*Дәвамы бар*

**Арслангали**

# Наласа мәзәкләре



***

Татар теле дәресе бара. Укытучы укучыларга җөмләләр төзергә куша. Укучылар дәррәү килеп җөмләләр яудыра:
– Балалар йөгерә. Балалар урамда уйный. Балалар укыйлар.
Укытучы аптырап:
– Укучылар, уйлап карагыз әле, балалардан башка мисал юкмы әллә?
– Бар. Хайваннар.

* * *

Дәрес бара. Укытучы балалардан сорый:
– Укучылар, сез гөмбә җыярга йөрисезме?
Бер укучы сикереп тора да:
– Әйе, без ял саен урманга гөмбәгә барабыз.
– Нинди гөмбәләр җыясыз инде?
– Әти күрсәткәннәрен.

* * *

Укытучы балага ачуы чыгып кычкыра:
– Тик утыр, алайса «икеле» куям!
Укучы тыныч кына:
– Ә нишләп шулай аз?

* * *

Бер урыс егете татар кызына өйләнә. Берничә атна үтә. Марҗа кодагый урамга чыгып, күршесенә сөйләнә икән:
– Хай, соседка, моего сына санакка утырттылар.
– Үләм, күрше, җанымдыр ла, арт яклары нишләп беткән соң? – дип сораган аптырап. Марҗа, хәйран калып, үзенчә аңлатып бетергән.
Бактың исә, аның улын сөннәткә утыртканнар икән.

* * *

Авыл абзые Казанга барырга уйлый, ләкин анда ничек йөрисен белми икән. Моны авылның акыллы хәйләкәр агайлары өйрәтеп җибәрә.
Ярар, абзый Казанга барып җитә, трамвайга утыра. Билет ала да компостер янына килеп, өйрәткәнчә, әйтеп куя:
– Наласадан Гаптери. До вокзала довези.

***

Мәктәптә ишеткәннәр:

*

– Һай, пультыгыз юк шул, булса сүндереп кенә куяр идем...

*

– Дөрес итеп утырдык. Сколиозларны турайттык.

*

– Шүрәле. Аның бөтен җире дә йон белән капланган.
– Нәрсә, әллә күзләре дәме?

*

– Сания Сабировна, сезнең отчествогыз ничек?

***

Шәһәрдән авылга бер кыз кайта. Бу хәбәр егетләр арасында бик тиз таралып өлгерә. Кич белән клубка чыгалар. Шәһәр кызы челт-челт басып йөри, ә егетләрнең күзләре елык-елык килеп тора. Танцылар беткәч, үзен бик авторитетлы дип хис иткән егет кунак кызны озата кайта. Тик егетнең урысчасы чамалырак була.
Капка төбенә килеп җитеп, бераз басып торгач, егет сине кочакларга ярыймы, дип сорарга ниятли:
– Можно держать тебя кругом?



Гөлшат Фәттахова

# ИПЛЕ КӨЛӘ БЕЛӘСЕҢМЕ?

## Ленар Шәех әсәрләрендә юмор-сатира




Соңгы елларда татар әдәбияты мәйданына килгән яңа буын турында еш сөйләнелә һәм языла. Бу күренеш җәмәгатьчелекнең дә, язучыларның да, китап сөючеләрнең дә игътибарын җәлеп итте, яшьләрнең күбесе җәмгыятьтә үз урынын табып өлгерде. Алар арасында Ленар Шәех тә бар.

### ҮЗЕНЕҢ ИҖАТ СУКМАГЫ

Ул шигърият өлкәсендә җиң сызганып эшли. Иҗатында мәхәббәт лирикасы, гражданлык, милли, фәлсәфи лирикалар өстенлек итә. Шулай ук ул балалар өчен дә матур шигырьләр яза, проза, публицистика, әдәби тәнкыйть өлкәләрен дә үз итә. Шулай да Ленар Шәехнең иксез-чиксез шигъри иҗат мәйданында тагын бер юлы, үзе генә аралаган сукмагы, үз өлкәсе бар. Ул да булса – юмор-сатира. Аның бу юнәлештәге эзләнүләре һәм уңышлары аны профессиональ дәрәҗәдә әдәбиятка сукмак салучы яшь әдип дип әйтергә мөмкинлек бирә.

Язучы юмор-сатира жанрында яратып эшли. Аның көлүе – әче, мыскыллы, шәхесне юкка чыгаручан түгел, ә сыгылмалы, ипле, әмма һич кенә дә килешүчән булмаган көлү. Икенче төрле әйткәндә, аның юморы тупас хахылдау булмыйча, зыялыларча, тирән мәгънә салынган эчке елмаю булып тора.

2015 елда шагыйрь, Татарстан Республикасының Муса Җәлил исемендәге премиясе лауреаты Ленар Шәехнең «Бар бездә берәү!..» (*«Рухият» нәшрияты, 256 бит*) дип аталган китабы дөнья күрде. Китапта аның юмор һәм сатира жанрында язылган шигырьләре, пародияләре, юморескалары, монологлары, тормыштан алынган кызыклы вакыйгаларга корылган кечкенә күләмле мәзәк хикәяләре, үзенчәлекле гыйбарәләре тупланган.

### КӨЛӘ-КӨЛӘ ТӘРБИЯЛӘҮ

Шагыйрьнең юмористик әсәрләре нигезендә күзәтүчәнлек, берәү дә игътибар итмәгән вакыйга-хәлнең гыйбрәтле тәмен табу ята. Юмор хисең булу, үзеңнән һәм башкалардан көлә алу – үзе зур бәхет.

Китапка кергән шигырьләр арасында сатирик планда иҗат ителгәннәре бар. «Синең өлеш, минем өлеш» дип аталган шигырендә бу аеруча көчле тоемлана. Колхоз (колхоз җитәкчелеге, рәис дип аңлыйбыз) геройга печән чабарга җир бүлеп бирә. Ике кибәнне күтәреп куйгач, колхоз баштан берсен, аннан икенчесен тартып алып, геройны ярык тагарак алдында калдыра:

*Алып кайттым парсыз кибән...*
*Колхоз тагын миңа килгән*
*(Туймаса да туймый, бирән!):*
*«Җиң сызганып эшкә кереш,*
*Килеп чыкты таныш-белеш,*
*Печән кирәк – синең кибән...»*

Менә шулай шагыйрь колхоз җитәкчелегенең кешелексез эш алымнарына, колхозчының рәис алдында хокуксызлыгына төрттереп ала. Әгәр дә колхозчы үзе чабып, киптереп куйган печән кибәнен бирмәсә, башка ихтыяҗ килеп чыкканда, башын түбән иеп, тагын шул колхоз рәисенә барасын уйлый. Чөнки авылда колхоз рәисе – үзе «патша», үзе «президент». Шул рәвешле, асылда, автор кешене куркырга «өйрәткән» хакимият турында сүз алып бара. Шигырьләре гади сүзләр белән генә язылган булса да, аларда киң

һәм тирән мәгънә ята, чөнки шагыйрь бары хаклыкны, дөреслекне сөйли.

«Чын дөресен әйткәндә…» дигән шигырьдә дә сатирик юлларга тап булабыз. Әсәрдә автор илдәге сәясәткә үз мөнәсәбәтен белдереп, болай ди:

*Артык кирәкми безгә, –*
*Алдынгы илебезгә.*
*Гел читкә чыгартабыз,*
*Чыгарып, югалтабыз.*

*Һәрвакыт арттырабыз,*
*Тауларны тарттырабыз.*
*Берәрсе законны бозса,*
*Тәртип урнаштырабыз...*

Шагыйрь үз әсәрләрендә, көләкөлә, чынбарлыкны сурәтли, җәмгыятьтәге ялгышлыкларга, җитешсезлекләргә төртеп күрсәтә.

Аның максаты – көлә-көлә тәрбияләү. Кытыклый-кытыклый дөрес юлга кертергә тырыша адәм баласын. Әлбәттә, сүз бирелә рухи дөньясы тәмам таркалган, кешелеклелеген югалткан хайвани затлар турында бармый. Аларны беркем, берничек тә – төрмә дә, закон һәм башка чаралар белән дә төзәтеп булмасын һәркайсыбыз белә. Сүз бирелә халыкның ким дигәндә туксан тугыз процентлы турында бара. Әсәрләрендә лирикадан юморга, юмордан ирониягә күчәргә булыша торган үткен чагыштырулар, җанландырулар, арттыру-үткенәйтүләрне актив куллана; әдип көлүендә моңсу юмор, нечкә сатира, пародия кебек жанр формалары еш очрый. Аның лирик герое еш кына үзеннән үзе көлә, әмма шуның артында җәмгыятьтәге һәм кешеләрдәге кимчелекләрне фаш итүе, аларны усал тәнкыйтьләве ачыла.

Ленар Шәех бүгенге яшь шагыйрьләрдән, каләм ияләреннән шигырьләрендә, иң беренче нәүбәттә, өлкән язучыларга карата ихтирамы һәм яшьтәшләренә күрсәткән игътибары белән аерылып тора. Башка бер генә яшь шагыйрь иҗатында да Илдар Юзеев, Гамил Афзал һ. б. кебек шәхесләребезгә багышлап ихластан язылган юлларны ул тиклем очратмассың. Аларга багышланган ихлас шигырьләр әлеге язучыларны күпне күргән зур шәхесләр буларак ачып бирә. Шуның белән бергә Ленар Шәехнең «Бар бездә берәү!..» китабында олуг шагыйрьләргә ияреп, аларның стилендә язылган шигырьләре дә бар. Мәсәлән, карак Сәлим образы Гамил Афзалга, Һади Такташка һәм Габдулла Тукайга ияреп язылган сатирик шигырьләрендә үзенчәлекле итеп бирелә.

Ленар Шәехнең үзе дә нинди жанрга кертергә дә белмәгән шигъри юлларга салынган диалоглар остасы булуын һәм аларда геройларның характерын ачуга гына түгел, ә бәлки герой психологиясенең эчке хәрәкәтен, ягъни аның эчке һәм тышкы көрәш параметрларын күрсәтүгә зур игътибар итүен билгеләп үтәсе килә. Язучының диалоглардан торган әсәрләре шактый. Сөйләшү манерасы, тел байлыгы, сүз сөреше, әйтелгән һәм әйтелеп бетмәгән җөмлә, ымлык, паузалар ярдәмендә автор укучыны иң кыска юл белән герой психологиясенең эчке дөньясына алып керә. Юмор һәм сатира кыскалыкны ярата. Аз сүзле, әмма бай эмоциональ бизәкле. Мондый текстларда «юл аралары» хисләр, фикерләр белән тулы; алар укучы хыялына киң мәйдан бирәләр. Моны «Бар берәү бездә!..» китабына кертелгән диалоглар да раслап тора. Моңа мисал итеп «Ике ахир» шигырен алыйк. Ике дус хатынның телефоннан сөйләшүе бик кызык формада бирелә. Берсе бай эшкуар хатыны – Фәридә, икенчесе – акча, яхшы тормыш күрмәгән Җәмилә. Башта сөйләшү бай хатыны Фәридәнең байлыгы, матур кием-салымы, Франциядән ире алып кайткан тәмле хушбуйлар турында, ә Җәмилә мескеннең ике тапкыр юып төсе киткән халаты, табаны төшкән туфлиләре турында бара, ә инде сүз ирләргә күчкәндә, сөйләшүнең тоны кыза башлый. Бай белән ярлы талашса, барлыгы белән юклыгын әйтер дигән кебек, монда да нәкъ менә шулай:

*«Тапкан кеше!.. Ireңә бит*
*Тартырга да җитми!.. Кит, кит!..*
*Юньле булсаң, ку «өтәш»не,*
*Яңаны ал, мин сөйләштем...» – ди*
*Фәридә.*

Җәмиләсенең дә үз җавабы бар:

*Ireң ташлар әле берәр,*
*Яшь чибәрне ул бик теләр.*
*Калырсың син ялгыз гына –*
*Китеп барыр балдызына...*

Ленар Шәех монда замана чире – байлык артыннан куып, яхшылык, миһербанлылык сыйфатларын, хатын-кызга хас оялчанлык, тыйнаклык хисләрен югалткан Фәридә кебек затларны камчылый да, акчасызлыкка, хәерчелеккә батса да, кешелеклелеген, горурлыгын җуймаган Җәмилә кебек хатын-кызларны кызгана да белә.

Ленар Шәех «Мин – кыска, мин – озын», «Сорап тормады…», «Ярты-ярты… Киңәя?!», «Без карт идек…», «Сәерлек», «Илһамланган мәлдә…», «К»ылашу…», «Бәхетсезрәк…», «Мин», «Салым җыючыларга мөрәҗәгать», «Иң акыллы мәзәкче», «Син моңайма, мәктәп!» һ.б. шигырьләрендә Газинур Морат, Галимҗан Гыйльманов, Рәмзилә Хөрмәт, Лилия Гыйбадуллина, Айдар Җамал, Ләбиб Лерон, Рифат Сәлах, Рафис Корбан, Гамил Афзал, Илнур

Юнысов һ.б. әсәрләренә пародияләр тудыра. Шагыйрь пародияләре белән көн кадагындагы мәсьәләләргә үз мөнәсәбәтен белдерә.

Тематик төрлелеккә килгәндә, Ленар Шәех иҗатындагы бер-береңне кабатлау, шагыйрьлек осталыгы, кешенең рухи халәте, мәхәббәт маҗаралары, кешенең тышкы кыяфәте, яшьлек-картлык мәсьәләсе һ.б. кагылышлы пародияләрнең шигърият үсешен алга этәрүе, мөмкинлекләрен киңәйтүе мәгълүм. Димәк, бүгенге әдәбиятка пародия бик кирәк, дигән нәтиҗә соралып тора. Ә шагыйрь пародияне үстерүгә үзенең өлешен керткән, дип ышанып әйтергә мөмкин.

Авторның әлеге китабында эпиграммаларга да урын бирелгән. Аның эпиграммалары Мәгъсүм Гәрәевкә, Рабит Батуллага, Роберт Миңнуллинга, Мөнир Вафинга, Фәнил Гыйләҗевкә, баянчы Марат Шәйхетдиновка һ.б. багышланган. Бу эпиграммалар аерым шәхесләрнең яки күренешләрнең тискәре якларыннан көлү өчен кулланылмаган, шагыйрьнең һәр эпиграммасының герое булган шәхескә карата дустанә мөнәсәбәт һәм хөрмәт ярылып ята. Мәсәлән: «Робертлар… Рабит» эпиграммасында ул болай дип яза:

*Р. Миңнуллин, Р. Әхмәтҗан,*
*Р. Батулла – Рабит.*
*Иске исеменә кайтса,*
*Олы шагыйрь була бит...*

Ленар Шәехнең юмор белән язган шигырьләре – ихлас һәм кабатланмас. Менә болай ди оялчан егет «Оялам» шигырендә:

*Оялам мин, панимаешь,*
*каты гына.*
*Кызлар кочу кая инде,*
*какуй миңа.*

Әлеге оялчан егет образы «Оялам», «Үбенеп йөрим», «Ходаймы шулай кушкан?», «Шаяртам», «Гашыйк җан», «Костюм кияргә микән?» һ.б. шигырьләрендә урын алган.

Шулай итеп, шагыйрь юмор-сатира өлкәсендә өзлексез эшләп килә. Ленар Шәехтә йомшак, теләктәшле юмор өстенлек итә, шуның белән бергә көнкүреш хәл-әхвәленнән тыш, шагыйрь иҗтимагый тормыштагы ямьсез, гарип күренешләрне дә игътибар белән күзәтә һәм аларны көлү объектына әверелдерә һәм сатира утына тота.

Көлә белеп көлгәнгә һәм белеп файдаланганга да көлү Ленар Шәехнең кулында тормышны раслауның гаять көчле коралына әверелә. Аның хәзерге актуаль социаль һәм сәяси мәсьәләләр белән таныштырган шигырьләре юмор-сатира өлкәсендәге яңа бер иҗат уңышы буларак кабул ителде.

## ШАГЫЙРЬ ИҖАТЫНДА ЮМОРЕСКАЛАР

Ленар Шәех иҗатының иң асыл үзлекләренең берсе – юмор һәм сатира, дидек. Баштан аның бу сыйфаты шигырьләрендә күренде. Юморескаларында исә авторның әлеге таланты чынлап торып ачылып китә. Язучының бу өлкәдәге эшчәнлеге аерым сөйләшүгә лаек. Үз мохитен дөрес итеп чагылдыруга, гади һәм колоритлы итеп, ачык буяулар белән сурәтләүгә зур әһәмият бирә ул.

Кемне генә очратмыйбыз без аның әсәрләрендә: авыл һәм шәһәр кешесен дә, олысын да, кечесен дә; нинди генә һөнәр ияләре юк алар арасында: студент та, мәктәп инспекторы да, күмәк хуҗалык рәисе, полиция хезмәткәре, бай кияү эзләүче кыз да, өйләнергә теләмәгән сазаган егет тә. Нинди генә яхшы һәм тискәре сыйфатлар көлке үлчәвенә салынмаган, нинди генә көлү төсмерләренә тап булмыйбыз без биредә: шаярту, оста сүз уйнату, җиңелчә моңсулык кушылган җылы елмаю – көлемсерәү, рәхәтләнеп шаркылдап көлү, көлдерә-көлдерә елату, көлүнең ирония, сатира төренә күчүе.

Ленар Шәех юморы, беренчедән, үзенең табигыйлеге, ясалмаган булуы, геройлар психологиясенең эчке үсешенә хилафлык китермәве, киресенчә, шуларның эчке хасияте үзенчәлегеннән килеп чыгуы белән күңелне җәлеп итсә, икенчедән, тормышның үзе кебек үк гаять күпкырлы һәм күптөрле чагылышта яшәве белән кызыклы.

Үзенчәлекле эмоциональ тәнкыйть формасы – көлү – комик конфликт нигезендә туа. Комик конфликт үзе вак каршылыклардан – көлке детальләрдән төзелә. Нәкъ менә шул детальләрне бирүдә оттырмаганда гына төп көлү максатына ирешергә мөмкин. Ленар Шәех юморы әлеге киртәне бик җиңел үтә. Әлбәттә, мондый өлгерлек язучының рухи байлыгы белән дә нык бәйләнгән. Шагыйрь үз геройларын кирәк урында күздән яшьләр чыгарлык итеп кызгандыра белә, ә кирәк урында укучының күзеннән яшьләр атылып чykканчы көлдерә дә.

Шулай итеп, Ленар Шәехнең юморескалары безнең көндәлек тормышыбыздагы яшәү рәвешебезне, психологик халәтебезне үзебезгә кызыклы итеп сөйләп бирүгә корылганнар. Елмайта торган юморескалар язу өчен, кешеләрне ярата белергә кирәк. Әсәр геройларының җитешеп бетмәгән яки «артыграк җитешкән» якларыннан үзләрен рәнҗетмичә генә көлү – Ленар Шәех юморескаларының асылы. Алар елмайтып кына калмыйлар, уйлаталар да. Әсәрләрне укыгач, елмаеп яки көлеп куясың да, алай икән, дип уйланып аласың, үзеңнең яшәү рәвешеңә игътибар белән карый башлыйсың.

## ЛЕНАР ШӘЕХ ИҖАТЫНДА МӘЗӘКЛӘР, АКЫЛЛЫ УЙЛАР

Ленар Шәехне язма әдәбиятның иң борынгы жанрларыннан берсе булган мәзәк төренең, бүгенге чынбарлык материалы җирлегендә, аның тематик офыкларын киңәйтүче каләм осталарының берсе дияргә мөмкин. Аның бу төр әсәрләре төрле газета-журнал битләрендә даими басыла килә, хәзер инде аерым җыентыкта нәшер ителә.

Мәзәк – борынгы заманнарда ук туып, безнең көннәрдә дә актив яши һәм үсә торган жанр. Аның төп идея-эстетик кыйммәте тормыштагы төрле тискәре күренешләрне сатира-юмор ярдәмендә фаш кылуы, әдәп-әхлак нормаларын ныгытуга, кешеләрдә, бигрәк тә яшь буында югары рухи сыйфатлар тәрбияләүгә ярдәм итүе белән билгеләнә.

Мәзәкләр, гадәттә, мәҗлесләрдә, күмәк ял вакытларында җыелган кешеләрне бер көлдереп алу, аларның күңелен ачу максатында сөйләнәләр. «Мәзәк – күңел ачкычы» дигән гыйбарә дә жанрның әнә шундый вазифасына ишарә итә.

Шагыйрь Ленар Шәехнең «Бар бездә берәү!..» дип аталган китабындагы мәзәкләренең геройлары нинди генә халәттә дә үзләренең җорлыкларын, тапкырлыкларын җуймый торган зирәк кешеләр булып күз алдына килеп басалар.

Мәзәкләренең бер өлеше Ленар Шәехнең үз авызыннан сөйләнелсә, икенчеләре, өченче зат – автор исеменнән алып барыла. Әлеге беренче заттан сөйләүче герой урынын лирик герой яулый бара. Ленар Шәех әлеге героен (үзен дип аңлыйк) тормыш-көнитешнең төрле ситуацияләренә куя, аны төрле яклап күрсәтә башлый. Мәзәкләрнең беренчеләренә «Ун кызга өйләнү», «Чишенеп каршы алыгыз!», «Якташлар», «Культурный», «Салфетка», «Кем нәрсәдә йөри?» һ.б. икенчеләренә «Лаури!..», «Ленин бабай турында», «Тапкыр җавап», «Селкенеп тора!», «Телим...», «Ярты» дип аталган мәзәкләр керә. Монда Ленар каршыбызга тапкыр, шаян, сүз артыннан кесәгә керми торган герой булып килеп баса. Шуларның берсенә тукталып үтик:

*«Ленар Шәех «Иделем акчарлагы» дигән яшь язучылар бәйгесеннән шигырь язу буенча лауреат исемен алып кайта. Университетка баргач, группадаш кызларына:*
*– Мин хәзер Ленар гына түгел... – ди.*
*– Ә кем?.. – дип гаҗәпләнәләр кызлар.*
*Бераз тын торгач:*
*– «Лаури атлы!...» – дип куя Ленар».*

Сүзне хикмәтле иткән дә, канатлы иткән дә – юмор хисе. Шуңа күрә Л. Шәехнең «Төркем-төркем уйлар»ы Шәүкәт Галиевнең «Хикмәтле сүзләр»ен – чын мәгънәсендә бу традицион жанрны – әдәбиятта хәзерге чорга якынайтып яңарткан традициясен дәвам иттерә дип уйларга мөмкин. Аларның бер өлеше үткен фикергә корылган шигъри парчалар булып яңгырый:

*Безнең илдә гел шулай:*
*Үлгәч кенә син – Тукай;*

*Яктыра...*
*Соңга калган каракны чаптыра.* һ.б.

Кыскасы, Л. Шәех, халык авыз иҗатындагы мәзәк, хикмәтле сүз, мәкаль, әйтем кебек үткен фикерләүгә нигезләнеп, кыска жанр формаларын заманча яңгыратуга, аларны әдәбиятның тулы хокукы белән яшәргә хаклы актив жанр формалары итеп яшәүгә юл тота.

*Мин Ленар Шәехнең «Бар бездә берәү!..» китабында милли, халыкчан юмор белән очраштым.*

*Ленар Шәех – чын мәгънәсендә талантлы, киң колачлы, эрудицияле һәм белемле шагыйрь. Аның бер генә кызыксынмаган, бер генә белмәгән нәрсәсе юк сыман. Авыл һәм шәһәр тормышы турында да, үзенең замандашлары турында да, каләмдәшләре турында да бер үк дәрәҗәдә белеп һәм яратып яза.*

*Ленар Шәехтә йомшак, теләктәшле юмор өстенлек итә, шуның белән бергә көнкүреш хәл-әхвәленнән тыш, шагыйрь иҗтимагый тормыштагы ямьсез күренешләрне көлү объектына әверелдерә һәм сатира утына тота.*

*Юморескаларының новеллистик характерда язылуы аны халык мәзәкләренә якынайтуын, халыкчанлыгын арттыруын күрдем. Иҗатындагы мәзәк, хикмәтле сүз кебек кыска жанр формаларын заманча яңгыратуга юл тотуы күзәтелә. Тормышчан, халыкчан булса да, язучы тупас, пычрак, итәк күтәреп көлдерүдән ерак тора. Язучы гап-гади кешедә матурлык төшенчәсен эзли, таба, үстерә. Шул ук вакытта китапта мин оригиналь, үзенчәлекле Ленар Шәехкә генә хас юмор стиле белән таныштым. Юмор-сатира өлкәсендә Ленар Шәех заманча яңгырашлы, халык авыз иҗатына якын үз стилен булдырырга тырыша. Язучы яшәешнең төрле өлкәләренә үтеп кереп, замандашын, аны борчыган мәсьәләләрне игътибар үзәгенә куя, уңай һәм тискәре күренешләрдән җиңелчә, җитди нигезле итеп яратып көлә дә, бераз камчылап та ала. Ныклы фикерен әйтү өчен дә сатира, ирония, юмор мөмкинлекләрен киң файдалана.*



Әсгать Закиров

# КОШЛАР ҖЫРЫ АК КӘГАЗЬДӘ

## КОШЛАР ҖЫРЫ

Җырым инде төште ак кәгазьгә,
Бушангандай булды күңелкәй.
Ник бакчада һаман кошлар сайрый,
Һаман сайрый кошлар: тышта – җәй.

Без сайрыйбыз, ә син тыңла тагын,
Тыңла да яз тагын берәрне,
Безнең телне аңлый торганнарны
Ишеткән юк иде, диләрме?

Шулай, кошлар, безнең җырлар әгәр
Җилкендереп күңел күтәрсә,
Шуңардан зур бәхет буламы соң,
Моңыбызны берәү искәрсә?!

## УЙЛАРЫМ

Һәрбер уйны барлап, сыйпап,
Тартмаларга тездем пөхтәләп.
Кайберләре тыныч, шаяннары
Йөри гелән чыгып – кергәләп.

Орышамын, ачуланам хәтта
Бармак янап куям кайчакны:
Бераз гына тыныч булыгыз, дим,
Ярамый бит инде шул чаклы.

Бәлки, алар дөрес эшлиләрдер
Кылган гамәлләре – гөнаһсыз.
Җилдән җитез минем шаян уйлар,
Йөгерәләр шуңа тыз да быз.

## КАЙГЫ АГАЧЫ...

Каеннарга килеп күп сыендым,
Кайгы килер диеп тормадым.
Ә җәйләрен барып урманнарга
Каен себеркесе урладым.

Каен дәвалады минем тәнне,
Җанымны да тик ул чистартты.
Өй алдында үсә бер каеным,
Ямьләндерә берсе өй артын.

Каен сүзе кайгы сүзе белән
Мин килешәм, әйе, аваздаш.
Бар уртаклык – бары шунда гына!
Аңлый моны минем гади баш.

Каен белән кайгы бер үк түгел–
Бик ерактыр алар арасы.
Каен безгә бары шатлык бирә,
Кайгы бирә тормыш карасы.

* * *

Эчкерсез бер мәхлуктырмын –
Әшәкелек ятмый эчемдә.
Начарлыкка каршы яхшылыкны
Бүләк итеп йөрим кешегә.

* * *

Югарыга менеп сүзләр алып төшәм,
Тезеп куям шуны дәфтәргә.
Кайчагында бары бер сүз җитми
Иң кирәкле җөмлә әйткәндә.

## УРТАБЫЗДА ШӘМ ЯНА

Кечке өйдә икәү бергә,
Шәмнәргә ут эленгән.
Син дә, мин дә – икебез дә
Читләр белән сөелгән.
Икәү бергә, күзләр күздә,
Тик уртада шәм яна.
Икәү бергә, күзләр – күздә,
Тик күзләрдән яшь тама.
Бер мизгелгә бергә без дә,
Тик уртада шәм яна.
Шәмнән аккан балавыздай
Йөрәктән әрнү тама.
Күрәсеңме, көләч каеннарым,
Кышкы йокысыннан уянып,
Җилне үртәп башын ия-ия,
Кызлар кебек тора елмаеп?

## ӨЧЛЕ ҮЛЧӘМ

Өскә үлчим – өстә түшәм,
Аска төшсәм – аста идән.
Кая төртсәм, шунда тиям,
Чыга алмыйм ябык өйдән.
Түшәмнән соң ничә түшәм?
Идәннән соң ничә идән?
Чыга алмыйм очына һаман,
Надан булып яшәү яман.
Йолдыздан соң ничә йолдыз?
Галәмнән соң ничә галәм?
Үлгәннән соң нишли адәм?
Беләсеңме шуны, бәндәм?




Эльвира Фатыйхова

# ЯЗУЧЫ МАРАТ КӘБИРОВКА АЧЫК ХАТ

**(«КИТАП» БАСМАСЫН БЕР ТӘҮЛЕКТӘ УКЫП БЕТЕРҮЧЕНЕҢ УЙ-ФИКЕРЛӘРЕ)**

*«Марат абый, минем бүген йокы туймады. Сез миңа тагын бер төн тиеш. Һәм көн дә. «Бердәнбер һәм кабатланмас» дип исемләнгән китабыгыз белән шулай бер йокымны урлаган идегез инде, хәзер тагын... Юк, иң элек, кичәге шатлыгым турында әйтергә телим. Беренчедән, моңарчы интернет аша гына аралашып торган язучы безнең редакциягә килеп, шушы китапны миңа тоттыргач, куанычымнан кочаклап үбәсем килде. Кыенсындым гына. Бәхетне «контроль» йозагы артына яптым да, рәхмәт әйтү белән чикләндем. Югыйсә, өр-яңа китапны язучыңның үз кулларыннан алу һәм беренче укучылар рәтендә булу...*

*«Китап»ка килгәндә... Мин тагын депрессиягә бирелдем. Узган китабыгыздан соң да шулай тилмергән идем, хәзер дә шулай ук. Һәр язучының үзгә бер хис-кичерешләр уятуы яхшыдыр инде ул, начар дип әйтмим. Мисал өчен, Фәүзия Бәйрәмованы укысам, системага каршы көрәшү өчен мең тонна энергия җыйгандай булам. Тураебрак басасы, башны горур күтәрәсе һәм һөҗүмгә әзер булып йодрык төйнисе килә. Нәбирә Гыйматдинованы укый башласам, кулъяулык әзлисе булачагын алдан белеп, хәстәрен күрәм. Зифа Кадыйрова белән Рәмзия Габделхаковага да шулай ук дисәм, аларда күз яшьләре дозасы кимрәк. Ркаил Зәйдулланы укысам, борын астыннан ике көн мыгырданып фәлсәфәгә бирелеп йөрим... Күп инде алар. Ә менә сезне укысам, депрессия башлана.*

*«Китап»ны сентябрьдә диңгезгә баргач, комда кызынып ятканда укырмын, дип уйлаган идем. Кичә кайтып кергәч тә, ачкычларны сумкама тыкканда, кул астыма туры килде дә, сөйрәп чыгарып, тумбочка өстенә куйдым. Аяктан салып, баскан килеш кенә беренче битен ачтым һәм... дөньям китте. Әйтми кала алмыйм: беренче биттә үк бик яхшы провокация ясагансыз. «Син бу китапны әле укымассың. Син бит эш кешесе. Анда чабасың, монда чабасың...» дип башлагансыз. Карале, мин әйтәм, бу нәкъ минем турында икән. Китапны укый башлаганда, әнә шулай дип уйлаганымны хәтерлим һәм 253 битне япканда гына өс-башымның алыштырылмаганлыгы исемә төште.*

*Кайбер җөмләләрегезне үземнең блокнотыма теркәп тә куйдым. «Мескен халыкның язучылары бәхетле була алмый», дигәнсез мәсәлән. Яхшы әйтелгән! Милләтебезгә күрә сезнең бәхетсезлекнең күләм-дәрәҗәсен күз алдына китерергә тырыштым. Җәлләдем. Ул урында хәтта еладым да. Чарасызлыктан, мескенлектән. Үземне кызганып... Язучы – ул халык тормышының барометры, дисез бит. Сез шулай бәхетсез булгач, без бит сездән дә бәхетсезрәк булып чыгабыз түгелме? Ул бәхетнең кайчан да булса чүт кенә артачагына өмет юк.*

*Роман эчендә, кешеләрнең китап укымавына ачыну белән тулы монолог, аларның зомбилашуы, техниканың тиздән безнең белән идарә итә башлауга ишарәте, һәр басылган китап соңгы булырга мөмкин дигән хәсрәти фикерләр буып үтерә дип торам.*

*Төп геройның үз уйларын контрольдә тота алуына сокланып укыдым. Җәмгыятьнең зомбилашмавы өчен, «хисләре һәм акылы белән идарә итә белгән, үз аңына башкаларны үткәрмәслек ихтыярга ия булган затлар кирәк», диюегез дә уйландырды. Мин шундыймы соң? Андый булу өчен нишли алам? Замана чирен ияртмәү өчен кая качыйм?*

*Матди байлык һәм җенси канәгатьлек белән генә «тук» булып яшәүчеләрне тәнкыйтьләү формагыз да кызыклы. Бер карагында, бу роман нәкъ шул аудиториягә юнәлдерелгән, хәтта шуларга яраклаштырылган да. Нишләптер бу урында Жириновский искә төште. Ул да, күптән түгел генә, гаиләдә җенси мөнәсәбәтләр санын тәгаенләргә кирәклеге хакында чыгыш ясаган иде. Әллә аена бер тапкыр гына кирәк диде, әллә елына дүртне – хәтердә калмаган. Артыгы – энергияне бушка сарыф итү, имеш...*

*Уйланулар күп булды, әле дә килеп-килеп чыгып уйландыра. Шуңа, фикеремне йомгаклый да алмыйм. Борчылырга мәҗбүр итсәгез дә, төнемне урлавыгыз өчен рәхмәт! Бу китабыгыз соңгысы булмасын, тагын бик күп төннәремне сезнең китапларга багышлыйсым килә. Әйткәнем дә бар инде, тагын кабатлыйм: сез минем иң яраткан язучым!»*



**МӘДРӘСӘ**
*Дини белемгә яңа мөмкинлекләр*



**ХӘРӘКӘТТӘ – БӘРӘКӘТ**
*Саба хоккейчылары*



**ГОМЕР ИТМЕШ**
*Исемнәрегез күркәм булсын!*

# Мәдәният



**Радик Сабиров**



# КИТКӘН УРЫН БУШ ТОРМЫЙ, ЛӘКИН...

Ильяс Галимов көрәштән китте. Соңгы елларда милли спорт төренең билбирмәс пәһлеваны булып танылган Әлмәт батыры карьерасына нокта куюын җиткерде. Ильясның элегрәк тә чыгышын туктатып торганы булды. Әмма бу юлы ул ныклы карарга килгән. ТР Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы призларына уздырылган көрәш бәйгесендә – 8, Татарстан чемпионатында – 9, Русиянекендә – 7, «Ватаным Татарстан» газетасының каһарман-шагыйрь Муса Җәлил истәлегенә оештырылган турнирында 9 мәртәбә откан, бер мәртәбә дөнья чемпионы булып танылган, мактаулы исемнәре һәм титуллары янына «Татарстан алдындагы казанышлар өчен» орденын алган пәһлеван ул.

Фотолар Ильяс Галимов архивыннан

Әлбәттә, спорт дөньясында спортчы карьерасын тәмамлау уеннары, «ахыргы матчлар» – гадәти күренеш. Ошбу чараларны иң танылган, халык хәтеренә кереп калган спортчылар гына үткәрә ала. Ә татар көрәшендә андый шәхесләрнең берсе, һичшиксез, Ильяс Галимов. Һәм татар көрәшендә шундый чараларны беренче булып та нәкъ менә ул үткәрде. Кичәдә республиканың авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, көрәш дилбегәсен үз кулларында нык тоткан җитәкчебез Марат Готыф улы Әхмәтовның катнашуы бик матур фал булды. Яшьләр эшләре һәм спорт министрының беренче урынбасары, атказанган спорт остасы Хәлил Шәйхетдинов, район башлыклары, үткәннең танылган батырлары – Рәкыйп Хәмитов, Рәшит Сәмигуллин, Фазыл Әхмәтҗанов, Марсель Таһиров, Әүхәт Мөхәммәдиев, Айрат Гилаев, Айдар Хәйретдинов, Зөлфәт Хәсәнов һәм башкалар, танылган тренерлар, сәнгать осталары катнашында узган бу чара чыннан да көрәш дөньясындагы иң матур, истә калган кичәләрнең берсе булды.

## «МАКСАТЫМ БЕР БУЛДЫ – БЕРЕНЧЕ БУЛУ»

**– Ильяс, күпләр түзә алмый: янә көрәшкә чыга. Көрәшми түзә алырсыңмы икән?**

– Мин чыннан да катгый карарга килдем. Үз-үземә сүз бирдем: рәсми ярышларда – Татарстан чемпионаты, Муса Җәлил һәм башка титуллы бәйгеләрдә генә түгел, ә Сабан туйларында да башка көрәшмәячәкмен. Әгәр мондый рәсми чара оештырганмын икән, димәк, көрәшкә чыксам, барысын да алдаган булып чыгам. Әлбәттә, көрәштән китеп тә бетеп булмас, гел көрәшергә омтылыш та булыр, бигрәк тә башлангыч дәверләрдә. Ләкин исәнлек мөһимрәк диган нәтиҗәгә килдем. Гаилә бар, алдагы тормышка планнар бар. Әлегә үзебездә көрәш федерациясендә башкарма директор вазифаларын башкарам. Ләкин тренер булырмын, дип уйламыйм. Бөтенләй башка өлкәдә күрсәтергә исәп үземне.

**– Татар көрәшендә мондый рәсми озату булганы юк иде әле. Күп батырларның келәмнән киткәннәрен белми дә калабыз...**

– Алайса, мин бу нисбәттән дә беренче булам. Легендалар, һичшиксез, матур китәргә тиеш һәм аларны матур итеп озата да белергә кирәк.

**– Инде синнән соң уңышларыңны кабатлардай көрәшчеләр булырмы?**

– Киткән урын буш тормый, әлбәттә. Ләкин бүгенге көндә күрмим шул үземә алмашны. Беренче чиратта, авыр үлчәүне күз алдында тотам. Әлегә бирдә Ульян көрәшчесе Сергей Павлик беренче номер




**«Ильяс Галимов – татар көрәшенең легендасы. Татар кешесе татар буларак, сәламәт буларак, шәхес буларак нинди булырга тиеш дисәләр, Ильяс Галимовны үрнәк итеп китерер идем. Ул – милләт өчен, традицияләре, бүгенгесе һәм киләчәге өчен фидакарьләрчә хезмәт иткән иң татар җанлы егетләребезнең берсе. Аны бик күп яшьләр үзләренә үрнәк итеп китерәләр, олылар аның көрәшенә, матур алымнарына, үз-үзен тотышына соклана. Шундый шәхес булып формалашу титаник хезмәт сорый, моңа ирешү өчен сәләт тә, көч тә, тырышлык та, баш та кирәк. Үзеңнән йомшагракны җиңү – авыр түгел, ә менә үз-үзеңне җиңү – анысы инде сирәкләргә генә бирелә. Ильяс – шундый сирәкләрнең берсе ул».**

***МАРАТ ӘХМӘТОВ, ТР авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры, республиканың татарча көрәш һәм билбаулы көрәш федерацияләре җитәкчесе***



узган ел да Ильясның биле чыгып алды, аннан тезләре борчып торды. Ә шөгыльләнергә кирәк, ансыз уңышка ирешеп булмый. Менә быел да Сабан туйларына марттан әзерләнә башлады ул.

**– Көрәштән китүнең берәр чиге бармы аның, ничек уйлыйсыз?**

– Күпләр оттыра башлагач китә, менә шулдыр инде аның чиге. Дөрес, Ильяска кагылмый бу сүзләр, әле аның оттырганы юк иде. Сәламәтлеген һәм гаиләсен беренче планга куйды ул. Аның күпме тырышканын, шөгыльләнгәнен үзе белә дә, мин генә беләмдер инде. Әйтүе генә җиңел бит ул: тагын Ильяс җиңгән, тагын машина откан... Мин исә аның кадәр тырышлыкка машина гына түгел, автобус та бирер идем.

**– Яшьләргә ничегрәк үрнәк итеп куеп булыр иде аны?**

– Ихтыяр көче көчле анда. Спортзалга, әлбәттә, бар да йөри, барысының да көчле буласы килә, әмма бар да Ильяс кебек шөгыльләнә алмый. Минем шәкертләрем күп булды, ләкин Галимов кебек үзен кулда тотканнары артык булмады. Аның төгәл максаты бар – беренче булу, һәрвакыт җиңү. Һәм ул шул максатка ирешү өчен, кирәк икән, көнен дә, төнен дә тырышачак. Яшьләргә



булып калыр ахрысы. Димәк, шәп көрәшчеләр тәрбияләү өчен шәп тренерлар кирәк. Тренерсыз булмый. Принципиаль, үз эшен белгән остазлар булу сорала. Мин беркайчан да сөйләшүләргә, бүләк бүлешүләргә кысылмадым, чөнки һәрвакыт беренче булырга теләдем. Ләкин бер гаебем булды: Җөри Сабан туенда көндәшемә җиңүне бирдем. Шуннан бик нык үкендем. Чөнки тренерым Салават абый Юсупов бер ел минем белән сөйләшмәде. Шул «гаебем» гомерлек сабак булды.

**– Тренерлардан уңдың син...**

– Әлбәттә. Беренче тренерым – Әдип абый Нуруллин. Нәкъ менә ул мине – Чистай техникум янында тәмәке тартып басып торган җиремнән көрәш залына алып керде һәм көрәшче ясады. 1994 ел иде бу. Бер елдан яшьләр арасында икенче урынны алдым. 1996 елда инде Зәйдә Муса Җәлил турнирында өченче калдым. 1998 елда бөтен турнирларны оттым, Самарада фатирга ия булдым...

**– Легендарлар күп, синең чордашлар арасында да: Гилаев, Хәйретдинов, Әхмәтҗанов, Раил Нургалиевлар... Син алардан ни белән аерылып торасың икән?**

– Безне бер нәрсә берләштерә: көрәш, көрәшкә мәхәббәт, көрәшкә җаның-тәнең белән бирелгәнлек һәм бирелеп эшләү. Тир түкмичә берни дә килми, бик күп шөгыльләнергә туры килә.

## «МАШИНА ТҮГЕЛ, АВТОБУС БИРЕР ИДЕМ»

Ильяс Галимовны көрәштән озату чарасында остазы Салават Юсуповка да берничә сорау белән мөрәҗәгать иттек.

**– Салават абый, Ильяснык көрәштән китәм дигән карарын ничегрәк кабул иттегез?**

– Минем өчен көтелмәгән хәл булмады, чөнки бу турыда инде ул берничә ел дәвамында әйтеп килде. «Мөмкинлегең бар икән – көрәш», дип җавап бирә идем. Көрәш – бик авыр спорт төре. Аның иң куркынычы – җәрәхәт алу, имгәнү. Әнә,

 

**«Легендаларны бер нәрсә берләштерә: көрәш, көрәшкә мәхәббәт, көрәшкә җаның-тәнең белән бирелгәнлек һәм бирелеп эшләү».**

дә шуны телим. Әле менә октябрьдә беренче зур ярышлар башлана. Бүгеннән инде шул ярышларга әзерләнә башларга кирәк. Әгәр дә соңга калмаган булса. Көрәш курчагы атып кына көрәшче булып булмый, практика кирәк, көрәш ярышлары кирәк. Шөкер, бу яктан бүген хәлләр зарланырлык түгел, ел әйләнәсендә бәйгеләр узып тора.

**– Ходайдан бирелгән сәләт белән генә уңышка ирешеп буламы?**

– Ходайдан биргән сәләтне дөрес итеп, максатчан итеп кулланганда гына,ниндидер уңышларга ия булырга мөмкин. Ләкин аның өчен дә барыбер тырышырга кирәк. Менә Айвар Билаловларга, Фәнил Минһаҗевларга, Раил Нургалиевларга Ходайдан сәләт бирелгән иде, шул ук вакытта тынычланып калсалар, спорт залларында биш пот тир түкмәсәләр, алар әллә ничәшәр тапкыр чемпионнар була алмас иде. Бүгенге көндә бигрәк тә, чөнки татарча көрәш, ни генә әйтсәләр дә, профессиональ дәрәҗәдә ул.

Әлбәттә, профессионаллар дигән сүзгә үзем ике яклы карыйм. Миңа да авылларга, Сабан туйларына кайткач, әйтәләр иде: син бит профессионал, әлбәттә, син җиңәчәксең дип. Шунда мин болай җавап бирәм: әйе, үз эшемдә профессионал оста, үз эшемне җиренә җиткереп эшлим. Эштән кайткач, үземдә ихтыяр көче табып, әле спортзалга да китәм. Иртәнге дүрттә торам да, йөгерергә чыгып китәм, ә җидедә инде эштә булам. Ә сезгә кем комачаулый шулай ук шөгыльләнергә? Шуннан җаваплары табылмый иде. Без – барыбыз да Адәм балалары. Мөмкинлекләр дә бер үк, теләкләр дә. Уңышка ирешү-ирешмәүнең генә сәбәпләре төрле булырга мөмкин. Мин дә бар татар егетенә нәкъ менә Ильяс Галимов кебек тырышыгыз, эшләгез, ни булса да кеше булып кала белегез дигән теләктә яшим.



Нәзирә Гыйззәтуллина

# ДИНИ БЕЛЕМГӘ ЯҢА МӨМКИНЛЕКЛӘР

**Татарстанда дини уку йортлары барлыгын белсәм дә, аларның эшчәнлекләре белән аз таныш идем. Язмыш мине 2011 елларда әлеге уку йортлары белән тыгыз бәйләде. Русия ислам институтының уку-укыту бүлеге җитәкчесе булу белән беррәттән, дини уку йортларына укыту-методик ярдәм күрсәтү бурычы да йөкләнде безгә. Билгеле, моңа кадәр Татар дәүләт гуманитар-педагогика университетында, Казан (Идел буе) федераль университетында уку-укыту юнәлешендә эшләп килгән кешегә әлеге эш кара урман түгел. Охшашлыклар җитәрлек, әмма үзенчәлекле яклар да шактый булып чыкты...**



Иң беренче белем баскычы – мәчет каршындагы курслар. Билгеле, биредә тирән дини белем түгел, ә дини тәрбия бирелә, ислам диненең асылы аңлатыла, төшендерелә. Мөгаллимнәрнең күбесе кайчандыр Татарстан республикасы мәктәпләрендә укытучы булып хезмәт куйган, соңрак мәдрәсәләрдә дини белем алган белемле, зыялы ханымнар. Шуны әйтеп үтәргә кирәк: алар бары буш вакытларында «Аллаһ ризалыгы өчен» дип, үзләре алган гыйлемне башкаларга җиткерүче гүзәл, нурлы абыстайлар. Әлеге курслар һәр мәчет каршында диярлек эшли. Монда бернинди мәҗбүриләү, зачет, имтиханнар юк. Теләге булган өлкән яшьтәге кеше дә, бала-чага да килә, тыңлый, өйрәнә, китә.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте тәрбия бирү программалары, дәреслекләр эшләүне, аларга нигезләнеп, дини тәрбия алып баруны һәрдаим контрольдә тота.

Икенче баскыч – мәдрәсәләр. Хәзерге көндә Татарстанда һөнәри дини белемне тугыз мәдрәсәдә алырга мөмкинлек бар. Урта һөнәри дини белемне Кукмара, Мамадыш, Яр Чаллы, Буа, Урыссу, Әлмәт мәдрәсәләрендә, Казан шәһәрендәге «Мөхәммәдия», «Ислам динен кабул итүнең 1000 еллыгы» исемендәге мәдрәсәдә, «Казан ислам көллияте»ндә бирәләр.

Барлык мәдрәсәләрдә дә белемле, тәрбияле шәкертләр әзерләү буенча системалы эш алып барыла. Һәр мәдрәсәне дә тәҗрибәле, дөньяви, шул ук вакытта дини белеме дә булган хөрмәтле җитәкчеләр җитәкли. Алар арасында озак еллар дини мәгариф өлкәсендә хезмәт куйган Рөстәм Шәйхевәлиев, Ильяс Җиһаншин, Марат Мәрданшин, Наил Яруллин кебек абруйлы, хөрмәтле шәхесләр дә бар. Һәр мәдрәсәнең үз тарихы, күркәм традицияләре... Биредә белем бирүче остазлар да дөньяви, шул ук вакытта дини белеме дә булган хөрмәтле укытучылар.

Мәдрәсәләрдә укыту «Дини оешмаларга хезмәткәрләр һәм дини персонал әзерләү» «Подготовка служителей и религиозного персонала религиозных организаций» юнәлеше буенча

алып барыла. Укыту имам-хатыйплар һәм ислам фәннәре укытучылары әзерләүгә юнәлтелгән.

Татарстан мөселманнары Диния нәзарәте мәдрәсәләрдәге уку-укыту системасын бер калыпка салу юнәлешендә дә шактый нәтиҗәле эш алып бара. Казан ислам университеты, мәдрәсәләр, Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе белгечләре ярдәме белән уку-укыту стандартлары эшләнде. 2015-2016 уку елыннан башлап, Татарстан Республикасы мөселманнары Диния нәзарәтенә караган мәдрәсәләрдә шәкертләргә белем әлеге стандартлар нигезендә бирелә башлады. Уку планнары, уку-укыту программалары эшләнде, дәреслекләр бастырылып, мәдрәсәләргә таратылды.

Өченче баскыч – югары дини белем. Югары белемгә ия булырга теләгән абитуриентлар Казан ислам университетына юл тоталар. Әлеге уку йортын хәзерге көндә тәҗрибәле җитәкче, сәясәт фәннәре докторы, академик Рәфыйк Мөхәммәтша улы Мөхәммәтшин җитәкли. Биредә дә дини һәм дөньяви белемле һәм шулай ук фән кандидаты, докторы дәрәҗәсенә ия остазлар хезмәт куя. Укыту «Дини оешмаларга хезмәткәрләр һәм дини персонал әзерләү» юнәлеше буенча алып барыла. Әлеге уку йортында да уку-укыту стандартларга нигезләнеп оештырыла. Стандартлар 2017 елда «Ислам фәннәре» профиле буенча «Ислам фәннәре бакалавры» квалификациясе өчен эшләнде һәм расланды. Казан ислам университетында әлеге стандартка нигезләнеп уку оештырылды.

Шулай ук Казан шәһәрендә урнашкан Русия ислам институтында да студентлар «Ислам теологиясе», «Ислам икътисады», «Ислам журналистикасы» профильләре буенча «Теология», «Икътисад», «Журналистика», «Лингвистика» юнәлешләрендә югары белем ала алалар. Биредә уку Федераль дәүләт стандартларына нигезләнеп укытыла. Уку йортын тәмамлаган студентларга дәүләт дипломы бирелә. Шуны ассызыклап үтәргә кирәк: алда санап үткән барлык уку йортлары да дини стандартларга нигезләнеп уку-укыту процессын оештыра һәм билгеләнгән үрнәктәге дипломнар бирә иде.

Дини белем алуның соңгы баскычында быел тагын бер уку йорты пәйда булды. Ул – Болгар ислам академиясе. Соңгы вакытта «Анда кемнәр укыячак, кемнәр укытачак?» кебек сораулар җәмәгатьчелектә еш күтәрелде. Кайберәүләрдән «Бу уку йорты кирәк идеме инде?», «Бигрәк еракта урнашкан» дигән төрле каршылыклы фикерләрне дә ишетергә туры килде.

Болгар академиясендә магистр һәм докторларны әзерләргә җыеналар. Бу ислам югары белем бирү системасының тагы да югары дәрәҗәсе дип санала. Уфада, Казанда яки башка шәһәрләрдә бакалавр дәрәҗәсенә ия булган белгечләр монда килеп магистр һәм киләчәктә доктор була алалар. Татарстанда урнашса да, академия Русиянең төрле төбәкләреннән килгән яшьләрне укытырга планлаштыра. Шул ук вакытта магистрларның чыгарылыш эше темалары татарларда, Русия мөселманнарында илаһият гыйлемен өйрәнүгә дә багышланган булачак. Мәрҗани, Утыз Имәни, Курсави һәм татарның күренекле башка шәхесләренең мираслары өйрәнеләчәк.

Бу уку йортында да әзерлек «Дини оешмаларга хезмәткәрләр һәм дини персонал әзерләү» юнәлеше буенча оештырыла. Уку-укыту шулай ук расланган стандартка нигезләнеп алып барылачак. Стандарт «Ислам фәннәре» профиле буенча эшләнгән, шәкертләр «Ислам фәннәре магистры» квалификациясе алып чыгачаклар. Әлеге стандарт үз эченә берничә белгечлекне ала:

- «Ислам хокукы» («Исламское право»)
- «Ислам фикере һәм тәгълиматы» («Исламская мысль и вероучение»)
- «Коръән тәфсире һәм Коръән фәннәре» («Толкование Корана и коранические науки»)
- «Ислам икътисады» («Исламская экономика»).

Күптән түгел генә Академиянең президенты итеп Татарстан Президенты ярдәмчесе Камил Исхаков сайланды. Исхаков уку йортының финанс эшләре, халыкара бәйләнешләре, үсеш стратегиясе һәм программасы, административ-хуҗалык эшләре өчен җаваплы булачак. Ректор Рәфыйк Мөхәммәтшин исә фән һәм белем бирү юнәлеше, башка мәсьәләләр белән шөгыльләнәчәк.

Белгәнебезчә, бүгенге көндә һөнәри дини белем бирә торган уку йортлары студент өчен барлык мөмкинлекләр тудыра. Бөтенләй бушлай яки символик суммага гына ашау, яшәү, иң мөһиме – һөнәри белем алу мөмкинлеге ул. Диния нәзарәте дә грантлар ярдәмендә кайбер авылларны имамлы һәм иманлы итү өстендә эшли, стандартлар раслый, дәреслекләр бастыра, уку йортларын җиһазлар, техника белән тәэмин итә. Әмма, шуны ассызыклап үтәсем килә: хәл ителмәгән проблемалар да җитәрлек әле. Һөнәри уку йортларында кандидат, доктор дәрәҗәсендәге мөгаллимнәрнең аз булуы, ерак авылларда, мәчетләрнең имам булмау сәбәпле, йозакта торуы, кайберәүләрнең төрле дини агымнарга кереп китүе һ.б. Диния нәзарәте, дини белем бирә торган уку йортлары, дәүләт бер максат куеп эшләгәндә генә әлеге проблемаларны хәл итәргә мөмкин булачак.



Гөлүсә Закирова

# РИМЗИЛ ВӘЛИНЕҢ КҮЧМӘ БАКЧАСЫ

Күренекле җәмәгать эшлеклесе, журналист, «Идел» журналының беренче баш мөхәррире Римзил Вәлиевнең Казандагы данлыклы бакчасы турында ишетеп белә идек инде. Ниһаять, татарның билгеле шәхесләре, чит илләргә сибелгән мөһаҗирләре утырткан агачларны күрергә җай чыкты. Әйдә, Римзил абый, ач капкаңны, «Идел» журналы бакчаңа кунакка килде!



## ТҮГӘРӘК АЛАН ГАИЛӘНЕ ХӘТЕРЛӘТӘ

1994 елда, әнисе Фазыйла әби вафатыннан соң бер ел үткәч, Римзил абый Вознесение бистәсендәге бакчасында ике миләш агачы утырта. Һәм... миләшләрнең берсенә әни агачы – Фазыйла агачы дип исем куша. Шуннан китә инде... Исемле агачлар утырту гадәте күркәм шөгыльгә әверелә.

– Ишегалды калкурак урында иде, мин аның туфрагын трактор белән кистереп, тигезләттем дә матур гына түгәрәк алан барлыкка килде, – ди Римзил абый. – Әйләнәсенә агачлар утырта башладым. Әйтерсең алар агачлар да түгел, ә тере кешеләр. Белмим, агачларга исем кушу дөресме икән... Әмма бу гамәл туганлыкны, дуслыкны аңлата торган метафора, шулай дип аңлагыз.

Баштарак кем агачы булуын күрсәткән табличка куярга да теләдем. Әмма бу уемнан кире кайттым. Чөн-



ки исемнәр җисемгә табигый рәвештә килеп торырга тиеш. Агач ботаклары кебек. Зур-зур кешеләр Казанның меңьеллыгын үткәргәндә агачлар утыртты – анда табличкалары бар, ә күп кенә агачлары корыган...

### БУ ЧЫРШЫ – МӨҺАҖИРЛӘР ЯЗМЫШЫН ХӘТЕРЛИ

Вознесение бистәсендәге Дүсән-2 ишек алдында (Дүсән – Римзил абыйның туган авылы, Башкортстанның Бишбүләк районында), мунча йортыннан дүрт-биш тапкыр биегрәк үсеп, түбәсе зәңгәр күккә тигән мәгърур чыршы янына тукталабыз.

– Бу чыршы – Төркиядә яшәүче профессор Надир Дәүләтнеке. Ул 1944 елда Кытайның Мукден шәһәрендә туган. Хәзер ул күренекле татар галиме, Төркиянең Истанбул шәһәрендә яши, Мәрмәрә университеты профессоры, TASAM премиясе лауреаты. Чыршысы Төркиядәге барлык мөһаҗирләргә күренерлек булып үсте. Ул илдә яшел төс бик тансык. Барысына да җитәрлек аның күләгәсе. Надирның язмышы мине тетрәндерә. Бала вакытында Кытайда Гаяз Исхакыйлар белән бергә татар җәмгыятендә катнашкан өчен аның әтисен дә, әнисен дә төрмәгә утырталар. Совет хакимияте Харбинга ук килеп, тәртип урнаштырган. Берүзе калган малайны һәм Харбиндагы татар җәмгыятен илленче еллар башында Төркиягә күченергә Лев Толстой исемендәге урыс вакыфы ярдәм итә. Истанбулда аны Ибраһим исемле татар мөһаҗире уллыкка ала. Әтисе төрмәдә вафат була. Үз әнисе, күп еллар үткәч, төрмәләрдән котылып, Надирны эзләп таба. Хәзер Казанда яшәүче сеңлесе Фәридә төрмәдә туган. Ул балалар йортында үсә. Менә нинди фаҗигале язмыш! Болар турында Марина Разбежкина документаль фильм да төшерде. Бер караганда, шулкадәр авырлыклар күреп, Надир Дәүләт яхшылыкка ышанмаска да тиеш кебек. Ә юк... Ул башка... Андый язмышлы кардәшләргә багышлап шушы бакчага агач утыртырга булдым. Ботакларда алма да бар, чәнечкеләре дә. Кеше язмышы кебек...

### «ВАТАНЫҢ КАЙДА?»

Тик нигә соң мөһаҗирләр «Казан», «Татарстан» дип өзелеп тора? Республиканың милли йөзе, тарихы, мәдәнияте өчен сызлана, ярдәм итәргә әзер?

– Моның сәбәбе гади, ул сәясәт яки милли радикальлек белән бәйле түгел. Кешегә ватан кирәк! – ди Римзил Вәлиев. – Ә кайда соң Ерак Шәрыкка, Төркиягә күчкән кардәшләрнең ватаны? Фәрит Иделле, Надир Дәүләт, Фәридә һәм Фәрит Бичури Кытайда туганнар, Төркиядә үскәннәр. Аларның замандашларының бер өлеше Америкага яки Алманиягә киткән. Финляндиядә торучылар бар. Җүнәйт Чапан оглы Сан-Францискода яшәде. Оркыя һәм Абдулдаян Сафалар Кореядә үсеп, АКШта гомер иткән. Алар барысы да Казанга: «Аһ, ватан!» – дип кайта. Югыйсә – Казан бары тик Татарстан автоном республиканың гына башкаласы, Советлар берлегенең, Русиянең бер төбәге. Ә ватанга сусаган, меңьеллык тарихын белгән татар кешесе өчен Татарстан, Казан – изге мәркәз, рухи кыйбла.

Бу бакча тамыр җибәргәндә Татарстан мөстәкыйльлеге өчен көрәш, Мәскәү белән тартышкан катмарлы туксанынчы еллар булган. Беренче тапкыр ата-баба җиренә кайтучыларның хисләре, милли үзаңы – бик катлаулы чаклар. Шунда Римзил абый милләттәшләргә болай дип әйткән: «Бу җир – сезнең җир, илегезгә кайтып киткәч, монда, үзе бер милли җәмгыять булып, агачларыгыз кала. Ризамы – риза!» Агачка исем бирү тантанасы бик гади – исем кушу догасы укыла һәм шуның белән шул.

### «АЗАТЛЫК» АЛМАГАЧЫ

Алмагачлары шактый Римзил абыйның. Алма исеннән башлар әйләнә. Балланып җиргә тәгәрәп төшкән алмаларны кочагына җыя-җыя, «Бу алманы Зилә ярата» дип куя.

Надир Дәүләт чыршысына терәлеп үскән алмагач каршында ул кинәт җитдиләнеп калды. Өлгереп бетмәгән алмасы ачы булдымы дисәм, юк – «Азатлык» радиосы белән бәйле кайбер хатирәләре яңарган икән.

– Журналистлар агачы бу. Баштарак мин аны Рим Гыйльфанов агачы дигән идем. «Азатлык»ның Казандагы бюросы ябылгач, алмагачын кисәм дип, пычкы күтәреп чыктым. Чын әгәр. Биш-алты татар Аурупа шартларында яшәсен өчен Казандагы, төбәкләрдәге хәбәрчеләрне кыскарту акыллы эш булмады. Шәкертем, соңрак түрәбез булган Рим үзе кунакка кайткач агачны кисәрмен, дип уйлаган идем, соңрак сүрелдем. Ул, гомумән, барлык милли журналистлар агачы.

Ә «Азатлык» бюросының архивы миндә саклана. Прагада, Мюнхенда түгел, шушы бакча йортында ул.

**ФӘРИТ ИДЕЛЛЕ ЧЫРШЫСЫ – АЛМАН ИЛЕ ТАТАРЛАРЫН ХӘТЕРЛӘТӘ**

– Ә мәнә бу чыршыга Алманиядә яшәүче Фәрит Иделле белән дога кылдык, – дип сүзен дәвам итә Римзил Вәлиев. – Ул озак еллар буе «Азатлык» радиосының татар-башкорт редакциясе мөдире вазифаларын башкарды. Танышуыбыз кызык кына булды. «Идел» журналының беренче саннары чыккач, «Азатлык» радиосында Фәридә Хәмит, шундый шәп журнал чыккан, дип сөйли башлады. Журналда чыккан язмаларны укый. Шуннан «Идел»гә чит төбәкләрдән игътибар артты. Чит илдән татар радиосы сөйли, мин куркам, «теге» заман бит: туксанынчы еллар. Көз көне Русия Язучылар берлегенең пленумына бардым. Шул баруымда үзем эшләгән «Комсомольская правда» редакциясенә сугылдым. Анда бөтен дөньяга шылтырата торган «собкор челтәре» аша, Мюнхенга шылтыраттык. Трубкадан «Аги» дигән сүз ишетелде. Таныштык, сөйләштек. Аннан киләсе язда мин алар чакыруы буенча Мюнхенга бардым, Фәрит Агилар өендә булдым. Мәнә кызык әйбер – Япониягә беркетелгән совет шпионы Шамил Хәмзинны яхшы беләм ул. Кытайда яшәгәндә (Харбин, Хайлар, Чән-Чүн) милли җәмгыятьтә катнашкан өчен Фәритнең этисе Әмрулланы совет төрмәсенә утырталар.

Этисез калган Агилар гаиләсен Хәмзиннар үз йортларына фатирга кертә. Соңыннан Агилар Төркиягә китә. Этисеннән ике яшьтә аерылган Фәрит аны егерме ел үткәч, Әмрулла абзый лагерьдан чыгып гаиләсен Истанбулда тапкач кына күрә. Мәнә шундый язмышлы кеше ул Фәрит Иделле. Ул җитәкләгән «Азатлык» радиосының Казан бүлеген ачтык, бик әйбәт эшләдек, нинди генә хәлләр булса да, Фәрит әфәнде тугры дус булды. Ул вакытта миңа Надир белән Фәрит төп фигуралар иде. Ул кешеләр – үзгә иде. Чит илгә киявгә чыккан ханымнар, эшкә, яшәргә чит илгә киткән яңа эмиграция дулкыны, Русия паспорты белән чит илдә яшәүчеләр белән аларны чагыштырып булмый.

> **Мин белгән мөһаҗирләр яңарак кына чит илгә эшкә киткән гастарбайтерлар түгел, аларны, этиәниләрен милләт язмышы, зур вакыйгалар, сәяси давыллар илдән илгә йөрткән. Беркем дә үзе теләп, җиңел генә, ватаннан аерылмый.**



*Фәрит Иделле*



*Надир Дәүләт*



*Сан-Франциско татар мәхәлләсе имамы Абдуллаян Сафа һәм аның җәмәгате – татар җәмгыятенең күренекле шәхесе Оркыя ханым – Казанга ел саен килә. Алар исемендәге гөлҗимеш агачы хәзер өй түбәсе биеклегендә*



## ТУЯ АГАЧЫ АЙРАТ ИСЕМЛЕ

Янәшәдә генә тагын бер журналист агачы үсеп утыра. Җәен-кышын яшел, йомшак энәле туя. Анысын моннан ун-унбиш ел элек Ульяннан журналист Айрат Ибраһим белән бергәләп утыртканнар.

– Бик хөрмәтле кеше. Сембер ягында милли хәрәкәтне күтәрүчеләрнең берсе, «Азатлык» хәбәрчесе дә булды ул. Тумышы белән Башкортстанның Бәләбәй районыннан. Казанда аның дусты Нурулла Гариф яши, китаплар чыгара. Аның да агачы бу! Айрат абый олы яшьтә булуына карамастан, бәхәсләшә белә, турысын ярып әйтә иде. Шуның өчен әлегә дә инде, җирле хакимият, кайбер кардәшләр дә өнәп тә бетермәгәндер. Кыю китаплар чыгарды. Туя агачын күчмә бакчага үзе алып килде. Гаҗәеп агач, әмма бик әкрен үсә икән. Китмәс, дип уйлаган идем, бик матур үсеп китте.

## ТӨРКӘР ИСЕМЛЕ НАРАТ

Шулай ди дә Римзил абый матур гына калыккан туяны сыйпап куя һәм карашы янәшәдә үскән наратка туктала. Швециядә яшәүче Төркәр Сууккан агачы икән. Ни өчен милләттәшебез нәкъ менә наратны сайлавын сорашабыз.

– Шулай бервакыт Обсерваториядәге иске бакчамда «бәдрәф туе» үткәрдек. Тактадан бәдрәф эшләдем дә, бәдрәф туе дип плакатлар язып, мәҗлес кордык. Кунаклар арасында Батулла, Төркәр дә бар. Татардагы чисталык дип, бәдрәфнең роле турында нотыклар сөйләнде инде. Аның миндә видеоязмасы да саклана әле. Обсерватория – урыс сүзе, дип, Батулла аны Зикурат дип тәрҗемә итте. Андагы наратларга Төркәрнең бик исе китте инде.

Еллар үткәч, Зикурат-Обсерваториядәге ул язлыкны саттык. Әмма бу бакчага Төркәр кайтты. Иң зур, бердәнбер наратның үз исемендә булуын күргәч, бик сөенде. Төркәр – Стокгольмда полиция академиясендә хокук белемен алган бик лаеклы кеше.

## БАКЧА НИЧЕК БАШЛАНГАН?

Иң тәүге мөһаҗирләр белән 1987-1988 елларда таныша Римзил абый. Ул чорда чит төбәкләрдән татарлар килә башлый. Беренче тапкыр Финляндиядән, Сан Франциско һәм Нью-Йорк шәһәрләреннән бер төркем татарлар Идел буйлап пассажирлар көймәсе белән киләләр. Казанда чит ил ватандашларына тукталырга рөхсәт ителгәч тә. Совет елларында





Казан «ябык» шәһәр була. Римзил абый очрашуга улы Динисны да алып бара, аның исе китә: апалар-абзыйлар татарча сөйләшә, урысча белмиләр. Казанны карап соклана-лар, елыйлар. Академик Мирза Мәхмүтов, журналист Дамир Гыйсметдин «Ватан» җәмгыятен җитәкләгән чакта язмабыз герое да бу эштә катнашып китә. Сан-Францискодан килгән Рәйсә Хәкимнең язмаларын «Идел» журналында да бастыра әле ул. Гаҗәп бит: Фәрьял исемле кызы, Шан исемле ирланд кешесенә кияүгә чыккан. Америкалы кияү бу гаиләнең ватанга омтылуларын, дөньяга карашларын, ватанга омтылуларын, милләтне кадерләүләрен, Тукай кичәләрен үткәрүләрен күреп, ислам динен кабул иткән.

– Мин белгән мөһаҗирләр әле яңарак кына эшкә киткән гастарбайтерлар түгел, аларны, әти-әниләрен милләт язмышы, зур вакыйгалар, сәяси давыллар илдән илгә йөрткән. Беркем дә үзе теләп, җиңел генә ватаннан аерылмый. Кайберәүләр, чит ил татарын күрсә, әһә, сез анда шәп яшисез, мине дә чакырыгыз әле, дип фикер йөртә. Икътисади мөһаҗирлек, мулрак шартларда яшәргә теләү дә табигый анысы. Ләкин илдән, милләттән читтә яшәгән татарларга шәхси максат белән мөрәгать иткәнем булмады. Чакырсалар да, кунакка бармадым. Хәтта Финляндия, АКШ кебек татар җәмгыяте булган илләргә дә. Вакытым да булмады, гадәттә Казанга алар үзләре килде. Кеше эмиграциядә бер сәгать кенә булса да, аның фикерләве үзгәрә, ул башка кешегә әйләнә, дип язган Эрих Мария Ремарк. Чемоданга бар булганын салып, юлга чыккан кеше, теләсә нинди авырлыкка әзер, ул яңа шартларга тиз күнегә, кирәк булса бер илдән икенчесенә дә күчеп китә. Ул илгизәргә әйләнә, үзе барган илләрнең яшәү рәвешен, телен өйрәнә. Шул вакытта ул милләтен үзе белән йөртә.

## РАВИЛ БОХАРАЙ ЯФРАКЛАРЫ ШИГЫРЬ СӨЙЛИ

Римзил Вәлиев бакчасындагы чиягә минем генә түгел, күпләрнең исе китәдер. Бик зур агач булып, ябалдашлары белән кура җиләкләренә күләгә булып утыра.

– Чияне яратам, мин аны алай үсеп китәр, дип уйламадым, – дип елмая бакчачы. – Һәр өйдә дә алай түгел ул. Бәлки Равил Бохарай агачы булгангадыр? Вафатыннан соң нигә күтәрәм мин Бохарайны? Аны урыс шагыйре диделәр, кайберәүләр аңа Тукай бүләген бирүгә дә каршы булды. Равил Бохарай кебек фикер иясе, дин эшлеклесе, кырыклап китап авторы, Русиянең иң яхшы шагыйре дигән аты булган башка шәхесне белмим. Алманиягә беренче тапкыр баргач, без аның белән бергә Фәрит Иделле йортында фатирда тордык. Шунда «Күчмә бакча» дигән роман язам, дигән иде. Миннән кыюрак иде күрәмсең, татарлар яшәгән илләрне урап кайтты. Үзенең мәдәни бизнес-проектларын да тәкъдим иткән. Шул тәэсирләре нигезендә «Азан» дигән китап чыгарды. Аны татарлар күпләп сатып алырлар да китап чыгымнарын каплар, дип уйлады. Тик бу проекты барып чыкмады. Аннан Равил Лондонда дини текстларны тәрҗемә итә торган мөселман җәмгыятендә үз юлын тапты. Ул Би-би-си радиосында эшләде, шигырь китаплары, проза әсәрләре язды, Татарстан турында саллы китаплар чыгарды. «Йосыф-Зөләйха» кыйссасын инглиз теленә тәрҗемә итү, бастыру да Бохарайның хезмәте булды. Зур шәхес, татарны танытучы буларак тарихка керде ул. Ә аның «Күчмә бакча» проекты биредә гамәлгә керде.

## МӨҺАҖИР САМАВЫРЫ, ҖӘЛИЛНЕҢ СКРИПКАЧЫСЫ ҺӘМ ЯҢА ЙОЛДЫЗЛАР АЧУЧЫ

Татарстанда мөһаҗирләр музее ачылырга тора, шул хакта да сөйләшеп алабыз. Римзил абый ул музейда мөһаҗирләр самавырын күрергә тели.

– Алар тирәлеккә яраклаша белгән, атналар буе пароходта барып кара! Самавырларын вертикаль бүлеп, бер ягында аш пешергәннәр, икенче яртысында чәй кайнатканнар. Менә шул самавырны эзлим. «Идел» укучылары арасында белүчеләр юк микән? Ул шулай да булып

куя. Муса Җәлил турында язганда, «Идел-Урал» легионында Җәлил үзе оештырган кыллы ансамбль төшкән фотоларын интернетка куйган идем. Скрипкада уйнаучы бер музыкантны танып, Оренбург өлкәсеннән туганнары шылтыратты. Дөнья кечкенә генә ул – дөнья татарлары бер-берсен танырлык.

Тагын бер алмагач янына тукталабыз. Рәшит Сүнәевнеке!

– Беләсезме, нинди кеше ул? – Римзил Вәлиев янә рухланып сөйләргә керешә. – Татар дөньясында беренче кеше! Иң зур астрофизик, «черная дыра» дигән әйберне эзләп тапты. Ул җиһанның корылышын, закончалыкларын белә. Путин аңа Дәүләт премиясе тапшырды, аның лекциясен тыңлады. Җир шарының язмышын Президент та белергә тели. Зур шартлау барлыкка китергән беренче матдә каян чыккан, дип тә сораган аннан Владимир Путин. Сүнәев исә, башлангыч матдә Алла кодрәтенә бәйле булуга ишарә ясап: «Бу сорау миңа түгел, чиркәүгә бирелсен!» – дигән. Нинди югары көч булу мөмкинлеген ул да инкяр итми. Ә астрофизикада Сүнәев алган бүләк ул Нобель премиясенә тиң.



### КҮЧМӘ БАКЧА ЙӨРӘКЛӘРДӘ ҮСӘ

– Урамнарга, урманнарга исем кушарлык лаеклы татарлар бик күп. Арабызда зур гамәлләр кылган олы йөрәкле кешеләр бар. Ерак барасы түгел – Минтимер Шәймиев иганәче Әсгать Галимҗановка үзе исән чагында һәйкәл салдырды. Без андыйларны күрергә, белергә тиеш. Ниндидер эшләрне фәрман-карарлар белән билгеләми генә дә башкарырга була... Яки халык язмышын хәл итүче гамәлләр башкалар. Мәсәлән, Семен Игнатьев Сталин заманындагы МГБ министры Татарстанда обком җитәкләгәч, татар телен, мәдәниятен күтәргән, Тукай бүләге тапшыруны керткән. Шуның өчен аны эштән алганнар. Мәдәни шәхес булган ул. Аның урамы, һәйкәле булырга тиеш. Ә бу бакчада аның агачы Казан ханлыгы тарихын язган Михаил Худяков белән уртак. Гумилев та шундый ук затлардан. Татар кешесе, бигрәк тә милли хәрәкәт, мәдәният әдибенең күңелендә мондый кешеләр бакчасы гөрләсен иде.

Хушлашканда Римзил абый пышылдап кына якташлары – шагыйрь Фатих Кәрим һәм бөек дипломат Кәрим Хәкимов исемнәрен әйтте. Иң кадерле алмагачлар алар исемендә икән. Барысын да кычкырып әйтү уңайсыз, диде ул. Кайбер җанлы затларга да, агачларга да күз тияргә мөмкин. Җил-давыллар була. Әнә Төркәр нараты 2008 ел гарасатында ауган була. Ике автомобиль тросы белән тарттырып, аякка бастырырыга туры килгән.

Ә агач корыса, яки сынса, яки бакчаның хуҗасы үзгәрсә, нишләргә? Римзил Вәлиев фикеренчә, бу табигый хәлләр. Агачны дәваларга мөмкин. Яңа агач утыртып була. Теләсә кайсы туфракта.

«Күчмә бакча йөрәктә үсә ул!» Римзил абый шулай диде. Шундый кешеләр дә татарга кирәктер.

**Чемоданга бар булганын салып юлга чыккан кеше, теләсә нинди авырлыкка әзер, ул яңа шартларга тиз күнегә, кирәк булса бер илдән икенчесенә дә күчеп китә. Ул илгизәргә әйләнә, үзе барган илләрнең яшәү рәвешен, телен өйрәнә. Шул вакытта ул милләтен үзе белән йөртә.**



Асия Зарипова



# САБА ХОККЕЙЧЫЛАРЫ

Җәй уртасында авыл малайларының хоккей уйнаганнарын күргәнегез бармы? Элегрәк бу чынга ашмаслык хыял булса, хәзерге заман балаларыннан көнләшергә генә кала. Саба районы Лесхоз авылындагы катокта без дә булдык. Һәм шаклар каттык. Биредә районның барлык авылларыннан боз шугалагында кәшәкә белән алка куарга теләгән һәр малай, кыз шөгыльләнә ала. Автобус белән бушлай алып киләләр, дәресләр тәмам булгач, кире илтеп тә куялар.
Шулай итеп, Саба районының «Черные пантеры» хоккей командасы уенын карадык без дә.

**«КАРА КАПЛАН» МАЛАЙЛАРЫ**

«Черные пантеры»га 2005 елда туган малайлар йөри. Алар Сабадан, Көек, Шәмәрдән, Шекше авылларыннан. Атнага биш тапкыр күнекмәләр алалар, ә бер көн уенга багышлана. Атна буе үзләштергән күнекмәләр әнә шул уенда күренә дә инде. Җәен үзләренә лагерь да оештырылган, Иске Икшермә кадет-интернат мәктәбе базасында яшәп, сәламәтлекләрен ныгытып, Лесхоз катогына да йөргәннәр. Яшь хоккейчыларның уңышлары да бар инде, ничә ел дәвамында тренерлары Илнур Галимҗанов кул астында хоккей серләренә төшенеп, республикакүләм ярышларда да катнашканнар. Экипировка белән тәэмин итү, турнирларга йөрү, анда балаларны ашату, кундыру мәсьәләсен дә район җитәкчелеге балалар файдасына хәл итеп куйган.

– Спорт мәктәбенә килгән һәр баланы кабул итеп, һәркайсы белән шөгыльләнәбез, – ди Саба балалар һәм яшүсмерләр спорт мәктәбе тренеры Илнур Галимҗанов. – Килгәндә тимераякта басып тора белмәгәннәре дә була. Күпмедер вакыттан соң, техниканы үзләштергәч, иң яхшы уенчыга да әйләнеп китәләр.

Шулайдыр, элегрәк биредә канат ныгыткан танылган хоккейчылар да бар бит. Саба егетләре Марсель Ибраһимов («Ак барс»та уйнап, инде ЦСКА уенчысы булган), Руслан Галимҗанов («Ак барс»), Илдар Ахунов («Ирбис»), Раил Шәрипов (Әлмәтнең «Спутник» командасында), кызлардан Алсу Рәхимова, Ландыш Фәләхова – зур хоккейда үзен сынаган спортчыларны саный китсәң,

Автор фотолары



Тренер И.Галимҗанов

шактыйга җыела. 2013 елда Русия-күләм «Алтын шайба» турнирында, аннан Чехиядә җиңеп кайталар. Бу – җиңүләрнең кайберләре генә. Тренер исә, иң зур җиңүебез алда ди, менә бүген тырышып алка куган «Кара каплан» малайларына өмет баглый.

## МӘТӘЛЧЕК АТУДАН БАШЛАНА

Спортның сәламәт яшәү чыганагы булуын, организмны тонуста тотуын һәр укыган кеше белә. Акыллы әти-әниләр баласын спортка тартып кына калмый, үзләре үрнәгендә гомер буе сәламәт яшәү рәвешен дә сеңдерә.



– Хоккейның гаҗәеп үзлекләре бар, – ди яшь хоккейчы Миланның әнисе **Лидия Сөнгатуллина**. – Дөнья күләмендә иң популяр спорт төре булганга гына түгел. Көчле шәхес сыйфатлары тәрбияли ул, чыдамлыкка өйрәтә. Егет кешегә холыкны чыныктыру да кирәк бит әле.

Тренер Илнур Галимҗанов та заман балаларының сәламәтлеккә йомшак булуын искәртә.

– Машинага гына утырып йөриләр, мәктәптә дә гел диярлек утырып үткәрәләр, хәрәкәт аз. Хәтта мәтәлчек тә ата белмиләр. Шуңа күрә, иң беренче дәрес итеп мәтәлчек атарга өйрәтәбез үзләрен. Алар аңа шатлана инде. Мобиль телефон, планшет, компьютерлар да үз эшен эшли: балаларның күзләре начар. Әле бүген генә журналдан җитмешенче еллар белән чагыштырып үткәрелгән тикшерү нәтиҗәләрен укыган идем, ул чорда балалар чыннан да сәламәтрәк булган икән. Ә хоккей элементларында җиңел атлетика да, бадминтон алымнары да бар. Тимераякта йөргәндә аяк мускуллары ныгый, этү-төртүләр була, димәк, көрәш алымнары да кулланыла. Анысы да монысы: балалар чыдам булырга өйрәнә, җиңүгә омтылыш, азарт барлыкка килә һәм... командада эшләргә өйрәнә. Математикасыз да булмый: баш эшләтү кирәк бит. Тимераяк шуып бара, кирәкле урында аякны бөгеп борыла белмәсәң, хата ясыйсың, ә алка читкә китә. Шулай да, балаларны куркыту ягында түгелмен. Әгәр күнекмәләрне үзләштерми икән – уенга чыкмаячак, ә запас уенчы эскәмиясендә утыру – алар өчен иң читене.

## БЕРДӘМ КОМАНДА

Командада әти-әниләрнең күпчелеге балалар белән бергә турнирларга йөрергә тырыша икән.

– Бик мавыктыргыч сәяхәт кебек ул, – ди Лидия ханым. – Вакытны кибетләрдә, шәһәр урамнарында үткәргәнче, хоккей дип җан аткан балаң янында булу күпкә файдалырак! Без – әти-әниләр – үзебез дә бердәм командага әйләндек. Һәр бала үзебезнеке кебек якын. Уеннарга җан атарга дип дусларны да чакырабыз. Шәһәр җирендә иртәнге сәгать бишләрдә малайларын бозга күнекмәләргә йөртүчеләр турында да ишетеп беләбез. Йокысы туймаган ул баланың көне буе укыйсы да бар бит әле. Ә безне бәхет басты: аларга уңайлы вакытта йөртә алабыз. Мөмкинлекләр тудырган өчен җирле хакимияткә, тренерыбыз Илнур Камил улына, автобус йөртүчебез Николай абыйга да рәхмәтлебез!

«Черные пантеры» хоккей командасы Татарстан беренчелегендә призлы урыннар яулаган инде. «Җиңгән саен һәр балага медаль да бирелә, бу аларга стимул булып тора, – ди Илнур Камил улы. – Һәр уенда, хәтта җиңеп чыкмасаң да, үзен яхшы яктан күрсәткән уенчыны билгеләү гадәте бар».

Илнур Галимҗанов үзе Сабаның олылар җыелма командасында да уйный. «Без балачакта кар яуганын зарыгып көтә идек. Анда шугалак ясап, кар яуган саен чистартып торсак та, күңел гел хоккей тартмачыгына тарта иде. Ә хәзер менә күрегез, нинди шартлар тудырылган. Балаларга тырышып уйныйсы һәм... яңадан-яңа уңышларга ирешәсе генә».





Альбина Гомәрова

# АЛИСӘ ВЕНЕСУЭЛА ИЛЕНДӘ

Алисә Шәймәрданова... 1977 елда Казанда дөньяга килә. Фешин исемендәге сәнгать училищесын тәмамлый. 2014 елда Икътисад, идарә һәм хокук институтында дизайн белгечлеге буенча диплом ала. Хәзерге вакытта Венесуэлада яши. Ирекле фикерли торган рәссам, талантлы дизайнер. Эчке дөньясын язган картиналары, уйлап тапкан интерьер аша чагылдыра торган гүзәл зат. Рәссам ул күзәтә һәм рәсем ясаучы үзенчәлекле иҗат иясе, табигате белән дәрвишне хәтерләтә. Дизайнер исә шул ук рәссам, тик башкалар белән аралаша, аларның теләген, зәвыгын истә тотып эшли. Шуңа да Алисәдә бер-берсенә каршы килә торган ике иҗат башлангычы, ике шәхес, ике стихия очраша дип әйтергә мөмкин.





## ОСТАХАНӘГӘ – УРЛАУ ЮЛЛАР АША

Алисәгә кечкенәдән рәсем ясау теләге тынгы бирми. Хисләрен киндер тукымага төшерәсе килә аның. Табигате белән ул рәссам гына түгел, ә хезмәтләрендә җанлы образлар тудыручы, ягъни «живописец». Әлеге сәләте бала вакытта ук төртеп чыкса да, әнисе аны сәнгать мәктәбенә җибәрми, анда үсеш күрми. Өстәвенә, уку түләүле дә була. Алисә берәүгә әйтмичә генә имтиханнар тапшыра һәм бик уңышлы. Ә инде уку өчен түләү вакыты җиткәч, кызчык чек алып кайтып әнисенә тоттыра.

Кыз башта ук, үскәч, дизайнер да, рәссам да буласын белә. Әле ул вакытта «дизайнер» сүзе кулланылмый, бу һөнәрне «рәссам-бизәүче» дип йөртәләр. Сәнгать мәктәбеннән соң күпләр рәссам булып китә, Алисә үзе генә ахыргача укып бетереп үз һөнәрендә кала. Аннары укуын Н. И. Фешин исемендәге сәнгать училищесында дәвам итә. Рәсем язу серләренә оста Геннадий Макаров курсында өйрәнә. Кызганыч, бу шәхес арабызда юк инде. Дүрт ел дәвам иткән укуның дипломын танышым биш елдан соң гына ала. Укыганда ук кияүгә чыгарга өлгерә, улы туа, академик ял белән студент тормышы бер елга озыная.

Алисә өчен олы тормыш башлана. Ул «Элекон» заводына эшкә урнаша. Тик анда бер генә ай эшләп кала: оешмадагы эш сәгате иҗат кешесенә батмый – иртәнге сәгать җидедә керергә, дүрттә чыгарга... Алисә республиканың сәнгать фондына урам рекламасы дизайнеры булып күчә. Бу дәвердә, үзенең бар мөмкинлеген эшкә җигеп, рәсем ясау сәләтен ачмый әле. Кулына пумала бөтенләй алмый. Чөнки алдында башка максатлар тора – улын үстерергә һәм укытырга кирәк була. Ә аның өчен акча кирәк. Алисә уен автоматлары салонының интерьерларын эшли. Аның алдында шундый бурыч куела: бирегә килгән кеше урамдагы көнне-төнне сизмәскә тиеш. Танышым барысын да хуҗалар теләгәнчә башкарып чыга. Әлбәттә, әлеге хезмәтләрен күреп, хәрәм кәсепкә өлеш керткәне өчен, битәрләүчеләр дә табылмый калмый. Уен автоматларын ябу турында канун чыккач, ул бу өлкәдән китә. Шушы гомердә дизайнер кыз нәрсәгә сәләтле икәнен башкаларга белгертергә өлгерә, интерьер ясап бирүне сорап, аңа берберартлы кешеләр мөрәҗәгать итә башлый. Бик күп объектларга йөрергә, эш барышын һәрвакыт күзәтергә туры килә аңа. Чөнки дизайнер – һәр заказны энәсеннән җебенә кадәр башкарып чыга торган һөнәр иясе.

Рәссам буларак Алисә Шәймәрданова яраткан кешесен очраткач кына ачыла. Картиналарны да Венесуэлада гына ясый башлый. Анда ул икенче мәртәбә кияүгә чыккач китә. Улы инде мәктәпне тәмамлаган, студент, димәк, ана бурычы үтәлгән. Алисә тыныч күңел белән үзенең бәхет илендә сәяхәт итә ала.

Хәзерге ире Марат белән бик сәер, хәтта мәзәк шартларда танышалар. Аягы сынып, хастаханәгә эләккәч, героемны Маратның апасы белән бер палатага салалар. Алисәнең олы йөрәкле икәнен күреп, теге хатын телефон номерын энесенә бирергә рөхсәт сорый. Имеш, аңа дизайнер хезмәте кирәк иде, ди. Әмма Марат ике ел узгач кына шылтырата. Очрашалар, ярты елдан инде гөрләтеп туй итәләр һәм яшәргә Венесуэлага күченәләр. «Кияүгә чыкмасам, мин анда гомеремдә дә бармас идем. Венесуэла – искиткеч ил. Тик хәзерге вакытта катлаулы чор кичерә», – дип сөйли рәссам хатын. Әлбәттә, тормышын болай кисәк үзгәртү, океан артына китү аның өчен авыр була. Казанда ияләшенгән, гел хәрәкәттә, кешеләр белән аралаша, эше буенча объектларга бара. Ә Венесуэлада өйдә бикләнеп утыра, чөнки хәтта көпә-көндез урамга ялгызы гына чыгып йөрү куркыныч!

Венесуэла – зур нефть катламнары яткан ил. Ун ел элек Латин

**Һәркем – кабатланмас язмыш. Рәссам өчен аларның йөзенә карау һәм шуны киндер тукымага төшерү нинди зур бәхет! Кеше, тормышы, гомере турында уйлану, нидер гөманлау... Киндер тукымага буяу төшерер урын калмагач, Алисә аңлый – картина ясалып беткән.**

Фотолар Алисә Шәймәрданованың шәхси архивыннан

Америкасында икътисади яктан уңышлы гына үсеп килә торган мәмләкәт булып саналса, хәзерге вакытта катлаулы чор кичерә. Марат белән Алисә яшәгән Сулия штатында нефть йөз ел элек табыла. Шуңа да карамастан, әлегә кадәр хезмәт хаклары түбән, халык ач, балалар үлә, медикаментлар җитми, җинаятьчелек тамыр җәя… Әмма дөньякүләм күрсәткечләр буенча монда ягулык иң арзаны. Бер бак ягулык салу – чынаяк каһвәдән дә арзанга чыга.

Авыр тормыш шартларында яшәсә дә, венесуэлалылар төшенкелеккә бирелми, көн дәвамында күңелле җырлар башкара, кояш нурларында коена.

Шуңа да Венесуэладагы иркен йортлары Алисә өчен төрмәгә түгел, ә остаханәгә әйләнә. Табигате белән һәрвакыт рәссам булган ханым, ниһаять, кулына пумала ала. Дөресрәге мастихин белән рәсем ясый башлый. Рухи азыкны ире белән Венесуэла буенча сәяхәт иткәндә ала. Маргарита утравының искиткеч комлыклары, Мерида штатындагы горур таулар, Трухильоның теләсә кемне әсир итәрлек биек шарлавыклары, Баринастагы милли парк – һәммәсе рәссамны илһамландыра. Колумбия, Перу, Эквадор, Панама кебек илләргә сәяхәт иткәндә алган хис-кичерешләрен дә Алисә киндер тукымага төшерергә тырыша. Студент елларында ул майлы буяу белән язса, хәзер акрилга күчкән һәм эш барышында мастихин файдалана. Шул рәвешле, үзенең кабатланмас стилен барлыкка китерә: сурәт мозаикалы, күләмле һәм җиңелчә һавалы булып күренә.

## ХЫЯЛДАГЫ КҮРГӘЗМӘ

Казанда кичләрен Казансу елгасы буенча кичке шәһәр белән хозурланып йөрергә мөмкин, Сулиядәге кебек көндез дә урамга чыгарга куркып утырасы юк. Алисә дә катлаулы үзгәрешләр кичергән әлеге искиткеч ил турында тирәнгәрәк кереп уйлана башлый. Ул – аның өчен үзенчәлекле остаханәгә әйләнгән дәүләт. Рәссам буларак Алисә анда кузгаткан иң беренче темаларның берсе – нефтьчеләр. Аларның ничек эшләгәнен фотога төшергән һәм шулар буенча ясалган картиналардан «нефтьчеләр» дигән тулы бер цикл барлыкка килгән. 2018 елда узачак күргәзмәдә урын алачак кырык картина арасында шуларны да күреп булачак. Алисә Венесуэлада яшәү дәверендә иренең хезмәттәшләренең, аларның балаларының, андагы венесуэлалыларның портретларын да ясаган һәм үзләренә бүләк иткән. Нефтьчеләр Алисәне авыр хезмәтләре һәм югары түләнә торган һөнәри иләре буларак кына кызыксындырмый, ул килеп туган вәзгыять хакында уйлана… Венесуэла – контрастлар иле. Анда халык бөтенләй башка, фәкыйрьлектә яшәүгә карамастан, күңелле җырлар җырлыйлар, яңа туган көнгә сөенәләр. Байлар да урам уртасында үзләрен кычкыртып талауга күптән күнеккән, саклану чаралары уйлап тапканнар… Моңа берәү дә гаҗәпләнми, көрәшми, агымга каршы бармыйлар… Күрәсең, кояш депрессиягә бирелергә юл куймый. Җылыта, яктырта…

Алисә Шәймәрдановaның икенче темасы – «таулардагы портрет». Берсендә ире белән күрше Мерида штатына бара алар. Ә ул тау башында урнашкан, кайбер урыннарда хәтта кар ята. Монда яшәүчеләр Сулия халкына һич кенә дә охшамаган. Биредәгеләр аңлый: акчаны берәү дә китереп бирми, эшләп алырга кирәк һәм игенчелек белән шөгыльләнәләр. Бу төбәктә рәссам хатынны кешеләр җәлеп итә. Ул тиз генә өлкән яшьтәге хатынны фотога төшереп ала. Бездә өлкән кеше дигәндә күз алдына әби килсә, анда әле ул хатын-кыз!



*Маракайбо күпере*



*Кояшлы кеше*



*Кыз бала*



*Тропик чәчәк*



*Мерида карчыгы*

Чәче тәрбияләнгән, үзе матур күлмәктән, йөзендә исә зирәклек һәм сабырлык чагыла. Портретта Алисә аның холкын ача. Бер елдан алар янә Меридага баралар, теге хатынны эзләп табалар. Ләкин шушы гомер эчендә ул бик нык үзгәргән, ябыккан була.

Һәркем – кабатланмас язмыш. Рәссам өчен аларның йөзенә карау һәм шуны киндер тукымага төшерү – нинди зур бәхет! Кеше, тормышы, гомере турында уйлану, нидер гөманлау... Киндер тукымага буяу төшерер урын калмагач, Алисә аңлый – картина ясалып беткән. Гүя, шушы рәсем белән алар бер-берсен яза. Сурәт аны эзләнергә, фикерләргә этәрә, яңа уйлар туа. Кайчак хәтта төсләр бер-берсен үзләре эзләп таба кебек тоела рәссамга, әйтерсең, пумала тоткан кулын кемдер йөртә. Картина башта уйлаганча килеп чыкмаса, ул тагы да ныграк куана...

Булачак күргәзмәнең өченче темасы – «флора һәм фауна». Венесуэла – күз явын алырлык үсемлекләр дөньясы. Ә менә үсемлекләр һәм чәчәкләрне Алисә фотога карап түгел, натуралата ясый. Диңгез дә – киндер тукымага төшерүне сорап торган тагын бер стихия. Күргәзмәдә диңгез шулай ук аерым цикл булып тәкъдим ителәчәк.

Ә иң кызыгы һәм дулкынландырганы шул: Алисә үзен Венесуэлада глобаль һәм гаять зур үзгәрешләр көтелгән чорда яшим дип хис итә. Бу үзгәреш яшәешне уңай якка үзгәртәчәк революцияне хәтерләтәчәк. Вәзгыять тиздән алышыначак. Анда аналар, акча җыеп, уналты яшь тулгач, кызларына күкрәкләрен зурайту өчен сертификат алып бирә икән. Ни өчен бу халык үзен шулай даһи итәргә тели? Дәүләтнең холкын ничек тотып алырга һәм сурәткә төшерергә? Алисә Шәймәрданова гадәти булмаган бу илнең кояшлы якларын ясарга омтыла: дөньядагы иң биек шарлавыклар, иң озын канатлы юллар... Бу гүзәллекне сүз белән әйтеп бетерә торган түгел! Эх, һәркем күрә алса иде!

Ни гаҗәп, Венесуэлада рәссамнар да күп икән. Русиядән килгән Алисә төсләрне кушарга, төшкән шәүлә, яктылыкны дөрес чагылдырырга өйрәтсә, венесуэлалылар төсләрне болгатмау яклы: картиналарда кызыл, зәңгәр һ.б. ачык ярылып ята, рәсемнәр дә кычкырып тора. Әлбәттә, алар үзләренчә матур.

– Ирем Маратка рәхмәт, – ди Алисә ахырдан. – Җай чыгуга ул мине тауларга яки диңгез ярына алып китә. Көч җыеп, ачык һавада рәхәтләнеп иҗат итсен, рухи азык алсын, ди.

**Рәссам буларак Алисә Шәймәрданова яраткан кешесен очраткач кына ачыла. Картиналарны да Венесуэлада гына ясый башлый.**





**Сөмбел Әхмәтҗанова,**
*Сәләтлеләр Университеты Медиа Лабораториясе*

# ТАТАРСТАН УКУЧЫЛАРЫ «СИРИУС»ТА: «ПРОЕКТ ИҖАТЫ БАШКАЧА ФИКЕР ЙӨРТЕРГӘ ЯРДӘМ ИТӘ»

Фотолар Сәләтлеләр Университеты Медиа Лабораториясе архивыннан алынды

Проект иҗаты – хәзерге белем бирү системасында иң масштаблы юнәлешләрнең берсе. Нәкъ менә проект белән эшләгәндә предметтан тыш «алга китеш» компетенциясе (soft skills) үсә. Проект иҗаты ярдәмендә мәктәп укучыларының инновацион эш өчен мөмкинлекләре арта. Әлеге яшьләрнең әйтүләренә караганда, проект эшчәнлеге мәктәптә укытыла торган фән кысаларыннан чыгып, алган белемнәрен гамәлдә куллана алу мөмкинлеге дә булып тора. Проект эше белән шөгыльләнгәндә укучылар киңрәк фикер йөртәләр һәм кейсларны стандарт булмаган рәвештә чишү юлын эзлиләр.

Татарстанда проектлар белән шөгыльләнүче яшьләр өчен Сәләтлеләр Университеты ачык проект иҗаты мәйданчыгын тәкъдим итә. Мәсәлән, «Генераль конструктор» – инженер-конструкторчылык эше белән кызыксынганнар өчен булса, «Эшмәкәрлек уеннары» проект олимпиадасы – эшлеклелек компетенциясенә ия булганнар өчен кызыклы.

1 июльдән 24 июльгә кадәр Сочи шәһәрендәге «Сириус» белем бирү үзәгендә (Сәләтлеләр Университеты партнеры!) «Бөек чакырулар» дип исемләнгән проектлар буенча белем бирү программасы уздырылды. Анда бөтен Русия күләмендә ун яшьтән алып унҗиде яшькәчә мәктәп укучыларын йөздән артык иң




яхшы укытучы һәм тренерлар укытты. Егерме дүрт көнлек программа нигезендә укучылар үзләренең проектларын булдырды һәм мастер-классларда катнашты.

Июль программасында Татарстаннан да егерме алты бала катнашты. Алар – мәктәп укучылары арасында проект һәм тикшеренү эшләре буенча бөтенрусия бәйгесенең республика этабын үткән малайлар-кызлар.

Сменаның «Дөнья океанын өйрәнү» юнәлешендәге катнашучыларның берсе – Татарстан кызы **Диләрә Габделхакова** үзенең проекты, лагерь мохите һәм проект иҗатына мәхәббәте турында менә ниләр сөйләде:

**– «СИРИУС»ТА КӨН БИК ТЫГЫЗ ҮТӘ: ИРТӘН БЕЗ ФӘННИ ПАРККА УКЫРГА КИТӘБЕЗ, АННАН КИЧКЕ ТУГЫЗДА ГЫНА КАЙТАБЫЗ. МИН БИРЕДӘ ЯҢА ТӘҖРИБӘ ҺӘМ КҮП БЕЛЕМ ТУПЛАДЫМ, ЧӨНКИ БЕЗНЕ РУСИЯНЕҢ ӘЙДӘП БАРУЧЫ ВУЗЛАРЫННАН ФӘН КАНДИДАТЛАРЫ УКЫТТЫ. «СИРИУС» ИЛНЕҢ ТӨРЛЕ ПОЧМАКЛАРЫННАН СӘЛӘТЛЕ БАЛАЛАРНЫ ҖЫЙГАН. БЕЗ КОМАНДАДА ЭШЛӘРГӘ ӨЙРӘНДЕК, ЧӨНКИ ПРОЕКТ ӨСТЕНДӘ ЭШЛӘГӘНДӘ ТӘҖРИБӘ УРТАКЛАШУ, ҮЗАРА ЙОГЫНТЫ ЯСАРГА ӨЙРӘНҮ ДӘ ЗУР НӘРСӘ. АННАН ТЫШ, ТОРМЫШКА АШЫРЫРЛЫК ҖИТДИ ПРОЕКТ ЭШЛӘРЕ ӨЧЕН КҮНЕКМӘЛӘР ДӘ АЛДЫК.**

– Минем өчен проект иҗаты шул ягы белән кызыклы: син башкача фикер йөртә башлыйсың, төрле шартлардан чыгу юлы эзлисең. Баштарак мин тикшеренү эше белән генә шөгыльләнә идем, соңыннан проект эшчәнлеге барлыгын да белдем. Мондый эшчәнлек миңа гына түгел, минем яшьтәшләремә дә мөһим дип уйлыйм, чөнки яңа технологияләр һәм эшкәртмәләр безнең кебек яңа буын вәкилләренең проектлары нигезендә барлыкка килгән бит.

Татарстанда сыйныфташым Алинә Гыйззәтуллина белән эшләгән проект «Суның портатив генераторы» дип атала. Завод-фабрикаларның ташландык сулары елгаларга түгелә, нәтиҗәдә сулыклар пычрана һәм эчәргә яраксызлана. Безнең бу проблеманы хәл итәсебез килә. Портатив генератор – дымны шешәгә җыя торган прибор. Аны шешә авызына беркетеп куялар. Генераторны поход шартларында да, суны башка төрле юл белән таба алмаган очракларда да кулланып була. Приборның корылышында Пельтье элементы бар, ул тоташкан ике керамик пластинадан тора. Көчәнеш күчкәндә, алар арасында температура ике төрле була: бер пластина кыза, икенчесе суына. Алар ярдәмендә без дымлы һавадан су җыя алабыз.

«Сириус»та эшләгән проектыбыз – «Индустрия шартларында балык үрчетү» дип атала. Тикшерү өчен без ике балык төрен: мәрсин балыгын һәм африка тиляпияләрен алдык. Проект кысаларында балыкларның үсүенә нинди ризык туры килүен өйрәнеп, суның химик составын, балыкларның авырлыгын үлчи торган приборлар белән эшләдек.

Татарстанның «Сириус»тагы белем бирү программасында катнашкан сәләтле балалары 18-23 август көннәрендә Казанда үткән «Сәләтләрне ачу» җәйге яшьләр мәктәбендә конкурстан тыш катнашу хокукына ия булды.





Чәчәк Гәрәева

# ИСЕМНӘРЕГЕЗ КҮРКӘМ БУЛСЫН!



Татарда исеменә күрә җисеме дигән бик тә матур гыйбарә яшәсә дә, хәзер кайбер яшьләр, аерылып торырга теләп, сабыйларына әллә нинди мәгънәсез исемнәр куша. Ә балага аның белән гомер юлын узарга кирәк. Бу хакта Казанның Кабан арты мәчете имам-хатыйбы Йосыф хәзрәт Дәүләтшин белән сөйләштек.

**– Йосыф хәзрәт, исем кешенең язмышына йогынты ясый, диләр. Ислам динендә моңа дәлилләр бармы?**

– Әлбәттә, исемнең адәм баласының язмышына тәэсир итә торган серле көче бар, дип әйтә алмыйбыз. Исем үзеннән-үзе генә тәкъдирне үзгәртә алмый, ләкин исем җисемне тәрбияли. Мәсәлән, берәүгә Залим дигән ат бирелеп, аңа көн саен «Залим», «Залим», дип эндәшсәләр, кешеләр аннан ерагаерлар, ул үзе дә җисеме белән залимгә әйләнүе бар. Ә менә Гадел исемен бирү барысына да яхшы тәэсир итәчәк. Кайвакыт, бераз тәртип бозучы баладан: «Исемең ничек?» – дип сорыйсың. Гадел дисә, аннан ул исемнең нәрсә аңлатканын әйтәсең. Бала үз исеменең «чиста», «дөрес», «юмарт» кебек мәгънәләргә ия икәнен белгәч, аның җитдилеге артып китә. Шуңа күрә, Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Сез Кыямәт көнендә үз исемнәрегез һәм аталарыгызның исемнәре белән чакырылачаксыз. Исемнәрегез күркәм булсын», – дигән.

**– Нинди исем сайлау хәерле, кайсыларыннан баш тартырга кирәк? Гомумән, мөселман гаиләсендә исемне балага кем куша?**

– Кайбер яхшы һәм яман исемнәрне Пәйгамбәребез (с.г.в.) искә алып: «Аллаһыга иң сөекле булган исемнәр Габдулла һәм Габдрахман. Иң дөресләре Хәрис («ә» хәрефе белән килгәндә «иген чәчүче» дигәнне аңлата) һәм Һәммәм («һ» белән килгәндә «һиммәтле», «гайрәтле» дигән мәгънәгә ия). Иң яманнары Харб («сугыш») һәм Мөррә («ачы»)», – дигән.

Исемне, гадәттә, туганнар җыелышып, киңәшләшеп сайлыйлар. Әлбәттә, соңгы сүзне әти әйтә. Исемне бездә мулла куша дип телгә керсә дә, асылда әти-әни билгели һәм алар игълан итә.

**– Балага әбисенең, бабасының, әти-әнисенең исемен бирергә ярыймы? Урысларда бу гадәти хәл, ә татарда «бер гаиләдә ике бертөрле исем булмаска тиеш», диләр бит.**

– Минемчә, моны урыслар гадәте дип кенә карау дөрес түгел. Әгәр бу чыннан да алар гадәте икән, димәк, яхшы йола. Әти-әниеңнең исемнәре күңелгә якын булу – табигый нәрсә. Күренекле сәхабәләрнең дә балалары арасында ата-анасының, әби-бабасының исемнәре еш очрый. Үземдә дә шундыйрак хәл тора: бабам Йосыф булды, кече кызыма әбиемнең исемен Хәнсә дип куштык. Туганнарыбыз кызыма эндәшкән саен, әбиебезне искә алалар. Аллаһы теләсә, оныкларга да әбибабайларның исемнәрен кушасы килә.

**– Соңгы елларда Весна, Оливье, Жигули һәм тагын әллә нинди колакка ятышсыз исемнәр кушалар. Татарга бу бер дә килешми. Ни өчен кеше, баласына шундый ат биреп, аның аерылып торуын тели?**

– Һәр ата-ананың баласын башкалардан аермалы рәвештә күрәсе килә, ягъни эксклюзив, дип уйлый. Бәлки шуңа да экзотик исемнәр кушадыр. Шөкер, дәүләт кануннары бөтенләй мәгънәсез исемнәр кушуны рөхсәт итми, дип беләм. Весна сүзенә килгәндә, ул урыс кешеләренә



Фото: islam.ru

килешәдер, бәлки. Чөнки татарда да Язгөл исеме бар, төрки халыкларда Бахар (яз) яки Гөлбахар (яз гөле) исемнәре очрый. Гарәп теленнән кергән Рабигъ, Рабига исемнәре дә «яз» дигәнне аңлата. Иң мөһиме, исемнең мәгънәсе күркәм булсын.

**– Соңгы елларда мөселман исемнәре популярлаша. Аларны ничек сайларга? Бу исемнәр адәм баласына җаваплылык өстиме? Әйтик, Ислам дигән исемле кеше нәрсәне белеп торырга тиеш?**

– Кайбер, аеруча зур мәгънәгә ия булган исемнәрне, галимнәребез балага кушарга киңәш итми. Чөнки, кеше ул исемгә туры килеп бетмәскә мөмкин. Ләкин бу тәкъдим тыю дәрәҗәсендә түгел. Мәсәлән, Пәйгамбәребезнең хатыны Зәйнәпнең исеме баштарак Бәрра була, «бик изге» дигән мәгънәне аңлата. Пәйгамбәр (с.г.в.) аны, тыйнаклыкка өндәп, Зәйнәпкә алыштырган. Кешенең аты Ислам булып та, ул җир өстендә явызлык кылып йөрсә, күркәм исемне пычратучыга әйләнә. Чөнки, кешеләр аның исемен ишеткәч, аларның күңелләрендә нәфрәт хисләре туа.

**– Кешенең исеме күркәм булмаса, җәннәткә керә алмый, диюләре хакмы?**

– Әгәр исемнең мәгънәсе бөтенләй начар булса, аны алыштырырга кирәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) бер кешенең исемен генә алыштырган. Әмма, аты начар булган өчен генә, кешесе яхшы икән, аны оҗмаһка керүдән тыймаслар, инша Аллаһ.

**– Әти-әнисе сайлаган исем ятышсыз икән, мулла исем кушудан баш тарта аламы? Бу ярый торган гамәлме?**

– Әлбәттә, мәчет имамына исем кушу вакыты җиткәч кенә түгел, бала туганчы ук мөрәҗәгать итеп, атны бергә киңәшләшеп сайларга иде. Урысча әйткәндә, күп мулланы «перед фактом» куялар да, аннан кайбер аңлашылмаучанлыклар килеп чыга. Бәйрәм өстендә, табын артында кәеф бозыла... Әмма, мулла атаана белән килешә алмаганда, исемен кушмаса да, балага азан әйтү, дога кылу барыбер кирәктер, дип уйлыйм. Чөнки, монда сабыйның гаебе юк.

**– Мөселманнарга «нар» кушымчасы кергән исем кушарга ярамый, диләр. Мисал өчен, Гөлнар, Илнар... Ни өчен? Андый исемле кешеләргә нишләргә?**

– Гарәп телендә «нар» сүзе «ут» дигәнне аңлата. Тәмугъ уты да «нар» дип килә. Әмма, бер үк сүзнең кайчак төрле мәгънә белдергәнен онытырга ярамый. Мәсәлән, Гөлнар – гарәп теленнән түгел, бәлки фарсы теленнән анар – гранат сүзен аңлата һәм Анар гөле була. Моның зыянын күрмим, Аллаһы Үзе Белүче.

**– Кайсы очракта исемне алыштыру хәерле? Кешегә исемен кыскартып, әйтик, Гөлия урынына – Гуля, Кадриягә – Катя дияргә ярыймы?**

– Исемнең мәгънәсе начар булганда, аны алыштыру хәерлерәк. Пәйгамбәребез (с.г.в.) Гасыя («гөнаһлы») исемле хатынга: «Син Җәмилә («матур») исемле буласың», – дигән. Хөзен («кыйгы») исемле ирнең: «Син Сәһел («җиңеллек») буласың», – дип исемен үзгәрткән.

**– Исемне балага ничәнче көнне кушу шарт? Бу эшне кемнәр башкара ала, кемгә ярамый?**

– Пәйгамбәребез (с.г.в.) һәр баланың җиденче көнендә корбан чалырга, чәчен алырга һәм исем кушарга боерган. Бу эш-гамәлне сабыйның туган көнендә үк башкарырга да ярый. Исем кушуда катгый рәвештә шушы көн булырга тиеш дигән канун юк.

**– Балага исем кушканда әти-әни нинди кагыйдәләрне белеп торырга бурычлы?**

– Алда әйтеп киткәнчә, иң элек, исемнең мәгънәсе яхшы булсын, аннан, әлбәттә, синең милләтеңә, халкыңа ятышлы яңгырасын.

**– Үз исемеңне ярату мөһимме?**

– Әлеге сорауга ничек җавап бирергә? Әлбәттә, ул исемне иясенә гомере буе ишетергә туры килә: дөньяда да, кабердә дә, кыямәттә дә... Минемчә, күп кешенең исемен яратуы белән проблема юк. Һәркемнең нәфесе бар һәм ул үз исеме чыкканны бик ярата, аеруча мактаган вакытларда. Күпләр тормышлары дәверендә үз исемнәрен эзлиләр: мактау такталарында, газета битләрендә... Кыямәт көнендә генә һәммәбез: «Минем исемем генә әйтелмәсә ярар иде» – дип торачак.

Йолдыз Миңнуллина

# ЭЙ... ЙӨРӘК ТИБӘ: КАЗАН – МОНРЕАЛЬ – КАЗАН

Язманың саундтрегы булачак. Җыр «Сораулар бирмә» дип атала. Альфред башкаруында. Дөресен әйткәндә, мин Альфредның кем булуын белмим. Моңарчы ишеткәнем дә юк иде. Ләкин, әйе, бу – реклама. Чөнки Альфред бер хакыйкатьне белә: йөрәк... тибә.








**– Йөрәк тибә... өч... унбиш... киттек!**

Кемнеке ничек, ә сәлкеш йөрәге «Сәләт»тә ачыла. (Акылыңа карап каршы алалар, йөрәгеңә карап озаталар?) Сизми дә каласың, ул котырып тибә башлый. Беренче каушау (оһо, тавышың матур, әйдә, сәхнәгә мен!), беренче һәм бөтенләй риясыз дуслык (кем беренче уяна, шул матур киенә), беренче мәхәббәт (чынлыкта, «Сәләт»тәге бөтен җырлар да – шул кеше турында), беренче сагыну (шәһәрара сөйләшүләр өчен бик күп түләргә туры килә) – һәм торган саен тизрәк, тизрәк тибә ул. Бераздан шушы ешлыкка күнегәсең – инде менә синең үз сәлкешләрең шул ук юлны үтә башлый. Беренче көнне – тыныч кына үсмерләр кебек, ә соңгысында карыйсың – күзләре мөлдерәмә, кочаклыйсың – нәкъ теге, син үзең сәлкеш булгандагы ешлык. Шундый тере хәзер алар. Әнә шул халәтне кабат кичерү өчен генә булса да, син монда булырга тиеш кебек.

Монда – Монреальда – Казаннан безнең белән килгән биш сәлкештән (Энҗе, Мәликә, Ислам, Арина, Резидә) кала, әле бар да тынычлар һәм бар да – үсмерләр. Шул яшькә хас уйлары, дөньяны кабул итүләре белән, үз хакыйкатьләре, үз протестлары белән. Кемдер монда ял итәргә килгән, кемнедер әти-әнисе туган телен шомартсын дип җибәргән. Алар әле белми: бу алан бөтенләй башка нәрсәләләр турында, бөтенләй башка яссылыкта. Без һәркайсы белән аерым-аерым танышабыз.

– Әнә теге кызны күрәсеңме, – ди Алимә. (Алимә инде хәзер кояш кутырлы, әфлисун сары кепкалы башкисәр кыз түгел. Җитди алан җитәкчесе. Тик мин аны кочаклыйм һәм бар да үз урынына кайта – тибә, һаман шул ешлыкта.) – Әнә теге кызны күрәсеңме, – ди ул, – шундый вакыты хәзер: гел инглизчә генә сөйләшә.

Мин елмаям.

– Бу егеткә күңелле булырмы икән, бик җитлеккән кебек күренә...

Тагын кич белән – тыныч үсмерләрнең берсе:

– Сөйләшәбез дә сөйләшәбез. Бу программага activity җитми. Җәй бит – күбрәк уйнарга, су коенырга кирәк...

Фотолар «Сәләт» архивыннан алынды



Ә бу алан – бөтенләй башка яссылыкта. Алар да әлегә – үз яссылыкларында түгел, алар әле үзләрен белмиләр.

**– Һәм йөрәк тибә... өч... унбиш... башлыйбыз!**

Көн тәртибе: уяну, тән язу, иртәнге аш, остаханәләр... – болары турында бераз соңрак. Ә хәзер, унда, нәкъ ике секундтан – бөтен сәлкешләр сары футболкаларын киеп алуга – ачылу тантанасы башланачак. Ул беренче карашка гына сәламләү, юллама бирү кебек. Ләкин кара: океан артындагы Канада күгендә Татарстан һәм «Сәләт» әләмнәре җилферди. Шушы мизгелдән без монда үзебездән дә яшьрәк. Һәркайсыбыз. Нәкъ җиде сәгатькә.

Ислам абый (без «абый», «апа» дибез, һәм бу кешенең яше түгел – аның статусы, дәрәҗәсе) «Сәләт» җырларын кабызуга, сәлкешләр кыздырырга тотына. Бию аралаш «тынычлар»ны күзәтәбез. Алар башта аптырап, аннары кызыгып карый. Инде иртәгә аларның яртысы күмәк биюгә кушылачак. Өйрәнеп өлгермәгәннәре өчен Тимур (Прагадан) махсус бию уйлап табачак (куллареңны йодрыкка җый, имән бармакларыңны күтәр, шуларны аска-өскә хәрәкәтләндереп елмай). Кумәк бию ул – читтән караганда матур күренә, ә эчтән – хәтта бию дә түгел. Бары бер ешлыкта типкән йөрәкләр генә. Казанда инде биш тулып килә.

Ян (без яшәгән йортның хуҗасы):

– Беләсеңме, бу кухняда хәзер беренче булып нәрсә бетә? – дип сорый. – Сөт! Сез – татарлар – бар нәрсәгә дә сөт кушасыз.

Ян Дәрдемәнд шигъриятен белми, ләкин тиздән монда җирле татарлар – Америка, Канада татарлары җыеласын белә, шуңа сөтне мулдан алырга тырыша. Бик төрле алар – безнең Сабан туена килгән кунаклар. Казанда, бәлки, беркайчан танышмаган да булырлар иде. Ләкин монда – күренеп тора – беләләр, аралашалар, яраталар. Нурия апа (Кытай, Төркия аша Канадага килеп төпләнгән нәсел дәвамчысы):

– Кеше үзе янында яшәгән кешеләргә охшый башлый. Шуңа татарларның бергә булуы хәерле, – ди.

Флоридадан ук килгән Римма апам (искәрмә: бу очракта инде «апа» – дәрәҗәдән бигрәк, туганлык күрсәткече):

– Читкә киткәч яхшырак күренә икән. Татарстанга кайткан саен бөтен туганнарны йөреп чыгарга тырышам. Кешенең көче – тамырында, нәселендә бит, – дип, мине тәрбияли.

Аланда сәлкешләр дөньяларын онытып, көч сынаша. Нури таяк тартышучылар төркемен җыя, Камилә (бәлки, 20 яшендә беренче тапкырдыр?) катыктан доллар эзли, Салих бар көченә чүлмәккә бәрә, кечкенә Камилә белән Латыйфа капчык киеп сикерәләр. Әнә Йосыф – йомырканы кашыкка җайлаштырып маташа.

Күл буенда Торонтоның даһи химигы Әмир җыелган кунакларга тел өйрәтә:

– Ишкәк була бит инде, ишкәк. Белмисезмени, Агыйделкәйне кичкәндә, җырлыйм ишкәк ишкәндә...

Һәм йөрәк тибә.

**– Өч... унбиш... хәерле иртә!**

Миннән: «Нигә син бүлмәңдә кунмыйсың?» – дип сорыйлар. Мин мантыйкка сыярлык җаваплар табарга тырышам. Төнлә компьютер кабызсам, башкаларга комачауламармын дим. Ләкин дөресе ул түгел. Дөресе – шушында кайнаган дөньядан аерылырга куркам. Бүлмәгә керермен дә иртәнгә башка җирдә уянырмын кебек. Мин аны – төнгә кадәр бер-берсеннән аерыла алмаган сәлкешләр, әйдаманнар дөньясын үземчә саклагандай итәм. Менә шәмчекләр (төркемнәрнең кичке серләшүен без шулай атыйбыз) тәмамлана, ашханәдә Алимә, Марат, Гүзәл, Айгөл генә утырып калалар. Алар алдагы көнне планлаштыра, оештыру мәсьәләләрен хәл итә. Бераздан өй бөтенләй тына. Иртән – чак кына яктырып, күл өстенә томан таралгач, Чулпан апа уяна. Чулпан апа Америка университетында сатып алучыларның үз-үзен тотышын өйрәнә. Иртәнге ашка кадәр әнә шул җитди эшенә кереп чума ул. Башкалар торганчы уйнап калыйм дипме, аның артыннан ук нәни Зифа килеп чыга. Аннары өске каттан Валентина төшә – безгә иртәнге аш әзерләргә җыена. Бераздан егетләр уяна





– Марат, Ислам, Нияз абыйлар – уя-налар да йөгерергә китәләр. Аннары муенына сөлге аскан Алик абый күренә – көннең җылы-салкын булуына карамастан, йөзәргә бара ул. Менә хәзер Илсөяр апа төшәчәк, абыйсына шылтыратып, хәерле көн теләячәк тә, көн башланды дияргә була. Бар аланга җыр тарала: әйе, хәерле көн, «Сәләт» аланы!

– Син исеме инде хәзер минем сөю хисемнең…

Рафаэль абый белән Камилә фортепиано янында торалар. Ләйсән апа соңгы аккордларын ала да, аларга борыла:

– Минем яраткан композиторым. Резеда Ахиярова бу. Ренат Харис сүзләренә язылган. Менә Равил Харисов аны болайрак җырлый…

Ул яңадан клавишаларга кагыла. Ашханә тынлыгында Ләйсән апаның тавышы гына яңгырый. Бар хикмәт тә шунда бит: җырны Камилә белән Рафаэль җырлаячак, ә өйрәнүен – менә хәзер – бөтен алан өйрәнә. Биюгә йөрүчеләр дә, театр осталыгын сайлаучылар да, диджейлык нигезләрен үзләштерүчеләр дә – барысы да сүзсез калганнар.

Дөрес, һәр остаханә, һәр кечке чара әкрен-әкрен генә безне соңгы көнгә (ярар инде, төнгә) әзерли. Ләкин аңа гына түгел – алдагы аланнарга, алдагы чараларга, алдагы тормышка да. Һәм онытмассыңмы дигәндәй, йөрәк тибә: Мин сине яратам, ахры (бер… ике… өч…) – Резеда Ахиярова, Сөембикә сынын юнган сынчы (бер… ике… өч…) – Бакый Урманче, без бергә биегән көй (бер… ике… өч…) – «Чабата», нигә синең шаян күзләр (бер… ике… өч…) – Һади Такташ… Барбекю исе, маршмеллоу тәме (рәхмәт сиңа, Ян!) сеңгән соңгы төннең офыгы кызаргач та калачак алар. Ә әлегә – алан дәвам итә…

**– Өч… унбиш… элемтә бар**

Безнең көн шулай үтә: дәресләр, аннары төшке аш, хәрәкәтчән уеннар (әйе, җәй бит – күбрәк уйнарга, су коенырга кирәк), төркем вакыты (Монреаль кичләренә, «интеллектуаль квиз», «аулак өй», «интуиция» кебек уеннарга әзерләнү яки әзерләнмәү өчен), кечке чаралар (һәр көнне үзеңне һәм башкаларны яңа яктан ачу өчен), шәмчек…

Шәмчек – көннең иң серле вакыты. Бер яктан, ул узган көнгә нәтиҗә ясау кебек. Ләкин! Шәмчекнең үз кагыйдәләре бар. Әйтик, шәмчектә беркем дә икенче кешене бүлдерә алмый. Шәмчектә дөресен генә сөйләргә ярый. Һәм монда сөйләшкәннәр – монда кала. Синең төркемеңә карамаган бер генә сәлкеш тә, бер генә әйдаман да мондагы сөйләшүләрне белмәячәк. Шәмчекләр бер-береңә, үзеңә ышанырга өйрәтә. Ә иң азакта без кулга-кул тотышып, сигнал җибәрәбез. Элемтә бармы? – дип сорый төркем әйдаманы әкрен генә. Бар – дип пышылдый сәлкешләр һәм шәмнәргә өрә.

– Күрәсеңме, – сәлкешләр соңгы шәмчеккә таралышкач, мин Алимәгә эндәшәм. – Күрәсеңме, ул инде күптән татарчага күчте. Теге халәте хәзер үзенә дә сәердер.

Шулай буласын белә идекме без? Белә идек. Кайдан, дип сора. Без үзебез дә кайчандыр әле үзен белмәгән үсмерләр түгел идекмени соң?

– Тозлы суга салсаң, кыяр тозлана инде ул, – дигән иде бервакыт мин укыган гимназия директоры. (Камәрия апа, мин хәтерлим!) – Бала йөрәген ачар өчен тиешле мохит кенә кирәк.

Һәм йөрәк, ачылырга әзер йөрәк кирәк, дип өстәр идем мин.

* * *

Без Казанга таба очабыз. Төрлебез самолетның төрле почмагына таралышкан. Ләкин карашлар әледән-әле очраша.

– Сез бөтенегез бер гаиләдәнме әллә? – дип сорый минем янда утырган француз кызы.

Мин – баш кагам. Һәм йөрәк… тибә…